Невозможно обойти стороной пословицы и поговорки, которые показывают веру татар в Аллаха: Алла язмаган эш булмас [2: 17]. Но это не исключает того, что среди татар были люди, которые критически и сатирически относились к верующим: Атны Аллага тапшырсаң да, дилбегәне үзең тот [2: 17].

В пословицах и поговорках татарского народа восхваляется единство и дружба: Күпчелек кайда – көч шунда [2: 17]. Кешенең иң зур дәүләте – чын дус [2: 17].

Издавна татарские пословицы и поговорки говорят о семейной жизни, о морально-этических, педагогических, эстетических взглядах народа. Большая роль в жизни отдается семье и любви: Кошлар оясыз булмый, кеше семьясыз булмый [2: 19]. Любовь к Родине – высшее нравственное качество человека: Ватан барыннан да газиз [2: 20]. Илнең төтене дә хуш исле [2: 20].

Татарский народ стремиться к знаниям, быть сильным, храбрым, совестливым, справедливым, и воспитанным, а труд – условие существования: Эшле кеше – көчле кеше [2: 20].

Татарские пословицы содержат значительное количество советов, обобщений, указаний конкретных проявлений трудовой деятельности: скотоводства, охоты, обработки земли и другие. Имеет место и восхваление знания ремесла, труда, профессии: Һөнәре бар ком өстендә көймә йөздерер [2: 21]. Егет кешегә житмеш төрле һөнәр дә аз [2: 21].

Еще одной традиционной тематикой для татарских пословиц и поговорок является наука, знание, чтение-письмо, их роль для жизни: Белем-белгечлек патшалыктан югары [2: 21].

В татарских пословицах и поговорках поднимается множество тем, связанных с нравственностью, воспитанностью, деяниями. Особое место занимают такие, которые призывают уважать пожилых, быть гостеприимными, терпеливыми. Осуждают жадность, болтливость. Если же встречаются пословицы и поговорки, которые отвергают утвердившиеся морально-этические взгляды народа, то стоит учитывать конкретные обстоятельства (когда, в какое время, кем) появления таких пословиц и поговорок.

Из вышесказанного следует отметить, что пословицы и поговорки – это отражение народной мудрости, в них хранится представление народа о самом себе и поэтому свойства национального характера можно попробовать постигнуть через пословицы и поговорки народа.

**ЛИТЕРАТУРА**

1. Исәнбәт Н. Татар халык мәкальләре. Казан: Татар. кит. нәшр., Т. 3. 1967. 1014 б.

2. Татар халык иҗаты. Мәкальләр һәм әйтемнәр. Казань: Татар. кит. нәшр., 1987. 591 б.

## ТАБУ СЛОВ, ИЛИ «СЛОВОМ МОЖНО УБИТЬ, СЛОВОМ МОЖНО СПАСТИ»

*Гаптелбаров И.Р., Саляхова С.А., Арский педагогический колледж, студенты I курса*

*Рук. – Д.М. Гаптелбарова, Л.М. Кашшапова*

Раньше бытовали верования, связанные сильным воздействием на человека слова. Словом можно было действовать на окружающий мир – вера в эту силу слова лежит в основе многих магических и заклинаний. В связи с этим существовали и правила поведения со словом, соблюдая которые проживешь долго и счастливо, и, наоборот, не выполняя которые, навлечешь на себя всевозможные несчастья. И действительно, недаром ведь говорят, что «словом можно убить, а можно и спасти». Чаще всего, эти правила выражались в запретах (табу).

Запреты на произнесение слов.

1.1.Табу слов.

Табу – этнографическое понятие, касающееся и языка. Табу означает запрет, на разных ступенях развития общества. Исходя из этого, такой запрет может распространяться и на факты языка.

1.2. Табу имен.

Важное значение личному имени человека придавали наши предки. Выбор имени для ребёнка производился тщательно, по святцам. Святцами называлась церковная книга с календарём, где были перечислены все почитаемые церковью святые. Имена святых были расположены по дням, в которые отмечается их память.

В период до крещения, то есть совершения специального церковного обряда, в ходе которого ребёнок получал имя, его называли каким-нибудь временным именем. В России в качестве временного использовалось имя Богдан, что значит данный Богом.

1.3. Табу места.

Нельзя ругаться за столом. «Стол – что в алтаре престол», – говорили в старину. К столу нужно было относиться как к алтарю в церкви: нельзя было бегать вокруг стола, класть на него посторонние предметы (шапку, например), садиться на стол, и, в частности, ругаться за столом. «Эх, сказал бы дурное слово, да стол в доме мешает», – говорил крестьянин. Если уж очень хотели поругаться, то выходили в помещение, где стола не было. Этот запрет служил содействию мира, лада в крестьянской семье.

1.4. Табу времени.

Нельзя ругать себя или других в неурочный час. Когда наступает этот час, «неровен час», еще называли – «дурной час»? К этому времени относились моменты перед восходом и заходом Солнца, время, когда служба идет в церкви, время полдня.

«Начальник не опаздывает, начальник задерживается!» – такую фразу любят бросать опоздавшие начальники своим подчинённым. В чём её смысл? Разве не всё равно, как назвать происшедшее, – ведь суть от этого не изменится? Оказывается, от слова зависит многое: опоздать – значит, провиниться, совершить проступок, а задержаться – как-то солиднее, у задержавшегося человека, скорее всего, были уважительные причины, не позволившие ему прийти вовремя. Объявить выговор опоздавшемупросто необходимо в воспитательных целях, но у кого поднимется рука наказать задержавшегося. Несмотря на крайнюю занятость или непреодолимые препятствия, всё же смог прийти?

Заменяя слово, производящее, на ваш взгляд, недолжное впечатление на слушателя, каким-то смягчающим, нейтральным, воздействующим благоприятнее, вы употребляете эвфемизм. В данном случае «задержаться» – это эвфемизм к «опоздать».

Итак, употребляя эвфемизм, то есть другое слово для называния того же самого явления, вы как будто изменяете и само это явление: тощий, названный худощавым, на глазах становится чуть более упитанным, толстый же худеет – от одного лишь слова полный. Использование эвфемизмов в речи – вещь очень древняя.

Не случайно бытует поговорка «Слово – серебро, молчание – золото». Слово это продолжение человека. Язык наш – достаточно солидного возраста, корни его уходят вглубь веков. Поэтому табуирование актуально в наше время. Из всего многообразия тем, которые можно поднять в разговоре о «великом, могучем, правдивом и свободным» языке, мы выбрали лишь один аспект – сакральное отношение в традиционной русской культуре. К слову и его составляющим – голосу, времени, звуку.

Нужно отметить, что отношение это было не просто важным, а глубоким, вдумчивым, четким. Анализ бытовавших представлений, предложенный в этой работе, прояснил нам некоторые стороны мировосприятия русского народа.

**ЛИТЕРАТУРА**

1. Булаховский Л.А. Введение языкознание. М., 1953. С. 51.
2. Волков С.В. Я познаю мир. М.: Издательство АСТ, 2002. 493 с.
3. Русская школьная библиотечная ассоциация. 2007. 103 с.
4. Даль В.И. Толковый словарь русского языка. М.: ЭКСМО. 2002. 598 с.

## ТАТАР ФОЛЬКЛОРЫНДА МУЗЫКАЛЬ ЖАНР (бишек җырлары)

*Гәрәева Ә., Саба р-ны Шәмәрдән лицее, X сыйныф*
*Җит. – Д.И. Галиҗанова*

Бу хезмәтебезнең максаты татар халкының борын-борыннан формалашып килгән рухи культурасы, бай фольклор хәзинәсе булган бишек җырларын өйрәнү. Мәктәпләр булмаган вакыттан ук халык иҗаты әсәрләре күп гасырлар дәвамында балаларның рухын тәрбияләп килгәнлеген ачыклау.

Эшебезне башкарганда, Н. Исәнбәт, К. Насыйри, Р. Ягъфәров хезмәтләренә таяндык.

Балалар иҗаты әсәрләре тел материалы булу ягыннан да игътибарга лаек. Аларда архаизмнар, диалектизмнар, күрше ха-

лыклардан кергән сүзләр күп очрый. Бу материаллар тел тарихын, диалектларны, сүзләр семантикасын, сүз ясалышын өйрәнүчеләргә дә кыйммәтле бер чыганак була ала.

Бишек җырларын «хатын-кызлар поэзиясе» дип йөртәләр. Алар аналар, бала багучылар тарафыннан иҗат ителгәннәр. Буыннан буынга күчеп, хәзерге көнгә кадәр килеп җиткәннәр. Көнчыгышның бөек галиме Әбугалисина «бәбиләрнең табигатен ныгыту өчен, беренчедән, тирбәтү, икенчедән, йоклатканда көйләнә торган музыка һәм җырларның бик файдалы икәнен билгеләп уза [4: 14]. Ш. Мәрҗани, К. Насыйри кебек галимнәр дә бишек җырларының бала тәрбияләүдәге әһәмиятен аерып әйтәләр.

Бишек җырларының килеп чыгышы мәсьәләсе балалар фольклорын өйрәнүчеләр арасында күп бәхәсләр уята. Рус фольклорчысы Н.М. Элиаш: «Бишек җырлары кешелек җәмгыятенең башлангыч чорында барлыкка килгән», – ди [4: 16].

Коми балалар фольклорын өйрәнүче Ю.Г. Рочев та: «Бишек җырлары өч нәрсәне: магия, йокыга талдыру һәм эстетик максатны күз алдында тота», – дип күрсәтә [4: 16].

Без бишек җырларын өйрәнү барышында аларны берничә темага аерып карадык:

1. Бишек җырлары аша аналар баланың бәхетен хезмәт сөючән булып үсүендә күрәләр, саулык белән гомер итүен телиләр.

2. Яхшы укып, гыйлем иясе булуына өмет итәләр.

3. Аналар ир бала белән горурланалар.

4. Кыз балаларга багышланган җырларда баланың чибәр, зифа буйлы, уңган булып үсүен теләү мотивлары өстенлек ала. Ана кызының илдә бер матур булып үсүен өмет итә.

5. Җырларда аналар үзләренең кызларына авыр тормышларын бәян итәләр.

6. Бишек җыры репертуарында баланың йокысын, аның килеш-килбәтен, әйләнә-тирәсендәге әйберләрне тасвир итүгә багышланган әсәрләр байтак:

Әлли-бәлли бишеге,<br>
Имеккәндә – имезе,<br>
Бал ялаган кашыгы,<br>
Сусаганда – кымызы [3: 25].

7. Татар бишек җырларының төрле җәнлекләр, кош-кортлар турындагылары аерым бер төркемне тәшкил итә:

Әлли-бәлли Бәхтияр.

Еламаганны кереп алма,
Ызба артында бүре бар:
Елаганны кереп ал [3:27].

8. Аналар балаларның бәхетен иң беренче туган илгә хезмәт итүдә күрәләр:

Әлли-бәлли ит, улым,
Атаң сугыш кырында,
Сандугачым, былбылым.
Сынмас кылыч кулында [3: 24].

Эзләнү эшебездә бишек җырларының төзелешенә дә игътибар иттек. Мәсәлән, алда әйтелгән дүртьюллыкта «җ», «к», «г» кебек тартык авазларның кабатланып һәм чиратлашып килүләре бишек җырының яңгырашын колакка ятышлы итә, матур ассоциация тудыра. Әйтерсең ана җырламый, ә назлы тавыш белән пышылдап сөйли төсле.

Бишек җырлары поэтикасында эндәш сүзләр дә мөһим роль уйныйлар. Еш кабатлана торган карлыгачым, былбылым, багалмам, бәгърем, җомрым, йолдызым, гөлием, сачагым, бәбкәем, күз нурым кебек эндәш сүзләр бишек җырларына үзенчә бер назлылык, ягымлылык, йөрәк җылысы өстиләр. Алдарак китерелгән мисалда да бу ачык күренә.

Аваз ияртемнәре, ымлык сүзләр дә аерым поэтик чара булып хезмәт итәләр. «Әлли-бәлли», «чү-чү», «шыбыр-шыбыр» кебек сүзләр бишек җырларында тынычлык халәте тудыра, әсәр ритмын бишек тирбәтү ритмына туры китерергә ярдәм итә.

Бишек җырларында төп лексик сурәтләү чаралары аз, троплар, метафора, сынландыру һ.б. юк диярлек. Чагыштыруларда бала еш кына халык поэзиясенең традицион образлары – алма, гөл; ә күзләре бөрлегән, карлыган белән чагыштырыла:

Минем кызым дәү кебек,
Ике күзе янып тора,
Бакчадагы гөл кебек.
Кара бөрлегән кебек [3: 25].

Җырларда рифмаларның күп төрләрен очратырга була. Аларда арадаш рифмалар да (аб аб), пардаш рифмалар да (аа бб) һәм, хәтта, тоташ рифмалар да (аааа) кулланыла. Мәсәлән:

Әлли-бәлли итүче,
Әткәң синең җиңүче,
Утлар-сулар кичүче,

Күп авырлык күрүче [3: 24].

Тема һәм эчтәлеге белән заман рухына туры килгән җырлар һаман яшәвендә дәвам итә. Еш кына традицион җырлар калыбында яңа эчтәлекле җыр-импровизацияләр туа. Шулай ук аерым шагыйрьләр, композиторлар тарафыннан иҗат ителгән бишек җырлары да халык репертуарына кереп киткәли. Мәсәлән, Дәрдемәнд сүзләренә Р. Ахиярова иҗат иткән «Бәллү», Г. Тукай сүзләре, халык көенә язылган «Бишек җырлары»н, композиторлардан Н. Җиһанов, З. Хабибуллин, М. Яруллин, А. Ключарев көеләрен атап үтәргә булыр иде

Балалар фольклоры халкыбызның күп гасырлар дәвамында тупланып килгән олы поэтик һәм педагогик мирасы ул. Җиргә килгән һәр буын шул әсәрләрдә тәүге кат матурлык, шигърият белән очраша. Шулар ярдәмендә аның күңелендә туган телгә, туган җиргә мәхәббәт тернәкләнә башлый. Нәни чакта сөйләнгән шигъри әсәрләр мәңгелеккә кеше рухында кала. Алар гомер буена адәм баласын самими матурлыкка өнди, күңел түрендә шигърият чишмәләре булып челтери.

**ӘДӘБИЯТ**


1. Балалар фольклоры һәм җырлы-сүзле йөз төрле уен. Җыеп төзүче һәм аңлатма мәкаләләр бирүче Н. Исәнбәт. Казан: Татар. кит. нәшр.,1984. 488 б.
2. Бишек җырлары: Төзүче И. Алмазов. Казан, 2000. 104 б.
3. Татар халык иҗаты. Балалар фольклоры. Казан: Татар. кит. нәшр.,1993. 336 б.
4. Тукай Г.Әсәрләр 4 томда. Т. 4. Казан: Татар. кит. нәшр.,1977. 432 б.
5. Ягъфәров Р.Ф. Шигърият чишмәләре. Казан: Татар. кит. нәшр., 1985. 158 б.


## ТӨС КОМПОНЕНТЛЫ ЧАГЫШТЫРУЛАРНЫҢ ТАТАР ӘДӘБИЯТЫНДА ЧАГЫЛЫШЫ


*Гомәрова Д., КФУ, I курс студенты*

*Фән. җит. – филол. фән. канд., доц. Ф.Х. Габдрахманова*


Төс белдерүче сүзләр төрле фән тармакларында өйрәнелә. Психологиядә төс проблемасы тоемлау һәм кабул итү дәрәҗәсендә каралып, кешенең психологиясенә, кәефенә һәм сәламәтлегенә дә тәэсир итә дип санала. Төсләр һәрбер халыкта төрлечә кабул ителеп, телдә дә үзенчәлекле чагылыш таба. Алар телдә һәрдаим үзгәреп һәм үсеп торалар.

Әдәбиятта төс гомуми категорияләрдән берсе булып санала. Төс – эстетик тәэсирле объектлар тудыру юлы белән тормышны үзләштерү, аңлату формасы. Төс әдәби әсәрдәге сурәтнең өлешләрнең характеристикасын атый. Аннан башка әдәбиятта

тормышны сурәтләү, күзаллау, танып-белү, кабат иҗат итү мөмкин түгел. Шулай да кешеләр төсләргә карата төрлечә нисбәттә торалар. Билгеле бер әдипнең эстетик зәвыгы нинди дә булса төсләрне аеруча яратуда чагыла. Бу аларның биологик үзенчәлекләренә (җенесе, яше) һәм иҗтимагый-психологик дәрәҗәсенә (милләтенә, темпераментына) бәйле.

Күпсанлы тикшеренүләр төсләрнең төп мәгънәләре белән бергә өстәмә символик мәгънәләре дә барлыгын дәлилли. Символ – универсаль сәнгати һәм мәдәни категория. Һәр символ – ниндидер мәгънә белдерүче, шул мәгънә белән кушылган, ләкин аның белән чикләнми торган образ. Кечкенә генә берәмлек аша гомумине аңлатучы символның иң әһәмиятле сыйфаты булып аның күпмәгънәлелеге тора.

Төсләр символикасы белән кеше аңы катламнары, кешеләрнең мәдәни-иҗтимагый тормышы арасында тирән бәйләнеш бар. Төс кешенең психик дөньясында аерым һәм үзенчәлекле үзгәрешләр барлыкка китерә. Төсләр семантикасының үзенчәлеге – күпмәгънәлелектә. Һәр төстә бик күп төрле мәгънәләр яшеренгән. Лексик берәмлекләр исә кешенең рухи дөньясын чынбарлык белән бәйлиләр.

Төс символлары халыкның тарихы һәм мәдәнияте арасында да бәйләнеш барлыгын белдерә. Һәрбер милләтнең үз төсе бар, ягъни һәр милләт аерым бер төскә өстенлек бирә. Татар милләтенең төп төсе – яшел, ул яшәү һәм яшәрү төсе. Әлеге төс татар халкының дөньяны кабул итү һәм бәяләү үзенчәлеген шактый тулы ачып бирә.

Проза әсәрләрендә төсләр үзенең туры номинатив мәгънәдән башка (төсне белдерә торган мәгънә), күчерелмә мәгънәдә (метафорик яисә предметка эмоциональ билгесен бирү) һәм шулай ук символик мәгънәдә дә очрый. Әйләнә-тирә дөньяны сурәтләү өчен, әсәрнең тональлеген укучыга дөрес итеп тапшыру өчен һәм, гомумән, әсәрнең төп идеясен үзләштерү өчен табигый объектларның төс атамалары кулланыла:

*Әнә инде офыкта зәңгәрсу диңгез күренә.*

*Әнә ап-ак кар белән томаланган дала.*

*<...> аның өстендәге кара урман төтенләнеп күренә.*

*Ишегалдына, йөрүче булмаганга, ямь-яшел чирәм үскән; бөтен җир буш, бөтен нәрсә тын гына нәрсәдер көтә* (С. Җәләл “Дим буенда”).

Хайваннар дөньясын тасвирлаганда, төс компоненты әһәмиятле урын алып тора:

*Әмма ул бик ерак китә алмады, урам чирәмендә үлән чемчеп йөргән яшькелт-сары каз бәбкәләре тезелешеп аның артыннан иярделәр* (Г. Гыйльманов “Оча торган кешеләр”).

*Яңа тарантаска җигелгән ике яхшы кара атны, әйбәт киемле кучерны, арбага ята төшеп утырган русны күреп, башта эчем жу итеп китте* (Г. Ибраһимов “Уты сүнгән җәһәннәм”).

Төсләр дөньясы үзенең табигате буенча тирән һәм антропоцентризмга хас. Чөнки барлык төсләр һәм төсмерләр кешегә аң белән бирелә. Сирәк булмаган очракта да төс атамалары эстетик категория төркеменә күчәләр. Төсләр кешенең портретын, тышкы кыяфәтен, өс киемен тасвирлаганда ярдәм итәләр. Автор теге яки бу образга үз психологик үзенчәлеген бирә:

*Матур бу кызның озын керфекле кара күзләре алсу-ак йөзенә, могҗизалы якутлар шикелле, нур чәчеп торганлыктан, гүзәл башы, хәтта бөтен буе нурда йөзә шикелле күренә иде.*

*Ал кием безнең Хәятка бик килешә…*

*Студентның ачыграк кына зәңгәрсу күзләре Хәятта бик матур тойгы калдырдылар* (Ф. Әмирхан “Хәят”).

Мифологик дөньяны тасвирлаган вакытта төс символикасы аша автор үзенең тормыш гаме, яшәү мәгънәсе турындагы уй-фикерләрен, фәлсәфи карашларын гәүдәләндерә:

*Илсез-җирсез итеп кара көчләр // Ятимлеккә илтеп ташлады* (Р. Сәгъди “Бакчасарай гөлләре”).

*<…> ул ал фәрештә шикелле була* (Ф. Әмирхан “Хәят”).

Күчерелмә мәгънәдә кулланылган төшенчәләрнең төсләрен билгеләү өчен дә еш кына төсләр кулланыла: *Инде аның рояльдә уйнаган көйләреннән өметсезлек, кара бәхеттән зарлану, ачынып елаулар аңкый* (С. Җәләл “Дим буенда”); *Җанга кара тап булып ята торган әйбер ул* (Г. Гыйльманов “Оча торган кешеләр”).

Димәк, әсәрләрдә төс белдерүче сүзләр авторның стилен, иҗадилыгын һәм дөньяны күзаллавын билгеләүдә зур роль уйный, әсәрләрне җанлы итә, күренеш-вакыйгаларны тасвирлаганда образлы картина тудыра. Төсләр аша кеше аңында аерым бер дөнья сурәте туа.

**ӘДӘБИЯТ**

1. Базыма Б. Цвет и психика. Харьков, 2001. 54 б.

2. Поварисов С.Ш. Татар телендә чагыштыру төзелеше. Уфа: БашДУ, 1996. 100 б.

КОНЦЕПТ СЛОВА «ТАҤАРА» (БОГ)
(в контексте якутских фразеологизмов)

*Гурьев А., Северо-Восточный федеральный университет, магистрант I курса*
*Науч. рук. – канд. филол. наук, стар. препод. А.Е. Шамаева*

Фразеология изучает сложные языковые образования, которые находятся на стыке лексики, синтаксиса, семасиологии и стилистики, и поэтому для установления признаков фразеологических единиц целесообразно сравнить их с соприкасающимися структурно-семантическими явлениями.

В семантическом плане фразеологическая единица отличается от слова прежде всего своей яркой экспрессивностью, эмоциональностью. В исследовании мы затронули фразеологизмы, основным компонентом в которых является слово таҥара.

Якутское слово таҥара («бог») происходит от древнетюркского teŋri. Шведский архивист, библиотекарь, искусствовед и профессор Улла Эхренсвард в своей книге [4] пишет про слово Tengri, ссылаясь на источник: teŋri 'бог' < кит. čen-li /40/ 'бог' (Benzing, 1954, 685). Ср. Pelliot, 1944, 185. (перевод лингвиста-тюрколога Н.А. Баскакова).

Оказывается, слово čen-li, которое написано адаптированной латиницей, на пиньине пишется как chēnglí, а на китайском как 撐犁／撐犁, и означало слово «бог» на китайском языке того времени и слово «небо» на языке хунну (видимо тогда оно уже было заимствовано) в 4 веке до нашей эры. Слово Chēnglí в современном китайском языке трансформировалось до 上帝 (Шангди / Shàngdì), но в том же значении. То есть бог на современном китайском языке будет Shàngdì.

В таких фразеологизмах как таҥараҕа мастаммыкка дылы и таҥараҕа ыллаан кэбистэ можно наблюдать употребление слова таҥара в значении «небо». Как было сказано ранее, когнат данного слова на языке хунну означал «небо». В якутском же языке слово таҥара в значении «небо» считается устаревшим и встречается лишь в фольклоре, что зафиксировано в большом толковом словаре якутского языка.

Кроме того, имеются фразеологизмы, слово таҥара в которых варьируется со словом күн. Например, таҥара / күн курдук көрөр и таҥара / күн накааһа. Из этого следует, что слово таҥара было синонимично слову күн. Но в толковом словаре оно в данном

значении не зафиксировано. Тем не менее, в книге Николая Алексеевича Алексеева «Традиционные религиозные верования якутов в XIX – начале XX в.» говорится о том, что якуты поклонялись солнцу и считали, что именно на солнце живет бог.

Примеры фразеологизмов со словом таҥара, основанных на якутских верованиях:

1. ТАҤАРАҔА МАСТАММЫККА ДЫЛЫ (МАСТАН) храбриться перед слишком сильным противником (Кулаковский) (о бессильной угрозе). Букв. все равно что небу палкой грозить.

2. ТАҤАРАҔА ЫЛЛААН КЭБИСТЭ түөлбэ терять что-л. безвозвратно. Тэҥн. халлааҥҥа туойан кэбистэ.

3. ТАҤАРА (КҮН) КУРДУК КӨРӨР глубоко уважать кого-л., преклоняться перед кем-л; боготворить. Тэҥн. таҥара гынан үҥк (үҥэр таҥара оҥоһун); таҥара оҥостор.

4. ТАҤАРА НАКААҺА сильное, жестокое мучение; терзание. Букв. божье наказание. Тэҥн. күн накааһа.

Из этого следует, что слово таҥара имеет китайское происхождение и изначально имело значение «бог». Затем оно было заимствовано из китайского языка в язык хунну и приобрело значение «небо». Можно предположить, что при этом значение «бог» не утрачивалось. Позднее, на якутской почве, под словом таҥара стали понимать также «солнце», так как это непосредственно связано с верованием якутов.

**ЛИТЕРАТУРА**

1. Алексеев Н.А. Традиционные религиозные верования якутов в XIX – начале XX в. Новосибирск: Изд-во Наука, 1975. 197 с.

2. Большой толковый словарь якутского языка = Саха тылын быһаарыылаах улахан тылдьыта: в 15 т. Т.Х: (Буква Т: т – төһүүлээ) / Под ред. П.А. Слепцова. Новосибирск: Наука, 2013. 575 с.

3. Нелунов А.Г. Якутско-русский фразеологический словарь. – Новосибирск: СО РАН «Гео», 2002. Т. 1. 287 с.

4. Turcica et Orientalia. Studies in honour of Gunnar Jarring on his eightieth birthday. Istanbul, 1987.

5. Ulla Ehrensvärd. Turcica et Orientalia. Studies in honour of Gunnar Jarring on his eightieth birthday. Istanbul, 1987.

## КАРАМАНЛЫ ТӨРЕКЛӘР ТУРЫНДА КЫСКАЧА МӘГЪЛҮМАТ

*Гүләр Окан, КФУ, I курс магистранты*

*Фән. җит. – филол. фән. канд., доц. З.Н. Кириллова*

Әлеге эштә Анатолиядә яшәүче төрекләрнең бер өлеше булган, тик алардан дин һәм грек графикасын кулланулары ягыннан

аерылган караманлы төрекләр, шулай ук алар кулланган алфавит турында кыскача мәгълүмат бирелә.

Караманлы төрекләр – Анатолиядә яшәгән һәм христиан динен тоткан төрекләр алар. Аларның килеп чыгышлары буенча ике караш бар. Беренче караш аларның грек булуы, ләкин Эгей диңгезе буйларыннан Анатолиягә күчкәч, әлеге халыкның, үз телләрен онытып, төрек телендә сөйләшә башлавы турында сөйли. Бу карашны күбрәк грек галимнәре яклый. Күбесенчә төрек галимнәре яклый торган икенче караш буенча, караманлы төрекләр – Урта Азиядән Анатолиягә күчеп, шунда Византия армиясендә хезмәт иткән, аннан соң христиан диненә күчкән төрекләр алар [1: 106]. Димәк, караманлы төрекләр белән печенеглар арасында нинди дә булса бәйләнеш бар дияргә мөмкин.

Нишләп аларны караманлы төрекләр дип атаганнар? Аларның әлеге исемне алулары үзләренең яшәү урыннары Караман регионы белән бәйле. Бүгенге көндә Караман шәһәр атамасы гына булса да, урта гасырлардан алып яңа гасырларга кадәр регион атамасы булып кулланылган. Әлеге регионда берничә шәһәр урнашкан булган: Кайсери, Конья, Нигде, Невшехир һәм Караман шәһәрләре. Шулай да караманлы төрекләр Караман регионында гына яшәмәгәннәр [1: 105]. Әмма Төркия республикасына нигез салынганнан соң, 1923 елның 24 июлендә расланган Лозанна шартнамәсе нигезендә Грециядә яшәүче төрекләрне Төркиягә, ә Төркиядә яшәүче грекларны (Истанбул шәһәрендә яшәүчеләрдән тыш) Грециягә җибәргәннәр. Шул сәбәпле караманлы төрекләрне дә, грек санап, Грециягә җибәргәннәр. Бу караманлы төрекләр өчен бик авыр хәл булган. Чөнки алар грек телен бөтенләй белмәгәннәр. Шуның өчен озак вакыт грек телен белмичә, үзара төрекчә сөйләшеп яшәгәннәр. Ә бүгенге көндә алар арасында өлкән яшьтәгеләр генә төрек телен хәтерли. Караманлы төрекләрнең төрек телендә генә сөйләшкәннәрен шушы җөмләләрдән аңлый алабыз: «Türkçe konuşuyorlardı. Buraya gelincik de Türkçe konuşuyorduk. Urumca bilen yok idi. Çocuklarımız bilmiyordu Urumca» (Төрекчә сөйләшәләр иде. Монда килгәч тә төрек телендә сөйләшә идек. Беркем дә грекча белми иде. Балаларыбыз да белми иде грекча) [2: 220].

Шулай ук караманлы төрекләр күбесенчә төрек исемнәрен кулланганнар. Төрек исемнәрен XIX гасырның уртасына кадәр дә куллануларын дәвам иткәннәр. Мәсәлән: Карагөз, Һасмәләк,

Кыймәт, Малкоч, Чакмак, Гүлизар, Кутлубәй, Алагөз, Каплан, Ягъмур, Баһадыр улы Турмуш, Тимур, Меликшаһ, Шаһин, Бүлбүл, Демир, Гүляр, Янык, Кумру, Кузу, Шириногълу һ.б. [1: 109].

Караманлы төрекләр өчен дини китаплар гына басылмаган, дөнья әдәбиятыннан тәрҗемәләр, шигырь һәм җыр китаплары, дәреслекләр дә басылган, шулай ук газеталар, балалар өчен газета һәм журналлар да чыгарылган. Дөнья әдәбиятыннан тәрҗемәләр арасында иң күренеклеләре булып Д. Дефоның «Робинзон Крузо» әсәре белән А. Дюманың «Граф Монте-Кристо» дигән әсәре тора. Караманлы төрекләр өчен чыгарылган китаплар кайвакытларда аларның сөйләш үзенчәлекләре нигезендә язылган, ә кайвакытларда, гарәп графикасындагы госманлы төрек теле имласын нигез итеп, грек графикасында язылган. Караманлы төрек теле көндәлек тормышта да бик актив рәвештә кулланылган: рекламалар, игъланнар, лотерея билетлары һ.б. караманлы төрекчәсендә дә чыккан.

Грек алфавитында 24 хәреф бар. Шулай да грек алфавиты, төрек телендә булып, грек алфавитында булмаган «җ, ч, х, ы, ж, ө, ү» авазларын күрсәтү өчен җитмәгән. Әлеге авазларны «ике яки өч хәрефне берләштерү» һәм «хәреф өстенә нокта кую» ысуллары белән язганнар [3: 138]. Караманлы төрекләр алфавиты белән язылган китапларны уку гарәп графикасы белән язылган госманлы төрек телендәге китапларны укуга караганда җиңелрәк, чөнки госманлы төрек телен язуда кулланган алфавитта төрек телендәге 8 тартык аваз 4 хәреф белән генә күрсәтелгән, ә караманлы төрекләр кулланган алфавитта авазларның барысы да күрсәтелгән.

Әгәр дә караманлы төрекләр Грециягә күчәргә тиеш булмасалар, караманлы төрек әдәбияты баеп дәвам итәр иде. Шул сәбәптән караманлы төрек әдәбиятының бетүе – төрек әдәбияты өчен дә бик зур югалту ул.

**ӘДӘБИЯТ**

1. İbar Gazanfer. Anadolulu Hemşehrilerimiz Karamanlılar ve Yunan Harfli Türkçe. İstanbul: İş Bankası Kültür Yayınları, 2010. 198 s.

2. Anzerlioğlu Yonca. Karamanlı Ortodoks Türkler. Ankara: Phoenix Yayınevi, 2003. 432 s.

3. Berkol B. Yıl Önce Yayımlanan Yunan Harfleri ile Tükçe (Karamanlıca) Bir “Robinson Cruseo” Çevirisi. Sosyoloji Konferansları, 2011. S. 135-158.

# МӘГЪРИФӘТЧЕ, ГАЛИМ, ДИН ӘҺЕЛЕ Ш. МӘРҖАНИ

*Гыйззәтуллина А., Удмуртия Республикасының социаль-педагогика көллияте, III курс студенты*
*Җит. – В.Х. Хәкимова*

Ш. Мәрҗани Казанга якын Ябынчы авылында мулла гаиләсендә 1818 елда дөньяга килгән. Әтисе Ташкичүдә имам булган, анда мәдрәсә ачкан. Ш. Мәрҗани да шунда беренче сабакларын алган. Балалыкта ул әтисе һәм бабасың китапханәсен укып чыккан, 17 яшенән үзе үк мөгаллим булып әтисенә булыша башлаган. Мәрҗани 20 яшьтә Бохарага укырга киткән. Монда иң күренекле мөдәррисләрдә белем алган. Анда зур китапханәләрдә әзерләнгән, чөнки аңа мәдрәсә белеме генә җитмәгән.

Ш. Мәрҗани XIX гасырда татарда гына түгел, барлык мөселман дөньясында да иң якты булып кабынган йолдызлардан. Аннан соң килгән дин галимнәребезнең күркәмнәре Галимҗан Баруди, Муса Бигиев, Физа Фәхретдин, Әхмәтһади Максудилар да нәкъ менә Мәрҗани салып калдырган юлны дәвам итәләр.

Ш. Мәрҗани эшчәнлегенең мөһим бер тармагы – аның реформаторлыгыннан килеп чыга торган һәм фәнни-практик эшчәнлеге белән тыгыз бәйләнгән, бергә үрелеп барган мәгариф эшчәнлеге, мәгърифәтчелеге. Бу эшчәнлекне ике аспектта карарга кирәк. Ул, бердән, дин әһеле һәм мөдәррис буларак, татар мәдрәсәләрендә хөкем сөргән кадимчелеккә, искергән укыту ысулларына каршы чыга. Казанның иң атаклы саналган мәдрәсәсендәге укыту-тәрбия системасына җитди үзгәрешләр кертә. Мәдрәсә шәкертләренә ислам тәгълиматын, шәригать кануннарын өйрәтү, гарәпчә – фарсыча кадими китапларны ятлату белән чикләнмичә, фәнни нигезләрен – математика, астрономия, география, биология, физика, гуманитар фәннәрне укытуны кертә, медицина һәм фармакология, әдәбият, сәнгать белеме нигезләре белән таныштыра. Мөдәррис (укытучы) буларак, Мәрҗанинең педагогик кредосы гуманлык, шәхеснең мөстәкыйль фикерләү хокукын тану һәм укыту тәрбиядә шуңа таянудан, кешенең иҗат эшчәнлегенә, дөньяны танып белү һәм тормышны үзгәртеп кору сәләтенә тирән ышанудан гыйбарәт. Ш. Мәрҗани – яңа заман милли педагогикасының юл башында торучы, аны нигезләүче. Әле галим эшчәнлегенең бу тармагын бөтен тулылыгы һәм тирәнлеге белән өйрәнәсе бар. Бездә әле мәгариф тарихы да, милли педагогиканың бай хәзинәсе дә, “Мөхәммәдия”, “Галия”,

“Хөсәения”, Иж-Буби мәдрәселәре тарихлары да, Галимҗан Баруди, З. Камали, Бубилар кебек мәшһүр укытучыларның педагогик мирасларын да өйрәнелеп беткән дип әйтеп булмый. Ә бит аларның барысы да Ш. Мәрҗани хәзерләгән, эшкәрткән җирлектә, ул чәчкән орлыклардан үсеп чыккан җимешләр иде.

Икенче яктан, Мәрҗани – киң мәгънәдә, үзенең җаны, бөтен барлыгы белән мәгърифәтче, XIX гасырның икенче яртысында барлыкка килгән, бөтен Русия мөселманнары арасында киң таралган, көчле яңгыраш алган XX гасыр башында илдә җәелгән милли азатлык хәрәкәтенең олы елгасын барлыкка китергән, җәдитчелеккә капка ачкан һәм юл күрсәткән олы шәхәс. Бу хәрәкәтнең җитәкчесе һәм идеологы, бөтен төрки дөньяның мәшһүр мәгърифәтчесе һәм сәясәтчесе И. Гаспринский Ш. Мәрҗани идеяләрен дәвам иттерүче, гамәлгә куючы була. Максатлары – татар дөньясын үзгәртү, туган халкына хезмәт итү, аны азатлыкка алып чыгу, башка халыклар һәм дәүләтләр арасында лаеклы урын алу, милләтне саклау, аның телен һәм мәдәниятен үстерү.

Ш. Мәрҗани – татар тарихы фәненә нигез салучы галим дә. Аның “Мөстәфадел – әхбар фи әхвали Казан вә Болгар” исемле әсәре мисалында моны күрәбез. Аны чын татарча итеп, “Казан һәм Болгар хәлләре турында файдаланылган хәбәрләр” дип түгел, бәлки күбрәк хәбәрләрне ирештерүче мәгънәсендәге тәрҗемәче (мөтәрҗим) яки “хәбәрләрне җыючы” (җамигъел – goруф) кебек сүзләр белән атый. Хезмәт ике кисәктән торып, аның 1885 елда чыккан беренчесе Болгар һәм Казан дәүләтләренең тарихын шул чор Евразиядәге якын күршеләре (кардәшләре) фонында яктырта. Дөресрәге, ул шул киң һәм катлаулы тарихны төрле яклап яктырта торган хәбәрләр җыелмасын эченә ала. Галим гарәпчә, фарсыча, русча, татарча һәм, гомумән, төркичә чыганаклардан хәбәрләр туплап, шулар нигезендә үз халкының язмышын гәүдәләндерә. Китапның I томы – 1885, икенче томы 1900 елларда дөнья күрә. Анда халкыбызның этник тарихы, татарлар арасында мәгариф эшенең торышы, рухи мирасы, күренекле шәхесләр хакында киң мәгълүмат бирелгән. Автор халыкны алга җибәрүнең төп чарасын белем-мәгърифәттә күрә. Китапның икенче томында 130 лап татар мәдрәсәсенең эше анализлануы, мәдрәсәләрнең шактый тулы исемлеге бирелүе педагог галимнең милли педагогика фәненә керткән җитди өлеше турында ачык сөйли. Мәрҗани төп игътибарын, мәдрәсәләр эшчәнлеген яктыртуга багышлый. Бу уку йортлары-

ныйданы укыту-тәрбия эшеннән ул канәгатьләнү тапмый. Шул ук вакытта яшь буынны аң-белемле итүгә зур өлеш керткән Мәчкәрә, Курса, Кышкар, Оры мәдрәсәләрендә җитәкчелек иткән мелла Мөхәммәдрәхим ахун, мелла Габденнарсыйр әл-Курсави, мелла Сәгыйдь әл-Барыши, мелла Хәбибулла әл-Орыви һ.б. эшчәнлегенә югары бәя бирә.

1876 елның 13 сентябрендә Казанда татар яшьләреннән рус теле укытучылары хәзерләү максаты белән “Татар укытучылар мәктәбе” (КТУМ) ачыла. Галим бу мәктәпне ачу эшендә актив катнаша. (Ул хәзер педагогика көллияте, Даурская ур., 30) Патша хөкүмәте бу мәктәпне билгеле, татар халкын агарту өчен түгел, ә үзенә туры хезмәтче булырлык кешеләр әзерләү өчен ачкан. Ләкин мәктәптә Ш. Мәрҗани кебек прогрессив карашлы укытучылар эшләү сәбәпле, биредә шактый күп кенә татар халкының зыялылары укыган, тәрбияләнгән. Казан татар укытучылар мәктәбе 1917 нче елга кадәр эшли. Бу уку йортында Х. Ямашев, Гафур Колахметов, Гаяз Исхаки, Садри Максуди, Сәгыйть Сүнчәләй, Мөхетдин Корбангалиев, Гыйбад Алпаров, Гыйлем Камай, Бакый Урманче, һ.б. галимнәр, җәмәгать эшлеклеләре, халык мәгарифен оештыручылар, укытучылар укыган. КТУМның беренче инспекторлары танылган татар мәгърифәтчесе Мөхәммәтгали Мәхмүдов, уку-укыту бүлеге мөдире В.В. Радлов була. Биредә М. Ломоносов, Н. Максимов, В. Богородицкий, Н. Брюханов, М. Васильев кебек данлыклы рус галимнәре белән бергә Ш. Мәрҗани, Шаһбазгәрәй Әхмәров, Ибрагим Терегулов, Шакирҗан Таһиров, Таиб Яхин һ.б. татар халкының күренекле вәкилләре эшләгән.

Ш. Мәрҗани гаять тирән белемле шәхес була. Ул татар, төрки телләреннән тыш, гарәп, фарсы телләрен камил белгән. Үзенең күп кенә хезмәтләрен гарәпчә язган. Ул атаклы рухани һәм күренекле педагог булу өстенә зур галим дә. Аның гыйльми эшчәнлеге күп тармаклы: тарих, философия, археология, нумизматика, этнография, география, халык авыз иҗаты һ.б.

Без Болгар тарихы югалган, Алтын Урда чоры чыганаклары харап булган, Казан ханлыгы архивы юкка чыгарылган, дип уфтанабыз. Шуңа күрә Ш. Мәрҗани хезмәтләрендә тупланган тарихи материаллар татар тарихының нигезен тәшкил итәләр. Ул үзенең хезмәтләренә болгар-татар тарихына гарәп сәяхәтчеләре язмалары мәгълүматләрен күпләп кертә. Шулардан чыгып, Мәрҗани, татарның борынгы бабалары дип, болгарлар тарихы турында дөнья хал-

кы ышанырлык итеп хезмәтләр бирә, аны татар дип атауны да ачыктан-ачык яклап чыга. Ул болгар-татарчылар юнәлешенең дөрес булуын дәлилләп бирә. Ш. Мәрҗанине болгар-татар теориясенә нигез салучы буларак та өйрәнергә кирәк.

Ш. Мәрҗанинең карашларыннан үсеп чыккан мәгърифәтчелек прозасында киң чагылыш тапкан проблемалар. Г. Исхакыйның “Ике йөз елдан соң инкыйразында” нда милләтнең киләчәк язмышын билгеләүче биш сәбәп буларак алгы планга куеп тикшерелә. Бу чорда публицистик сурәтләүнең киңәюе жанрга мәрәҗәгать итүләрен, прозадагы жанрларның эчке хасиятләрен билгегәүдә нигез ташлары салынуын да билгелеп үтү кирәк.

**ӘДӘБИЯТ**


1. Мәрҗани Ш. Мөстәфадел – әхбар фи әхвали Казан вә Болгар. Казан: Татар. кит. нәшр., 1989.

2. Гафиятуллина И. Марджани – это один из столпов не только татарского народа, но и всего исламского мира // Яңарыш. 2018. № 3.


## ТАТАР ХАЛЫК АВЫЗ ИҖАТЫНДА ШҮРӘЛЕ ОБРАЗЫ


*Гыйльмиева Д., Казан, 124 нче мәктәп, X сыйныф*

*Фән. җит. – Л.Ф. Җамалиева*


Татар халык авыз иҗатындагы иң популяр обрзларның берсе – Шүрәле. Ул татар кешесенә кечкенә вакыттан таныш. Күпләр аны Г. Тукайның әдәби герое дип уйлый. Әмма бу образ Г. Тукай һәм аннан соң башка әдипләр иҗатына халыктан килгән.

Халык ышануы буенча, шүрәлеләр дөм кара урманнарда күмәкләшеп яшиләр. Кыяфәтләре белән кешене хәтерләтәләр. Әмма шүрәле гәүдәгә кешедән күпкә зур, биек. Үзенең чандыр, озын буе белән ул урман ешлыгында агачлардан әллә ни аерылмый да. Тәне күбесенчә ялангач, башы кечкенә, күзләре зур. Кайчагында кешеләрдән калган сәләмәләргә төренгән була. Шүрәле иске бүрек киеп йөрүчән. Чөнки аның маңгай турысында кечкенә генә мөгезе дә бар. Бүрек кашын төшереп, ул әнә шул мөгезен кеше күзеннән яшерергә тели. Шүрәленең кешеләрдән аермалы иң төп сыйфаты – аның кул-бармаклары гадәттән тыш озын булуы. Урман буйлап алпан-тилпән йөргәндә куллары тез очына тиеп-тиеп китә, кайчакта очлы, үткен тырнаклары җиргә тиеп бара. Урман сукмагында очраган биш сызык эзе – шүрәленең әнә шул тырнакларыннан төшеп калган эзләр [1: 66].

Аерым ышануларга буенча, шүрәле үз гомерендә берничә мәртәбә бармагын алыштырып өлгерә, ди. Урман сукмакларында

шул бармакларны табып алган кеше шатланган, чөнки шүрәле бармагы әйбәт фал булып саналган [2: 69].

Шүрәлеләрне юкка гына "Урман сарыгы" дип йөртмиләр. Алар бик тар карашлы, тар зиһенле, беркатлы затлар. Аңгырарак булмасалар, су башы эзләп диңгезгә таба чапмаслар иде. Шүрәле атлар ярата, ат өстендә көн буе, төн буе атланып йөри ала, аларны ялыктыра. Хәйлә белән, күп очракта атның аркасына сумала ябыштырып тотылган шүрәлене авыл халкы төрлечә җәзалый: кыйныйлар, яндыралар, таш белән аталар һ.б. Шүрәлене рәнҗеткән кеше яки кешеләр бер вакытта да рәхәт яшәми. Шүрәле үтерелгән авыл бөлгенлеккә төшә; бу авылны яңгырлар урап уза, анда инешелгалар кибә, балалар тумый башлый [2: 150].

Татар халык иҗатының риваятьләр һәм легендалар томында әлеге тема белән бәйләнгән "Шүрәле", "Былтыр кысты", "Шүрәле Яппар", "Шүрәле каргаган авыл" һ.б. мифологик хикәятләр урнаштырылган. Шүрәлеләрне хәйлә яисә тапкырлык белән җиңгән батыр егетләр хакында мифлар, легендалар күп. Аның иң популяры Г. Тукайның "Шүрәле" поэмасына кереп калган.

"Шүрәле" сүзенең килеп чыгышына карата берничә сүз. Борынгы төрки телдә "шөр" дигән сүз бар. Ул "явызлык", "зыян" дигән мәгънәләрне белдергән. Галимнәр, Шүрәле сүзе шушы "шәр" сүзенә "әл" сүзе һәм "ле" кушымчасы кушып ясалган, дигән фикердә торалар, "шәр-әл-ле", ягъни "явыз куллы" [1: 153].

"Шәр"нең "шәр" һәм "шүр"гә әверелүе кызык. Мәгълүм булганча, татар телендә "шүрләү" дигән сүз бар. Мәгънәсе: курку, явызлыктан курку. Монда да шул ук мәгънә сакланган. Инде кайбер әйтемнәргә игътибар итик: "Шөр җибәрү", "Шүре тунын кию" (куркып калу, посу); "шүр" кергән сүзләрнең "шыр" варианты да булуын онытмыйк: "Шыр надан", "Шыр елату", "Шыр акырып җибәрү", "Шыр сыйрак" (йөгәнсез, башбаштак), "Шыр тиле", "Шыр СӨЯК", "Шырантай агач" (ботаксыз, озын, тарыган, шәрә калган агач), "Шыр чыккан" (үтә ялганчы), "Шыр җибәрү", "Шырыйлап кычкыру" (акыру-бакыру), "Шырыйнықы шөрепле" (анықы гадәттән тыш, арттырып сөйләү) һ.б. Шулай ук "Шәр җибәрү", "Шәрәгә калу" кебек сүзтезмәләрдә дә "Шүрәле" сүзенә килеп кергән борынгы мифологема бар. "Бар чагында бүредәй, булмаганда шүредәй" дигән әйтемдә дә шул ук тамыр: "шәр" – "шүр", ягъни "куркак", "басынкы", "шүрләүчән" [1: 153].

Татар халкында “Шүрәле” әкиятенең берничә варианты бар. Мәсәлән, Каюм Насыйри үзенең “Казан татарларының ышанулары һәм ырымнары” исеме белән, рус җәмәгатьчелеген татар фольклоры һәм этнографиясе белән таныштыру өчен язган бер хезмәтендә шүрәле турындагы әкиятнең эчтәлеген түбәндәгечә бирә: “Шүрәле урманда татарны очратып кети-кети уйнарга чакыра. Татар шүрәлене алдый ала. Татар бүрәнәгә балта белән бәрә дә, бүрәнә ярылып китә. Шул ярыкка татар чөй тыгып куя. Шүрәлегә шуннан тотарга куша да, чөен алгач, аның бармагы кысылып кала. Шүрәле үз иптәшләрен чакырып, “Татарны кытыклап үтерегез” дип бик каты тавыш белән кычкырып утыра. Татар эшне элегрәк аңлап, шүрәленең “Син кем?” дип соравын “Мин Былтыр атлы” дип җавап кайтарган булганга, шүрәле: “Былтыр кысты, Былтыр кысты!” – дип кычкыра. Шүрәленең иптәшләре җыелып киләләр дә: “Былтыргыны табып булмый аны” дип көлеп китәләр имеш” [3: 56]. Халык иҗатындагы бу вакыйгалар алга таба шүрәле белән бәйле әдәби әсәрләргә дә нигез булып торалар.


**ӘДӘБИЯТ**

1. Гыйльманов Г. Шүрәле // Татар мифлары: ияләр, ышанулар, ырымнар, фаллар, им-томнар, сынамышлар, йолалар. Казан: Татар. кит. нәшр., 1996. Б. 148-153.
2. Гыйльманов Г. Шүрәле // Татар мифлары: ияләр, ышанулар, ырымнар, фаллар, им-томнар, сынамышлар, йолалар. Казан: Татар. кит. нәшр., 1999. Б. 66-72.
3. Насыйри К. Казан татарларының тормышында ислам дине йогынтысыннан тыш барлыкка килгән ышанулар һәм гореф-гадәтләр // Сайланма әсәрләр. 4 томда, Т. 3. Казан: Татар. кит. нәшр., 2005.


## ТАТАР ҺӘМ ТӨРЕК ТЕЛЛӘРЕНДӘ КИЛЕШ КАТЕГОРИЯСЕ


*Гыймадиева Г., КФУ, IV курс студенты*

*Фән. җит. – филол. фән. канд., доц. М.Р. Саттарова*


Татар һәм төрек телләре төрки телләр төркеменә керүгә карамастан, аларның уртак билгеләре булу белән бергә аермалы яклары да бар. Телләрне тасвирлауда һәр категорияне чагыштырып өйрәнү мөһим. Әлеге мәкалә татар һәм төрек теленә хас уртак һәм аермалы билгеләрне ачыклау максатыннан килеш категориясен чагыштырма тасвирлауга багышлана. Килеш категориясе/Adım (ismin) durum eklerini alması=Ad (isim) çekimi [1: 73-84].

*Килеш* – исемнәрне башка сүзләр белән бәйләп, аларны үзара төрле синтаксик мөнәсәбәткә куя торган грамматик категория. Татар телендә 6, ә төрек телендә 8 килеш бар [2: 167].

Исемнең кушымчасыз формалары Yalın hâl, баш килешкә карый. Бу килеш – татар телендә дә, төрек телендә дә күп фунцияле

килешләрнең берсе. Баш килештәге исем җөмләдә ия булып килә: *Дөнья яшеллеккә күмелгән / Timsah karada hızlı gidemez.* Баш килештәге исем җөмләнең хәбәре дә була ала: *Bu nasıl yazı? Kargacık-burgacık.* Бу функциясе татар теле белән чагыштырганда төрек телендә беркадәр таррак. Татар телендә, баш килештәге исем хәбәр күбесенчә бернинди кушымча да алмый: *Мин рәссам.*

Төрек телендә исә, ия беренче һәм икенче затларны аңлатса, исем хәбәрдә һәрвакыт хәбәрлек кушымчасы була [3: 30-42]: *Ben öğretmenim.* Бары тик өченче зат белән бәйле булганда гына, кайбер вакыт хәбәрлек кушымчасы кыскара ала. Бу очрак мәкаль һәм әйтемнәрдә күзәтелә: *Bey aşı borç, düğün aşı* ***ödünç***. Татар телендә дә, төрек телендә дә баш килештәге исем бәйлекләр белән кулланыла: *Dağlar kadar işim var. / Дуслар белән очрашу.* Шулай ук баш килештәге исем эндәш сүз дә булып килә: *Әби, атны бераз ял иттерик. / Yasemin, çiçeklerine nasıl baktığını bana da anlatır mısın?*

Иялек килешенең (İlgi hâli) татар телендә кушымчалары – *ның/-нең,* ә төрек телендә кушымчалар *–ın (-in, -un, -ün), -nın (-nin, -nun, -nün).* Төрек телендә иялек килешендәге исем җөмләдә исем яки сыйфат фигыльгә бәйләнеп килсә, бу очракларда процессның субъектка мөнәсәбәтен белдерә: *Hasan'ın gelmesin beklemedi.* Татар телендә иялек килешендәге исемнең кайбер фигыль формаларын ачыклап килүләре күзәтелә, бу очракта исем затны яисә нинди дә булса хәлне кичерә торган предметны белдерә һәм җөмләдә тәмамлык булып килә: *Мотаһирның бу ихатага инде бик күптәннән аяк басканы юк (Р. Кәрами).*

Күп кенә очракта, җөмләләр татар теленә иялек килеше белән тәрҗемә ителә алмый: *Herkes* ***çoçuğun*** *göterdiği yere baktı – Бөтенесе дә* ***бала*** *күрсәткән урынга карадылар.* Мисалда күренгәнчә, төрек телендә иялек килешендә торган исем татар телендә баш килеш белән тәрҗемә ителә һәм үзе бәйләнгән сыйфат фигыль белән бергә иярчен җөмлә барлыкка китерә.

Юнәлеш килешнең татар телендә кушымчалары *–га/-гә, -ка/кә,* ә I һәм II зат тартымлы исемнәргә *–а/-ә,* III зат тартымлы исемнәргә –на/-нә кушымчалары ялганып формалаша: *бакча-га, бакчасы-на* һ.б. Төрек телендә Yönelme hâli, ягъни юнәлеш килешендәге исем *–e/-a* кушымчалары ала [3: 30-42]. Әгәр сүз тартык авазга бетсә, *-e/-a* кушымчасы турыдан-туры ялгана: *okul-a, otobьs-e, зау-а.* Әгәр исем сузык авазга тәмамланса, нигез һәм кушымча арасына тоташтыру авазы [y] өстәлә: hasta-y-a, bahçe-y-e.

Нәкъ татар телендәге кебек, төрек телендә дә юнәлеш килеш кушымчасы исемне күбесенчә фигыльгә бәйли: *Çiftliğ**e** nereden gidilecek?(Уртага каян барырга?). Эчкә кереп, залга киттеләр.* Татар телендә *таба, хәтле, каршы, кадәр* һ.б. бәйлекләр килә ала: *Ул кискен адымнар белән ишеккә таба китте (*А. Расих). Төрек теленә килсәк *kadar, göre, doğru, rağmen, karşılık, dek, dair, ait* бәйлекләре килә. Мәсәлән: *Sabaha kadar oturdu. Sabaha dek uyumadık* һ.б. Кайбер фигыльләр белән килгәндә, төрек телендәге юнәлеш килеше татар теленә тәрҗемә иткәндә юнәлеш килешендә калмый: *O çalışmalarına aralıksız devam ediyordu. – Ул эшен туктаусыз дәвам итте* [1: 73-84]. Шулай ук, тәрҗемә иткәндә, башка мәгънәдәш сүз белән алыштырырга мөмкин: *Buğün **işe** başladım. – Бүген **эшкә** керештем.*

Татар телендәге төшем килеше *–ны/-не,* III зат тартым кушымчалы исемнәргә *–ын/-ен/-н* кушымчасы ялгана. Төрек телендәге төшем килеше Yükleme hâli кушымчасының сузыклар гармониясенә бәйле рәвештә берничә варианты бар: -ı/-i, -u/-ü. Сүз сузыкка бетсә, кушымча алдына тоташтыру авазы өстәлә*: sofrayı, nineyi.* Төшем килешенең төрек теле грамматикаларында, дәреслекләрендә берничә исеме очрый: kimi hali, etkilenme hali, belirtme durumu, yapma hali һ.б. Төшем килешендәге исем ике телдә дә эш-хәлнең туры объектын билгесезлек төсмере белән дә белдерә, әмма бу вакытта ул кушымча алмаска мөмкин: *Küçük çantama hiç kitap koyman. / Мин кич өй эше эшлим.*

Чыгыш килеше, татар телендә *–дан/-дән, -тан/-тән, -нан/-нән,* III зат тартымлы исемнең кушымчасы *–ннан/,-ннән* кушымчалары ярдәмендә формалаша. Төрек телендә *ayrılma hâli, çıkma hâli* дип тә йөртелә. Кушымчалары *–dan/-den, -tan/-ten.* Чыгыш килешендәге исем, җөмләдә эш-хәлнең урынын, вакыт, сәбәп, күләм хәле дә булып килә, бу ике телдә дә шулай. Мәсәлән: *Шәһәр**дән** килгән яшьләр учак янына җыйналдылар. / Ben okul**dan** geliyorum. Мин куанычым**нан** ягымлы тавыш белән дәштем. / Bebek gьrьltь**den** uyandı.* Бәйлекләр белән дә кулланылырга мөмкин: *Ике җырдан соң тагы икене җырлады. / Sabahtan beri yağmıştı.*

Урын-вакыт килешенә килсәк, татар телендә –да/-дә, -та/-тә, III зат тартымлы исемнәрдә *–нда/-ндә.* Төрек телендә урын-вакыт килеше берничә исем белән йөртелә: *bulunma hвli, kimde hali, kalma hali* һ.б. Урын-вакыт килешендәге исем *–de/-da, -te/-ta* кушымчалары ала. Урын вакыт килешендәге исем, төрек телендә

нәкъ татар телендәге кебек үк эш-хәрәкәтнең үтәлү вакытын белдерә: *Якупның яз башын**да** урман**да** булганы юк иде. / Yağmur mevsimin**de** dağlardan şiddetli seller akıyor.* Күбесенчә төрек телендәге бу килеш, мәгънәви яктан, татар телендәге кебек кушымча алмый. Бу тәрҗемә иткәндә күренә. Мәсәлән: *Dedem otuzunda askerden dцптьє – Минем бабай армиядән утыз яшендә кайткан. Misafirleri ayak**ta** karşıladı. – Басып каршы алды.*

Шулай ук төрек телендә *vasıta hâli* бар, ул ***ile*** бәйлеге белән уртак эш, корал яки предмет белән бергә эшләнә торган хәрәкәтне күрсәтә, ул кушылып та, аерым да килә ала. Мәсәлән: *Araba**yla** gideceğiz. / Без машина белән барабыз.* Тагын берсе *eşitlik hâli*, образга охшашлык, бәйлелек хәрәкәтен белдерә һәм *–ca/-ce, -ça/-çe* кушымчаларын алалар. Мәсәлән: *Зocuk**за** (çocuk gibi) davranışlar yapıyorsun. / Син үзеңне бала-чага кебек тотасың.*

Нәтиҗә ясап әйткәндә, татар һәм төрек телләренең грамматикасында уртак яклар шактый. Шул ук вакытта аермалар да күренә, бу килешләрнең төрек телендә башка мәгънәдә кулланылуы, ә тәрҗемә иткәндә татар телендә башка килеш формасын алуында чагыла.

**ӘДӘБИЯТ**


1. Гениш Э. Грамматика турецкого языка. I том. Москва: ЛКИ, 2007. С. 73-84.
2. Татар грамматикасы / Н.Б. Борһанова, Ф.А. Ганиев, М.З. Зәкиев һ.б. II том. М.: Инсан, Казан: Фикер, 2002. 448 б.
3. Төrek grammatikası / Türk dilbilgisi. Төrkiyә: Qazan, 2002. Б. 30-42.


## ОСНОВНЫЕ СХОДСТВА И РАЗЛИЧИЯ МЕСТОИМЕНИЙ В РУССКОМ, ТАТАРСКОМ И АНГЛИЙСКОМ ЯЗЫКАХ


*Давтян К., Спасский р-н, Болгарская СОШ №1, X класс*
*Рук. – М.Е. Курзаева, Р.Г. Хабибуллина*


Местоимение – это часть речи, которая непосредственно не называет предметы и их признаки, а лишь указывает на них. Местоимения не имеют собственных морфологических признаков. Они заимствуют эти признаки у тех частей речи, с которыми соотносятся в процессе речи. Определим основные сходства и различия местоимений в русском, татарском и английском языках.

Личные местоимения ты, вы в русском языке и местоимения *син, сез* в татарском и английском выражены одним лишь местоимением *you* , то есть в этом заключается сходство русского и татарского языков и отличие их от местоимений в английском языке. Следует также отметить, что местоимение третьего лица единственного числа ул в татарском языке не имеет категории рода. Что

же касается русского и английского языков, то здесь местоимению ул соответствуют местоимения он, она, оно в русском языке, и he, she, It – в английском. Причём местоимение it в английском употребляется в отношении к животным, а he, she – только при особом к ним отношении. А в русском языке в этом плане употребляются и он, она. Например:у меня есть кошка. Она очень красивая. Минем песием бар. Ул бик матур. I have got a cat. It is very beautiful. Марат учится в 10 классе. Он – старательный ученик. Марат 10 нчы сыйныфта укый.Ул – тырыш укучы. Marat studies in the tenth form. He is a diligent pupil. Мама купила мне платье. Оно очень красивое. Әни миңа күлмәк сатып алды.Ул бик матур. My mother bought me a dress. It is very beautiful.

Вопросительные местоимения в английском языке with и what не имеют категории числа. Они соответствуют в русском языке местоимениям какой, который и могут переводиться как какой, какие и который, которые (например: what questions – какой вопрос,what books – какие книги, which student – который студент, which books – которые книги). Что же касается местоимения кайсы в татарском языке, здесь дело обстоит, как и с местоимениями which и what в английском языке, если после местоимения нет существительного, а если оно присутствует – то, как в русском (например: кайсы апа, кайсы студентлар, кайсы, кайсылары).

Возвратные местоимения также представляют различие между русским и английским языками. Дело в том, что возвратность в русском языке может выражаться двояко: с помощью возвратного глагола и возвратного местоимения (Он умывается. Он моет себя). А в английском языке – только одним способом: с помощью возвратного местоимения (he washed himself). Причём в русском языке возвратное местоимение себя является единственным в этом разряде, а в английском их несколько. Они употребляются в зависимости от местоимения личного (He – himself, she – herself, they – themselves и т.д). Что же касается татарского языка , то здесь такие же, как и в английском языке. Значит, возвратные местоимения представляют различие между английским и русским языками, и сходство между английским и татарским языками (Ул үзе юына).

Местоимению каждый соответствует английские every или each и татарское һәрбер. Местоимения every и each, однако, имеют некоторые различия в случаях употребления. Местоимение every

В настоящее время вопрос о содержании понятия «реалия» в теории и практике перевода стоит довольно остро. Помимо лакун, отечественные и зарубежные ученые, изучающие проблему реалий, дают различные определения реалиям, отмечают одни признаки этих лексических единиц и опускают другие, используют неодинаковые термины для их обозначения, такие как «безэквивалентная лексика», «варваризмы» [8: 141], «экзотизмы» [1: 222], «локализмы» [1: 222], «этнографизмы» [10: 41], «ксенизмы» [12: 260] и некоторые другие. Отсутствие точного или приблизительно единого определения термина «реалия», употребляемой лингвистами, учеными, переводчиками в отношении этого понятия до сих все еще требует четкого выяснения содержания реалии как переводческого термина и его разграничения от других единиц языка.

Таким образом, исследователи в области теории и практики перевода сталкиваются с проблемой реалий, связанной, в первую очередь, с поиском наиболее адекватных приемов и способов передачи реалий, характерных для одной лингвокультурной общности, средствами другого языка, с учетом максимального сохранения национальной и исторической окраски как отдельного факта, так и всего текста – подлинника в целом.

**ЛИТЕРАТУРА**

1. Ахманова О.С. Словарь лингвистических терминов. М., 1968. 608 с.
2. Верещагин Е.М., Костомаров В.Г. Язык и культура. М., 1980. 320 с.

3. Vinay J. P., Darbelnet J. Stylistique comparée du français et de l`anglais. Paris: Didier, 1958. 145 p.

4. Ермагамбетова А.С. Классификация слов-реалий и способы их перевода (на материале перевода романа-эпопеи «Путь Абая» на английский язык) // Иностранные языки. Вып.6. Алма-Ата, 1971. С. 91-108.

5. Жакупов Ж.А. Аудармотануды аңдату. Алматы, 2004. 245 с.

6. Муравьев В.Л. Проблемы возникновения этнографических лакун. – Владимир: ВГПИ, 1980. 106 с.

7. Ревзин И.И., Розенцвейг В.Ю. Основы общего и машинного перевода. М.: Высшая школа, 1964. 243 с.

8. Реформатский А.А. Введение в языковедение. М., 1996. 536 с.

9. Соболев Л.Н. О переводе образа образом. М., 1955. 309 с.

10. Томахин Г.Д. Реалии – американизмы. Пособие по страноведению. М.: Высшая школа, 1988. 234 с.

11. Швейцер А.Д. Теория перевода. Статус, проблемы, аспекты. М.: Наука, 1988. 253 с.

12. Ярцева В.Н. Языкознание. Большой энциклопедический словарь. М.: Большая Российская энциклопедия, 1998. 685 с.

## М.ҚАШҒАРИДІҢ «ДИУАНИ ЛҰҒАТ АТ-ТҮРІК» ЕҢБЕГІНДЕГІ МАҚАЛ-МӘТЕЛДЕР

*Ермағамбетова А., Ақтөбе өңірлік мемлекеттік университеті, филология факультеті, І курс студенты*

*Ғыл. жет. – Г.С. Обаева*

Мақал-мәтел – бейнелі сөз, халық даналығы. Әр халықтың мақалы мен мәтелі – сол халықтың өзі жасап алған логикалық формуласы, анықтамасы. Ол кез келген уақиғаның, мәселенің тұсында еске түседі, тілге оралады. Көп ойлануды, ұзақ баяндауды керек ететін қиын нәрсені оп-оңай, бір-ақ ауыз сөзбен ұғындыра алады. Мақал-мәтел – поэтикалық жанр. Ол әдетте белгілі бір ойды, пікірді ажарлап айқындау, қорыту үшін қолданылады. Бұл жағынан алғанда ол – сөздің қатығы, қаймағы дерлік.

XI ғасырда өмір сүрген аса дарынды түркі перзенттерінің бірі М. Қашқари сонша жерді кең жайлап, еркін мекендеген түркі тайпалары мен көрші елдердің ауыл-мекендеріне, шаһар-кенттеріне, дала-жайларына барып тілдерін зерттеген, мақал-мәтелдері мен өткір сөздерін, уытты орамдарын, қанатты да қалыпты айтылатын сөз иіндерін т.б. да қыруар тіл байлығын жинаған [1: 61]. Махмұд Қашқаридың «Диуани лұғат ит – түрік» еңбегінде қамтылған мақал-мәтелдердің бүгінгі қазақ әдебиетіне қаншалықты етене жақын екенін аңғару қиын емес. Профессор Б. Кенжебаевтың жазуынша «Сөздікте» 270 шақты мақал-мәтел

келтірілгендігін айтады. Солардың ішіндегі 60 мақал-мәтел қазіргі қазақ әдебиетінде ешбір өзгеріссіз сол қалпында қолданылады. Ондағы мақал-мәтелдерден орта ғасыр көшпенділері мен тұрғын халықтарының сана – сезім тұрғысы, дүниетанымдары, ой-түйіндері, салт-сана, кәсіп-тәсілдері танылады. «Диуан» сөздері ақыл-нақылдар, мақал-мәтелдерді тізбектеп, жоғары адамгершіліктің қағидаларын жасайды. Адамның басқадан айырмашылығы оның бойындағы ең ізгі қасиеттерінде, білімінде, әділдігінде, ізгілігінде деп түйеді [2: 25].

Дүниеқоңыздыққа салынып, ішпей-жемей, бермей-кимей жиған мал-мүліктің еш қайырымы жоқ деп «Диуан» авторы қасиетсіз адамдардың, қайырымсыз жандардың тоғышар мінездеріне лағнет айтады. Жастарға ақыл айтып, жат мінезден сақтандырады. М. Қашқари ақылды, мінезді адамдарды бір сөзбен «жақсы», ал ақылсыз, мінезсіз адамдарды «жаман» деп атайды. Жақсылықтың белгілері: адалдық, қайырымдылық, арлылық, әдептілік, сыпайылық, талаптылық. Жамандықтың көріністері: арамдық, мейірімсіздік, арсыздық, әдепсіздік, тұрпайылық, талапсыздық. Бұған «Жақсы адамның сүйегі қурағанмен, аты қалар» мақалын келтіруге болады. «Жаз еңбек етсең, қыс қуанарсың», «Егін айдаудағы бірлік астық орғанда бұзылмас», «Күз болары көктемнен мәлім» деген мақалдардан сол кездегі халықтың егіншілік кәсібі, соған сай сөз саптаулары байқалады. Ғалым «Әдептің басы – тіл» – деп тіл өнерін қол өнерінен де, ерліктен де жоғары қойған. Тіл – ақылдың көрінісі. Тілсіз жерде бірлік те жоқ, тірлік те жоқ деп дәріптеген. Жамандықтың бір белгісі – күншілдік, іштарлық. «Күндестердің күлі де – күндес». Ондай жандар, әдетте, өзінен басқаның бәрін күндейді, жақтырмайды, жаратпайды. Өзінен өзгенің жақсы ісіне, сөзіне, табысына сүйсінбейді, қуанбайды, керісінше, күйінішпен, қызғанышпен қарайды, қалайда біреуді кемітіп, мұқатуды өзіне дәреже көреді, ең болмаса сыртыңнан жамандап, даттап жүреді.

Мақал-мәтелдердің бірсыпырасы жақсы адам, парасатты азамат боламын деген талапкерді қашанда халқымен, қауыммен бірге болуға, өмірдің қызығын да, қиындығын да елімен, халқымен бірге көруге шақырады. «Жалғыз қаздың үні шықпас» дейтін мақалдың мәнісі адамды ұйымшылдыққа, бірлікке шақырады. «Еңбек етсең – емерсің», «Тас бас жарар, еңбек тас жарар», «Екпейінше – өнбес, талпынбайынша – жетпес» мақалдары елді

еңбекқорлыққа үндесе, «Жалқауға бұлт та жүк боп көрінер», «Жалқауға бұлт саясы да тимейді» деп жалқаулықтан жирендіреді.Адамның тағы бір қасиеті – мінез. «От – түтінсіз болмас, жігіт – мінсіз болмас», «Тәкаппар тақсірет тарттырады», – дейді ғалым.

М. Қашқари ата-ананы дәріптеп, жоғары бағалауға, ағайын-туғанмен тату болуға байланысты да көптеген мақалдар келтірген. Мысалы: «Атаның ұлы – атасына тартып туар», «Ұран көтерілсе – ру жиылар, жау келсе – жамағат жиылар», ««Ағайын» десе – шақ қарадық. Қиын-қыстау шақтарда халықты шыдамдылыққа, сабырлылыққа шақырып «Ауыр күн де өтеді, оған сабыр, шыдам қыл» деп тоқтам айтқан.

Ғұлама мақал-мәтелдерін жазуда басқа да көптеген (үрей туралы, байлық, кедейлік туралы, сараңдық, дәрменсіздік, дос туралы жоқтық туралы, ғылым, өсиет, тағлым туралы) тақырыптарға тоқталған. Олардың әрқайсысынан тек ақыл сөз, өсиет қана емес, орта ғасырдың терең ой-түйіндерін де байқауға болады. *Асау өзен өткелсіз болмас.* Бұл мақал бір істің шешімін, түйінін таба алмай, қиналып тұрған адамға «Мұның да түйіні табылып қалар» деп ақыл ретінде айтылады. *Ақымақ адам ес – жисын, елде әділ заң толыссын,Қозы мен бөрі бірге жүрсін, қайға кетсін.* Мақалдың мәні: қылышымызбен жақсы жол ашалық, ессіздерге ес кірсін, елдің дәстүр-заңы түзелсін, тоқтылар мен бөрілер қатар жүріп тіршілік етсін, қайғы-мұң бізден сабылып алыс кетсін, жоламасын, яғни ел арасында тыныштық болсын дегенді уағыздайды. *Ауыз жесе көз ұялар.* Бұл мақал біреудің затын сатып алған, яки жеген, бірақ оны қайтара алмай қиналған адамдарға арнап айтылады. *Адам аман болса, өмірден көр көрер, (Есен болса жаның – көрерің көп).* Бұл мақал адамның жаны аман болса, алдында көрері көп деп насихаттайды. *Іштік болса, ат жауыр болмас.*Бұл мақал әрбір істің алдында ала жай-жапсарын жан-жақты ойластырып алуға шақырып айтылады [3: 170-186]. Жоғарыда айтылып өткен М. Қашқари мақал-мәтелдерінің бүгінгі қазақ әдебиетіне қаншалықты етене жақын екенін аңғару қиын емес. Онда үй ішінің мүшелерінен бастап, ағайын туыс, достық, сыйластық, еңбекқорлық, ақыл-білім тақырыптары қамтылған. Қоғамға, адамгершілікке жат, ерсі мінез-қылықтар, жарлы мен жалғызға жасаған қиянат зұлымдықтар әшкереленіп сыналған. Бұл

мақал-мәтелдердің адамзат тәрбиесіне, өсіп-өркендеуіне зор ықпал ететіні анық.

Қорыта айтқанда, Махмұд Қашғаридің теңдесі жоқ бұл шығармасы біздің еліміздегі түркі тілдес халықтардың бәріне бірдей ортақ асыл қазына, тілдік, әдеби, тарихи, этнографиялық тұрғыдан қарастырғанда ұрпақтан ұрпаққа жеткен бай мұра. Халықтың қанатты сөздер мен мақал-мәтелдері орынды қолдана білген ғұлама шығармасының құндылығы да, оның кейбір сөз нұсқаларының қазіргі уақытта да өзгеріссіз қолданылуында. Ел билігі мен әкімдік, әділдік пен адалдық, парасат пен қайырымдылық, заң мен адамгершілік туралы айтылған өсиеттердің көкірегі ояу ұрпаққа берер ғибраты мол.

**ӘДЕБИЕТ**

1. Қыраубаева А. Ежелгі дәуір әдебиеті. Алматы, Ана тілі, 1992. 245 с.
2. Көшірбаева Ә.Н. Әлемдік педагогикалық ой-сана. Алматы:«Таймас» баспасөз, 2009. 451 с.
3. Қашқари М. Диуани лұғат ит-түрік. Алматы, 2006. 864 б.

## «АЙМАН-ШОЛПАН» ЖЫРЫНДАҒЫ ЭТНОГРАФИЯЛЫҚ ДЕРЕКТЕРДІҢ ҰЛТТЫҚ ТӘРБИЕДЕГІ МАҢЫЗЫ

*Жұмабекова Ж., Ақтөбе өңірлік мемлекеттік университеті,*
*І курс студенты*
*Ғыл. жет. – Г.С. Обаева*

Ұлы бабамыз Әбу Насыр әл-Фараби: «Адамға біліммен қатар, тәрбие берілуі керек, тәрбиесіз берілген білім – адамзаттың хас жауы» [1: 6], – деген екен. Ұрпақ тәрбиесінде ежелден қалыптасқан халқымыздың жақсы дәстүрлерін оқып үйрену, өнеге тұту, жас ұрпақты ізгілікке баулу үлкен жауапкершілікті талап етеді. Ұлттық тәрбие құндылықтарын қалыптастырудың бірден бір жолы – ұлттық фольклор, яғни халық ауыз әдебиеті мұраларын баланың кішкентай кезінен құлағына сіңісті етіп, бойына сіңіру. Халық фольклорының әрбір туындысында халықтың өзіне ғана тән тәрбие көздерін тануға болады. Қазақ фольклоры – тілінің бейнелілігімен, мәнділігімен, мазмұндық өткірлілігімен аса құнды қазына. «Алпамыс», «Қобыланды», «Қамбар батыр», «Ер Тарғын», «Ер Қосай», «Ер Сайын», «Кенесары-Наурызбай», «Қыз Жібек», «Қозы Көрпеш-Баян сұлу», «Айман-Шолпан» т.б. – қазақтың халық ауыз әдебиетінің жауһарлары рухани тазалықты, адамгершілікті, махаббатты дәріптейтін, ұрпаққа үлгі ететін ұлттың асыл мұрасы. Бұл жырлардағы кейіпкерлердің іс-әрекеті жас ұрақтың еліктеп,

өзіне үлгі тұтып өсуіне болатындығын, елін, жерін қалай шексіз сүю керектігін үйрететіндігі сөзсіз.

«Бақыт іздеп, ғасырлар бойына сахараны шарлап шарқ ұрған мұңдар жолаушы – қазақ халқы бізге архитектура мен скульптураның, сурет өнерінің ескерткіштерін қалдыра алмады. Бірақ ол бізге ең асыл мұра – жыр мұрасын мирас етті» деген екен ғұлама ғалым М. Әуезов [2: 3]. Көшпелі халықтардың тарихына арналған очерктері мен зерттеулерінде Шоқан Уәлиханов ауызша туған жырларды бүгінгі ұрпаққа өзгеріссіз жеткізген ақындардың құйма құлақ қасиеттерін терең талдаған. Шынында да, қазақ халқының бойына біткен ерекше дарын, бізге жеткен ауыз әдебиеті мұраларының молдығы кімді болсын таңдандырмай қоймайды.

XIX ғасырдың алғашқы жартысындағы қазақ елінің әлеуметтік-қоғамдық тіршілігін, тұрмыс- салтын қамтитын, халық арасына кең тараған, оқиғасы реалистік өмірден алынған қазақтың лиро- эпостық жырларының бірі – «Айман – Шолпан» жыры. Жыр Маманның екі қызын әуелі сұлулық, бақыт, салтанат құшағында көрсетеді де, кейін екеуін тұтқынға түсіріп, теңсіздікке ұшыратады. Бұл шендестіру Маман мен Көтібардың бақ салтанатын мақтай келіп, олардың өте ұсақ, халықтық мінезге жат адамдар екенін, феодалдық зорлық бар жерде қазақ қызының бағы жанбайтындығын көрсетеді. Жырдағы Шолпан мен Арыстанның махаббаты екі елді бітістіруге себеп болады. Ал, жырдағы Айман – өте ақылды, сирек кездесетін би қызының үлгісі. Айманның махаббаты романтикалық-трагедиялық сарында емес, прозалық-реалистік арнада баяндалған. Өз басының мүддесіне келгенде, ол – бас бостандығын іздеген, үлкен махаббат иесі болған образ.

«Айман-Шолпан» жыры қазақ фольклорының бағалы қазынасы, қазақ этнографиясының сүбелі шығармаларының бірі бола отырып, өзінің бойына халық тілінің өз кезеңіндегі мол қазынасын, танымын, психологиялық иірімдері мен жалпы ұлт, ұлт мәдениеті мен этнографиясы, тілі дамуының біртұтас кешенін жинақтаған құнды дерек болып саналады. Мәселен, ас беру, сауын айту, сауға беру, бәйгеге тігілген жамбы, бата алу, ант ішу, ашамай, жарғақ, өкіл ата, қалың мал, нақ сүйер, құдайы беру, байғазы, азамат, көрісу, жайдақ нарға мінгізу, қол алысу, жесір, мал (дүние-мүлік), саба, піспек және т.б. Жырдың басталуының өзі ас берумен басталады. Қазақ халқында өлімді шамасы келгенше туған-туыс, ауыл-аймақ болып аса құрметпен шығарып салатын дәстүр күні

бүгінге дейін жалғасып келеді. «Ас беру ислам дінінің шариғатымен байланысты қалыптасқан әдет емес», – деп жазады Х.А. Арғынбаев [3: 68]. «Айман – Шолпан» жырында шығыс халықтарының арасында, әсіресе қазақтарда кеңінен таралған – бата алу дәстүрі кездеседі. Мысалы: «..Айман қыз елден сөйтіп алды бата,// Ісінде болмаған соң зәре қате».

Бата араб сөзі – қазақша екі мағына береді: алғыс айту, ақ ниет, жақсы тілек білдіру (оң бата); діни ұғымда мұсылмандардың намазда т.б. діни жораларда оқитын дұғасы. Мұнда бата алу айтарлықтай ізгі іс жасағанда көпшіліктің беретін жақсы тілектері мағынасында қолданылған. Сонымен қатар халық арасында бата алған адам «көгеріп, өніп-өседі» деген де сенім қалыптасқан. «Жауынмен жер көгереді, батамен ел көгереді» мақалы осыдан туындаса керек. Жырдың басынан бастап шиеленіскен оқиға желісін ақылдылығымен, тапқырлығымен шеше білген Айман қыз көпшіліктің батасын алып, соңында бәрі құда болып, бір-біріне құрмет көрсетіп, сый-сыяпат, киіт кигізгенін мына тармақтардан көруге болады «Көтібар сонша жанға киіт берді». Жыр бойында қазақтың өміріне тән салт-дәстүріміздің өзге де белгілері айқын байқалады. Мәселен: «Атакеңе бар дағы байғазы де, //Алып келіп жүрмеңіз жек көргенін» немесе «Келеді Айман сұлу сүйіншіге, // Береміз Теңге тоқал сені» дейді. *Байғазы, сүйінші* деген сөздердің мағынасы қазақ халқы үшін өте терең. Бұл салт- дәстүріміз әлі күнге дейін жалғасын тауып келеді деп айтуға болады.

Этнография тұрғысынан жырдағы салт-дәстүр, халықтың нанымы мен сенімі, көзқарасы, өзіндік өмір сүру ерекшелігі айрықша нақтылықпен берілген. Қолданыстағы сөздердің, сөз тіркесінің алымы қазақы тілдің табиғатын, сөз жасау, сөз қолдану шеберлігін, ұлт танымындағы, түсінігіндегі ұғымдарды бейнелей алған сөз қолданысын байқата түседі. Қазақтың танымымен байланысты тіршілік дәстүрін бейнелеудегі жырдың тіліндегі ерекшеліктер ұлт құндылығын дәріптей алғандығымен де, ұлт санасына сіңіретін жыр ретінде қалыптаса алғандығымен де маңызды. «Айман – Шолпан» жыры осындай бай тілімен де құнды шығармаларымыздың бірі болып табылады. Қорыта айтқанда, «Айман-Шолпан» жырындағы этнографиялық салт-дәстүр деректері де жас ұрпақтың бойында ұлттық тәрбиені сіңірудің құралы бола алады деп ойлаймыз. Ұлттық жадымызды жаңғыртуда,

көне танымдық түсініктерімізді жаңғырту – ұлт құндылығын дәріптеуде тамаша негіз.

**ӘДЕБИЕТ**

1. Әл-Фараби. Философиялық трактаттар. Алматы, 1973. 245 с.
2. Әуезов М. Әдебиет тарихы. Алматы, 1991. 251 б.
3. Арғынбаев Х.А. Қазақ халқындағы семья мен неке (тарихи этнографиялық шолу). Алматы: Ғылым, 1973. 451 б.

## МИЛЛИ АСЫЛЫБЫЗ – ТУГАН ТЕЛДӘ

*Заһидуллин Р., Илеш р-ны, Карабаш урта мәктәбе, X сыйныф*
*Җит. – А.Ф. Мөсәлләмова*

Һәр халык үзенә генә хас рухи байлыгы, милли гореф-гадәтләре белән үзенчәлекле. Татарлар дөнья буйлап сибелгән. Ут күршебез Татарстанда аның бары 25 проценты гына яши икән,калганы читтә гомер итә. Шуңа карамастан, татар татар булып калырга тырыша. Чөнки безнең телебез, динебез, тарихыбыз уртак.

Мин – татар егете. Башкортстанның Илеш районында урнашкан, зур булмаган Иштирәк авылында яшим. Буш вакытларда гәзит-журналлар укырга яратам. Әнием укытучы булгач, без аларны күпләп алдырабыз.

Аларны бергә туплап, җыеп барабыз. Татарстанда чыга торган “Без – бергә” гәзитенең элегрәк килгән бер санында (№2, (045) 2015 ел) Татарстанның халык артисты, якташыбыз Салават Фәтхетдиновның бер фикеренә тап булдым. Ул болай дигән: “Гаиләдә булмаган тәртипне илдән сорап булмый. Өч балам бар. Берсе урысча сөйләшә, берсе – инглизчә... Татарча рәхәтләнеп сөйләшеп булмый. Өйдә булмаган мөхитне мин ничек халыкка: “Шулай булыгыз!” – дип әйтә алыйм?”

Нәкъ күңелендәгесен ачып салган, бик күпләребезне борчыган туган телебезне саклау мәсьәләсенең никадәр аянычлы хәлдә булуын үз гаиләсе мисалында аңлаткан.

Мин укыган Карабаш урта мәктәбендә төрле фәннәр рус телендә укытыла. Шулар белән беррәттән татар телен өйрәнү мөмкинчелеге дә бар. Бездә бары ике сыйныф кына башкорт төркеменә бүленә,калган сыйныфлар барысы да татар телен укый. Ә башкорт телен без дәүләт теле буларак өйрәнәбез. Кайбер кешеләр татар теле авылдан чыгып киткәч кирәкми, диләр. Мин моның белән һич килешмим.

Башкортстанның халык шагыйре Ә. Атнабаев турындагы бер истәлектә аның урамда үз оныгы белән татар телендә

сөйләшкәнен ишеткән бер ханым болай дип сорый: “Оныгыгыз каян бу кадәр татарча матур итеп сөйләшә?” Бу сорауга ул: “Кызым, шигырь укыгыз, шигырь ятлагыз”, – дип җавап кайтара.

Бөек шагыйрьнең шул сүзләрен мин үзем өчен васыять итеп кабул иттем. Һәм шуннан бирле мин шигърияткә гашыйк: шигырьләр укыйм,аларны бөтен ихласлыгымны салып, рәхәтләнеп ятлыйм. Шул мизгелләрдә күңелем күтәрелә,җаным җырлый.Чөнки мин үз телемдә – татар телендә сөйлим. Уңышларым да юк түгел.

Районда үткәрелгән “Тукай моңнары”, “Җиңүле яз”, якташ шагыйрьләребез Р. Миңнуллин, Р. Хәйри иҗатына багышланган сәнгатьле уку бәйгеләрендә призлы урыннар яуладым.Быелгы уку елында Уфада уздырылган яшь чәчәннәрнең “Урал батыр” исемендәге VIII Халыкара конкурсында 1 нче урынга лаек булдым. Бу чарада башкорт халкының тарихи эпосы 42 телдә яңгырады. Туган телемнең бер телдән дә ким түгеллеген үз күзләрем белән күреп,татар булуыма горурланып, канатланып кайттым.

Дөньяның җиде могҗизасы турында борынгы заманнардан бирле сөйлиләр. Әлбәттә, алар җидәү генә түгел. Ләкин ул могҗизаларның иң беренчесе итеп мин туган телемне саныйм. Туган телен югалткан кеше өчен бу дөньяның бөтен могҗизалары да бетә, күңелендәге хәзинәләр урынына бушлык кына торып кала.

Халыкны, бигрәк тә яшьләрне битарафлыкта гаепләсәк тә, теге яки бу күренешкә,проблемага күңеле әрнемәгән, борчылмаган кеше юктыр ул.

Бүген мине телебезнең,милләтебезнең киләчәге борчый.

“Гаеплене күрәсең килсә,көзгегә кара”, – дигән халык әйтеме бар. Үзебез татарча сөйләшә белсәк тә,бер кеше янында (русча сөйләшүче янында) кинәт кенә башка телгә күчәбез. Безнең авылда да балаларын аңлы рәвештә урыс итеп үстергәннәр бар. Әле күптән түгел күрше урамда яшәүче яшь гаиләнең беренче сабыйлары – кызлары дөньяга килде. Әтисе аңа, үсеп, шәһәргә киткәч, кыенсынып, оялып йөрмәсен дип, чит исем кушты. Искиткеч бит – ике татардан марҗа кызы туды! Үкенечкә каршы, бик күпләр хәзер шулай эшли, балаларын кечкенәдән русча сөйләштереп үстерә һәм мондый гаиләләр елдан-ел арта бара. Шулай итеп, әкрен генә милли асылдан читләшкән яңа буын үсә. Ни өченме?! Төп сәбәп, миңа калса, үз телебезгә ихтирам юклыкта.

Үз телебезне ихластан хөрмәтләсәк, жандай кадерләсәк, алай булмас иде.

Телебез гаиләдә саклануга гына кайтып калса, нәрсә булачагын күз алдына китерү дә куркыныч:

– Татар телен укыткан мәктәпләр калмаячак.

– Яңа сүзләр татарчага тәрҗемә ителмәячәк, димәк,сөйләм теле дә яртылаш урыс сүзләреннән торачак.

– Татар телендә язган язучылар да калмаячак, димәк, әдәбият та, татарча матбугат чаралары да юкка чыгачак.

– Татар телендәге театрлар ябылачак, чөнки анда йөрерлек тамашачы түгел, уйнарлык артистлар да калмаячак – нәрсә уйнасыннар, әсәрләр язылмагач.

– Татар халкының тарихы да өйрәнелүдән туктаячак, чөнки татарча чыганакларны файдалана белмәячәкләр.

– Чын мәгънәсендә, юкка чыккан төньяк халыклар хәлендә калачакбыз бит – теле булмагач, милләт тә юк, милләт юк икән, аны искә алучы да булмаячак. Ул гаилә теле булып кына калу!

## В. НУРИЕВ ХИКӘЯЛӘРЕНЕҢ ТӘРБИЯВИ ӘҺӘМИЯТЕ

*Закирова Г., КФУ, V курс студенты*

*Фән. җит. – филол. фән. док., проф. Ф.С. Сәйфуллина*

Вакыйф Вәкил улы Нуриев – татар балалар язучысы, әдип, журналист, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре, Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы, А. Алиш исемендәге әдәби бүләк иясе. В. Нуриев кече һәм урта яшьтәге балаларга атап язган дистәләрчә хикәяләр авторы. Узган гасырның сиксәненче елларыннан башлап аның хикәяләре көндәлек матбугат битләрендә, башлангыч мәктәпләр өчен чыгарылган уку китапларында, хрестоматияләрдә, күмәк җыентыкларда даими басыла килә.

В. Нуриев – җитмешкә якын хикәя авторы. 1990 елда Татарстан китап нәшриятында аның “Бүре кадәр бүрек” дигән хикәяләр җыентыгы дөнья күрә. 2006 елда аның “Җиденче палата”, “Карга карагы”, “Әбиемә – әфлисун” повестьлары нәшер ителә. “Язучының һәрбер әсәре дә үзенчәлекле, уйлануга нигезләнеп язылган. Китапны кулга алу белән, ачык матур сурәт төшерелгән тышкы кыяфәте дисеңме, әсәрнең упкындай тирән мәгънәсе дисеңме – барысы да, “мине тизрәк ачып укы” – ди, сыман” [1: 6]. Тагын шунысын әйтеп үтәргә кирәк: хикәяләрнең күләме кечкенә, алар җиңел һәм тиз укыла. Балалар өчен язылган хикәяләр шундый булырга тиеш тә. Акыл сатмыйча гына бала күңеленә яхшылык

орлыгы чәчү, үсеп килүче буынны каләм белән тәрбияли белү – һәркемгә дә бирелмәгән.

Каләмдәше Г Гыйльманов В. Нуриев иҗатын югары бәяли һәм бер мәкаләсендә болай дип яза: “Минем игътибарны җәлеп иткән бер кулъязмасы – ул “Бүре кадәр бүрек”. Укый башлау белән кинәт үземне ниндидер сихри дөньяда, инде шактый еракта калган балачагымда итеп тойдым” [2: 208]. Ул әдәбиятка олыгаеп, тормыш тәҗрибәсе туплап, әзер, оешкан язучы булып килә, һәм тиз арада үз эшенең чын остасы булып танылa. Әсәрләренең стиле нечкә, балаларны күңелен аңлап иҗат итүе белән тиз арада укучыларның игътибарын үз иҗатына җәлеп итә.

В. Нуриевнең геройлары – тормышны үзләренчә аңлаучы, кабул итүче, бәяләүче һәм шат күңелле, кайвакыт ялкаурак, бераз хәйләкәррәк һәм шуграк, әһәмиятлесе – тормышчан балалар.

Әсәрләренең кайберләре формасы ягыннан да үзенчәлекле оештырылган. “Ашыгудан ни файда?” хикәясе монологтан гына тора, образны ачуда автор геройның “үз-үзе белән сөйләшүе” алымын кулланган. Шул рәвешле геройның эчке дөньясын, кичерешләрен ачуга ирешкән: “Нишләптер минем әби кыбырсык җан. Артыннан куалармыни – ашыга. Мин үзем бер дә ашыкмыйм. Ашыгудан ни файда?” [2: 315]. Монолог аша лирик геройның ялкаурак, пошымсыз бала булуы, моңа җайлы гына аңлатма таба белүе дә сурәтләнә. Югыйсә, балаларның күпчелеге кечкенә вакытта шундый булалар. Моңа өстәп, эчке сөйләм геройларны индивидуальләштерүдә дә мөһим фактор булып тора. Ул персонажның характерын, сөйләү үзенчәлеген чагылдыра. В. Нуриевның герое монологына ваемсызлык, эгоистлык хас.

Авторның әнисенә багышланган “Матуркай” әсәре гуманлылык хисе белән өретелгән. Айгөл исемле нәни кыз бала яралы һәм бер күзе сукырайган каз бәбкәсен саклап кала. В. Нуриев әсәргә эпиграф иттереп мондый юллар китерә : “Каз үстерү, каз симертү буенча иң оста булган ике хатынны беләм мин Кесмәс елгасы буенда. Аның берсе – минем әни, икенчесе – Нәкыя. М. Мәһдиев” [3: 3]. Язучының хатыны Нәкыя исемле була.

Әсәрләренә игътибар итсәк, автор әллә нинди чит җирләргә, дөньяда булмаган фантастик әйберләр хакында язмый, киресенчә, ул табигый, көндәлек вакыйгаларны, кешеләрне сурәтли. Бу – аның тагын бер үзенчәлеге. Нигездә, В. Нуриевне вакыйгалар түгел, ә

геройның характеры, хикәядә бирелгән образның язмышы, рухи дөньясы кызыксындыра.

“Шәп малаймы?” хикәясе аталар һәм балалар, яхшылык һәм яманлык, ак белән кара кебек каршылыклардан үрелгән. Бу хикәя турыдан-туры тәрбияви максатка нигезләнеп язылган. Малайның изге күнелле, мәрхәмәтле, олы җанлы булып тасвирлануы күңелне тынычландыра. Чөнки, кече яшьтәге малайлар психологиясе катырак, ныгырак була һәм мондый эшләргә бик якын тормыйлар. Әлеге хикәядә киресенчә, лирик геройны сыйныф җитәкчесе әтисенә мактый. Баксаң, әтисе дә малаен укытучы янында яманлап, җитәкчесеннән киресен ишетергә теләгәнлеген белдерә. Чит кешедән үз балаң турында яхшы, мактау сүзләрен ишетү рәхәт, ата-аналарның балага вакытында дөрес тәрбия бирүе горурландыра.

Нәтиҗә ясап әйткәндә, В. Нуриев хикәяләренең шундый сихри, үзенә тартучы яклары күп. Аның кайсы гына иҗат җимешен алма, барысы да уйга сала, укучыны уйландыра. Балалар өчен әдәби әсәрләрне бәяләүдә бүген куела торган төп критерияләрнең берсе – тормыштан алынган характерларны бирү, геройларның күңел кичерешләренә, бала психологиясенә тирәнтенрәк үтеп керү. Язучының балалар өчен язылган хикәяләренең тәрбияви әһәмияте бәяләп бетергесез зур.

В. Нуриевның замана балалар әдәбиятында үз иҗади йөзе, лаеклы урыны барлыгын хикәяләрендәге образлар, табигать күренешләрен тасвирлау алымнары, халык авыз иҗаты байлыкларының урынлы, лексик чараларның оста һәм бай кулланылулары күрсәтеп тора.

**ӘДӘБИЯТ**


1. Барҗылы В. Чеховны узды мәллә? // Шәһри Казан. 2006. 26 дек. Б. 4.
2. Гыйльманов Г. Заман сүз сорый. Казан: Татар. кит. нәшр. 1991. 69 б.
3. Нуриев В. Җиденче палата. Казан: Татар. кит. нәшр., 2007. 287 б.
4. Садә Г. Ул бүген дә балачак илендә // Шәһри Казан 2008. 19 авг. Б. 2.


## РОБАГЫЙЛАР – КҮҢЕЛ ТАШКЫНЫ


*Закирова М., Балтач р-ны Смәел урта мәктәбе, X сыйныф*

*Җит. – М.Р. Гыйзәтуллина*


Җәмгыятьтәге вакыйгаларга, күренешләргә, кешеләрнең гамәлләренә мин битараф түгел, “аягөсте” йөргәндә аларга карата карашың формалаша һәм шигырь куплетлары – дүртьюллыклар булып бөреләнә”, – дип яза ул үзе турында. Аның әлеге җыентыгы,

әйтергә кирәк, дүртьюллыклардан гына тормый. Шулай да кыска шигырьләр саллы гына урын биләп торалар.

Әлеге фәнни эшемне башлаган вакытта, мин үземә авылдашыбыз иҗатын мөмкин кадәр тирәнрәк өйрәнүне үзмаксат итеп алдым. Аның беренче китабы үз эченә төрле тематиканы сыйдырган. Алар арасыннан туган җир, яшәеш, табигать темасын, мәхәббәт лирикасын, җырларын, такмакларын, башка гыйбрәтле шигырьләрен атарга була. Ә икенче җыентыгы, шагыйрьнең үз сүзләре белән әйтсәк, "чәнечкеле" шигъри юллардан тора. Ул аны сатирик – фәлсәфи фикерләүләр дип атый. Әлеге җыентыгы 2017 нче елда Казан шәһәренең "Сүз" нәшриятында басылып чыга. Бу китапка кертелгән дүртьюллыкларны робагыйлар дип тә атап була. Аларда сүз үткенлеге дә, фикер кыскалыгы да остенлек итә, робагый жанры үлчәменә дә туры килә. Аның робагыйларын башка шагыйрьләрнең иҗатлары белән чагыштырып өйрәнү, бүгенге эшебезнең төп максаты дип әйтергә кирәк.

Хәйям рас әйткән – аңа зур рәхмәт:
"Яшәүдән башка юк башка җәннәт!"

Үзенең кыска шигырьләренең остазы итеп ул фарсы шагыйре Г. Хәйямне атый. Аның робагыйлары, тирән фәлсәфи фикерләрне кыска һәм оста итеп әйтеп бирү белән бергә, шигъри матурлыгы, сурәтлелеге, төгәллеге белән дә таң калдыралар.

Робагый – фарсы поэзиясендә дүртьюллыклар буларак урын алган аерым жанр. Әлеге жанрда рифмалашу схемасы ААБА яки АААА белән белдерелә. ААБА буенча түбәндәге мисалларны китерергә була:

Юлыкты милләтебез иң зур хәтәргә –
Урыстеллелек сеңгән куп татарга.
Күр: япсаң да янәшә былбыл белән,
Былбыл булып сайрамый бит тартар да! – дип тел язмышы турында борчыла игенче – шагыйрь.

"Ад и рай – в небесах", – утверждают ханжи.
Я в себя заглянув, убедился во лжи:
Ад и рай – не круги во дворце мирозданья,
Ад и рай – это две половины души – дип Г. Хәйям робагыен тәрҗемә итә Г. Плисецкий.

Берәү күкрәк кага: "Бу – мин!" – ди,
Берәү байлыкка мактана: "Бу – мин!" – ди,
Дәрәҗә, мал вә дан булды дигәндә,

Кинәт үлем килеп таба: “Бу – мин!” – ди.

Бу юлларны да Г. Хәйям иҗатыннан Н. Арсланов тәрҗемә итеп калдырган. Телгә алынган өч мисалда ААБА схемасы остенлек итте. Шул ук вакытта АААА схемасы буенча иҗат ителгән робагыйларны да күрергә була. Интернет материалларына күз салсак, рус теленә тәрҗемә ителгән робагыйлар арасында әлеге схема буенча язылганнары азрак очрый. Ләкин Г. Хәйям һәм Ф. Галиев иҗатында андыйларны еш очратырга мөмкин.

Авыр гомрең, үтәчәк дәм, курыкма,
Бүгенгедә күрәчәктән курыкма;
Шат үткәр көнне, узганны сагынма,
Хафаланма, киләчәктән курыкма, – дип яза Г. Хәйям.

Ф. Галиев түбәндәге юллар белән үгет – нәсихәт бирә:

Ялганчы алдар сине һич күзен йоммый,
Алганчы сайрар теле – телгә йокмый,
Әмма күпләр бер әйтемне истә тотмый;
Карчыга авызыннан ит кире чыкмый.

Эшемне төгәлләп йөргән көннәрдә, тагын бер төркем робагыйларга тап булдым. Аларның авторы Ә. Саттар иде. Аны да күпкырлы, талантлы шәхес дип атар идем мин. Тормышы да аның сәер, серле була. “Ә. Саттар биш китап авторы, алар арасында иң күренеклесе “Робагыйлар” китабыдыр”, – дип яза А. Хәлим. Ф. Галиев белән Ә. Саттар иҗатында фикер уртаклыгы игътибарны җәлеп итә. Ил язмышы турында бергә уйланалар алар.

Халык байлыклары илдә мулдан иде,
Сукбайлыкка чыгып бара ил...
Бу илне мин барыбер “Русь” дип атыйм,
Хет яклаучы булсын Җәбраил! – дип яза Ә. Саттар.

Фаварис абый үзенең фикер йомгагын түбәндәгечә сүтә:

Сүтеп була һәр нәрсәне бик тиз генә –
Менә дигән зур илне дә сүттек, әнә!
Шул “шатлык”тан без йөрибез инде менә,
Дөнья буйлап хәер эстәп, ава – түнә.

Менә шундый шагыйрь ул авылдашыбыз Ф. Галиев – күпкырлы, эзләнүчән, принциплы һәм бераз гына “чәнечкеле”. Бүгенге киеренке заманда аның иҗаты көннән – көн яңа сулыш ала, укучылары күңеленә матур энҗеләр булып урнаша, рухи байлык, матурлык өләшә. Ул үзен шагыйрь дип атамый, шагыйрьлеккә дәгъва да кылмый. Бары йөрәк түреннән чыккан шигъри юллары,

күңел дәрьясы, үзе яраткан иген кырлары кебек киң, бай, якты, ташкынлы һәм ярсулы аның.

## Ш. МӘРҖАНИ ЭШЧӘНЛЕГЕНӘ ҮТКӘН ЗАМАННАРДА ҺӘМ БҮГЕНГЕ КӨНДӘ КАРАШ

*Закирова Т., Әтнә р-ны, Комыргуҗа урта мәктәбе, X сыйныф*
*Җит. – К.К. Шәмсетдинова*

Халкыбызның бөек акыл иясе, даны һәм горурлыгы булган бу мәшһүр затка багышлап төрле телләрдә йөзләгән фәнни хезмәтләр, матур әдәбият әсәрләре языла, диссертацияләр яклана, сәнгать төрләре (бюстлар, рәсемнәр) иҗат ителә.

Бөек шәхесләр үз халкының тормышына, рухи дөньясына, шул исәптән аның сәнгатенә, хәтта аның бер төре булган матур әдәбиятына да билгеле бер дәрәҗәдә уңай йогынты ясыйлар, алга таба ул халыкның, ул милләтнең горурлыгына әвереләләр. Ш. Мәрҗани – шундый шәхесләрнең берсе. Данлы шәхесләргә бай булган татар халкының рухи дөньясында бу зат үзенә аерым, үзенчәлекле урын били. Шушы уңайдан, Мәрҗани шәхесенең татар шигъриятендәге, аның бер жанры булган мәрсия жанрындагы әсәрләрдә урын алган. Мәрсия – вафат булган кешеләрне олылап, мактап искә алучы, аларга карата ярату, ихтирам итү, хөрмәтле тойгыларын чагылдыручы шигъри әсәр. Мәрсияләрдә үзеннән соң фән, әдәбият, мәгариф, мәдәният өлкәсендә данлы исем калдырган шәхесләргә дан җырлана. Беренче чиратта, мондый шәхеснең күркәм, соклангыч кешелек сыйфатлары тасвирлана, туган халкына күрсәткән изге гамәлләре, хезмәтләре югары бәяләнә. Ш. Мәрҗани шәхесенә багышлап Акмулла, Г. Чокрый, Н. Думави, Г. Тукай һ.б. язган әсәрләр шушы төр мәрсияләргә карый.

Билгеле булганча, Ш. Мәрҗанигә багышланган иң беренче мәрсияләрне М. Акмулла һәм Г. Чокрый яздылар. Акмулланың 506 шигъри юлдан торган “Дамелла Шиһабетдин хәзрәтнең мәрсиясе” әсәрендә данлы галимнең туган халкын гыйлемле итү өлкәсендә башкарган изге эш-гамәлләре, мәгърифәтчелек идеяләре киң тасвирлана, аның шәхесен зурлап “караңгы фонарь кабызган зат”, “тимерказык” булуы хакында җылы фикерләр әйтелә.

Ш. Мәрҗанигә багышланган икенче әсәр – Г. Чокрый мәдхиясе. Матбугатта аның бары тик дүрт юллы ике генә строфасы дөнья күргән. Текстта Ш. Мәрҗанинең башкарган эш-гамәлләре турында әйтелә, галимнең “шөһрәт һәм бөек фикер иясе”, “күп

фәннәр, хикмәтләр укып”, “төрле мәсьәләләр ачып, күп дәлилләрне белүче, безне дөрес юлга салучы” зат булуы турында бәян итеlә. Бу әсәр дә оптимистик рухта язылуы белән сыйфатлана.Уфадагы З. Вәлиди исемендәге Республика китапханәсенең өлкәне өйрәнү бүлегендәге Г. Чокрый фондында робагый белән 64 юллык күләмдәге мәрсиянең кульязмасы саклана.

Мәрҗанинең вафатына 25 ел тулуны билгеләп үтүгә хәзерлек мәсьәләләре алга килеп баскан чорда олы фикер иясенә багышлап шигырь язучылардан Н. Думави һәм Г. Тукай аеруча матур үрнәк күрсәтәләр. Н. Думави “Ш. Мәрҗани хәзрәтләренең кабере янында” исемле шигырен шул уңай белән иҗат итә һәм ул “Йолдыз” газетасының 1912 елгы 24 июнь санында дөнья күрә. Оптимистик рухта иҗат ителгән бу әсәр, формасы ягыннан караганда, Акмулла мәдхиясеннән ике юллыклар ярдәмендә иҗат ителү белән генә аерыла. Әмма эчтәлек ягыннан шушы иҗат җимешләре аваздаш: аларда буеннан буена Ш. Мәрҗанинең халыкка гыйлем тарату өлкәсендәге эшчәнлеге, яхшы кешелек сыйфатлары, оптимизмы, батырлыгы тасвирлана, эш-гамәлләренең кыйммәте объектив рәвештә бәяләнә. Г. Тукай фикерләре шигъри монда чагыла:

Чыкты ахры бездән дә бер бөтен кеше,
Яхшы аңлап, тәкъдир итү читен кеше,
Татарда да гыйрфан уты кабынганны
Күрсәтергә күтәрелгән төтен кеше.
Кирәк булса, әйтеп бирим: ул шәп хәзрәт,
Тулган ай күк балкып чыккан Шиһап хәзрәт,
Мәгарифкә әүвәл башлап адым салган,
Милләт өчен бәһа җитмәс кыйбат хәзрәт.

Совет хөкүмәтенең баштагы чорында шактый вакыт дәвамында Ш. Мәрҗани буржуаз галим, дини реформатор буларак кына бәяләнеп киленгән, аның тормышы һәм гыйльми эшчәнлегенә багышланган махсус фәнни тикшеренүләр, эзләнүләр алып барылмаган. Менә шушы дәвердә Г. Камал театрында режиссёр Х. Уразиков куйган “К. Насыйри” пьесасы игътибарга аеруча лаеклы. Татар халкының ике данлы шәхесе – К. Насыйри һәм Ш. Мәрҗани образларын сәхнәгә күтәрү ягыннан бу спектакль татар театрында аеруча әһәмиятле урын алып тора – спектакль берничә дистә елга сузылган фәнни фикерләүдәге бушлыкны

берникадәр булса да тутырырга булышучы кыйммәтле хәзинә булып санала.

Бүгенге көннәргә килсәк, фикерләр мондыйрак:

2005 елда А. Юзеевның Ш. Мәрҗанигә багышланган 350 данәдә генә басылган 112 битлек “Звезда по имени Марджани”нең документаль-биографик повесте “Гасыр” нәшриятында “Гасырлар авазы – Эхо веков” журналына кушымта буларак чыккан.

Россия Фәннәр академиясенең Көнчыгыш институты Гарәп һәм ислам тикшеренүләре үзәге галиме Леонид Сюкияйнен фикеренчә, Шиһабетдин Мәрҗани мирасы гаять дәрәҗәдә бай һәм тирән. Аның китапларын төрле телләрдә күпләп нәшер итеп таратырга кирәк, Энциклопедик галим күрсәткән юл буенча традиция рәвешендә барырга кирәк.

Философия фәннәре докторы А. Юзеев Шиһабетдин Мәрҗани рухи тормышта иске, таушалган авторитетларның монополиясен җимерүче, татарны торгынлык йокысыннан уятучы булуын билгеләп үтә.

Мәрҗанине дөньяның бик күп галимнәре белгән. Ул алар белән аралашкан, әңгәмәләшкән. Танылган рус галиме, академик Василий Бартольд аны: “Татарлар арасында прогрессив агымга нигез салучы…” – дип атаган.

## ОБРАЗНЫЕ ПРИЛАГАТЕЛЬНЫЕ В ЯКУТСКОМ ГЕРОИЧЕСКОМ ЭПОСЕ П.А. ОЙУНСКОГО «ДЬУЛУРУЙАР НЬУРГУН БООТУР»

*Захарова А., Северо-Восточный федеральный университет, магистрант II курса*

*Науч. рук. – канд. филол. наук, доц. А.К. Прокопьева*

Сравнение – не только способ представления эмоции и оценки говорящего (автора), но и сигнал для их обнаружения читателем. Оно создает особый экспрессивный подтекст. Фольклорист Г.У. Эргис писал, что многие сравнения, уподобления и метафоры в олонхо заимствованы из мира окружающей природы, скотоводчества и охотничьего быта [5: 204].

Сравнения в якутском языке могут выражаться путем основосложения. Л.Н. Харитонов такой способ основосложения называет парными сочетаниями, которые «по значению соответствуют русским сложным прилагательным типа снежно-белый, пепельно-серый» [4: 133].

Ю.И. Васильев отмечает: «суть этого способа состоит в том, что существительное, представляющее эталон сравнения, непосредственно примыкает слева к названию признака – модулю сравнения, выраженному прилагательным» [1: 37]. Также Ю.И. Васильев делит на две группы сочетания, образованные способом основосложения: сочетания, в которых в роли второго компонента (модуля сравнения) выступают названия цветов и сочетания, в которых в аналогичной роли выступают названия качеств, признаков кого-то или чего-либо.

В примере ***үүт маҥан халлаан*** ‘что молоко, белое небо’, где *үүт* ‘молоко’ – эталон сравнения, *маҥан* ‘белый’ – модуль, *халлаан* ‘небо’ – объект сравнения: *үс хартыгастаах / үрдүк* ***үүт маҥан халлаан*** [3: 24] ‘трехъярусное белое небо’ [2: 17], букв: ‘высокое трехъярусное, что молоко, белое небо’. Слово *үүт* ‘молоко’ использован для подчеркивания значения модуля.

Похожее сравнение неба есть в следующем примере ***үрүмэ долгуннаах*** ‘волны с пенкой’, где волны неба сравниваются с пенкой молока: *үс хартыгастаах /* ***үрүмэ долгуннаах*** */ үрдүк маҕан халлаан* [3: 74] ‘на трехъярусном своде, / где облака гуще белого каймака’, букв: ‘трехъярусное, что волны с пенкой, высоченное белое небо’.

Следующие два примера направлены на описание масти лошадей: ***Үрүмэччи маҕан аттаах*** */ Үрүҥ Уолан* [3: 84] ‘на Мотыльково-белом коне / Юрюнг Уолан-богатырь’ [2: 65]; *Ньэлбэн Айыыһыт /* ***үүт кэрэ биэ*** *буолан* [3: 38] ‘белой, как молоко, / кобылицей оборотясь’ [2: 27]. В первом примере ***үрүмэччи маҕан аттаах*** ‘с белым, что мотылек, конем’, где *үрүмэччи* ‘мотылек’ – эталон сравнения, *маҕан* ‘белый’ – модуль, *ат* ‘конь’ – объект сравнения: Во втором примере ***үүт кэрэ биэ*** ‘белая, как молоко’, ‘кобыла’ *үүт* ‘молоко’ употреблено для усиления значения масти *кэрэ* ‘белый’.

Образное выражение ***көмүс уйа*** ‘как золото гнездо’ используется для описания очага Сабыйа Баай Хотун: *Ньэлбэн Айыыһыт /* ***көмүс уйаларын****/ өрөкүйбүтүнэн кэлэн / өҥөйөн көрдө* [3: 38] ‘Ньэлбэн Айысыт прискакала к урочищу первых людей, / прянула на дыбы, / глянула в их золотое жилье’ [2: 27].

В якутском героическом эпосе «Дьулуруйар Ньургун Боотур» встречаются сочетания, в которых в роли второго компонента выступают названия цветов. В наших примерах модулем выступает

цвет *хара* ‘черный’ в описаниях окрестности старика Хаан Хандыгана и Эрбэс Боотура. ***Хандалы хара тыа*** ‘черный лес, что кандалы’, где эталон сравнения *хандалы* ‘кандалы’, модуль – *хара* ‘черный’, объект – *тыа* ‘лес’: ***хандалы хара тыа*** *haххалаах* / Хаан Хандыҕан оҕонньор [97] ‘скрытый за черной / чащобой лесной / Хаан Хандыган-исполин’ [74]. Второй пример***: тумул хара тыа*** ‘черный лес что мыс’, ***даркы хара тыа*** ‘черный лес что груда’, где эталон сравнения *тумул* ‘мыс’ и даркы ‘груда’, модуль – *хара* ‘черный’, объект – *тыа* ‘лес’: *адаар хара тыа / атаастаах, /* ***тумул хара тыа*** */ тусаһалаах, / тэҥкэ хара тыа / тэлгэһэлээх, /* ***даркы хара тыа*** */ даллаах, / баай хара тыа / балаҕаннаах / Эргэнэ хара тыа иччитэ, / Эригир харах, Эрбэс Боотур!* [3: 97] ‘твой широкий алас – / высокий лес, / твой скотный двор – / дремучий бор, / твой коровий варок – / обгоревший лог, / дверь твоя – / лесной бурелом, / твой богатый дом – / вся тайга кругом, / летняя твоя ураса – / лиственные леса’ [2: 74].

В тексте встречаются и примеры описывающие ребенка как физически активного и смелого. ***Кылыс дыгый оҕо*** ‘ребенок грациозный как нож’, где эталоном сравнения выступает *кылыс* ‘нож’, модуль – *дыгый* ‘грациозный’, объект – *оҕо* ребенок: *тустуук уол миэхэ баар, / Сыыдам атах / Сыссыык оҕо миэхэ баар, / Кылыыһыт бэрдэ /* ***Кылыс дыгый оҕо*** *миэхэ баар* [3: 316] ‘у меня есть такой борец, / что если за руку схватит кого, – / руку с плечом оторвет. / у меня самый быстрый мальчик-бегун, / у меня самый легкий парень-прыгун. / у меня – знаменитый неесный скакун’ [2: 246]. ***Таас-килиэ оҕо*** ‘ребенок как камень’, где эталон сравнения *таас-килиэ* ‘камень’, объект *оҕо* ‘ребенок’: *Адьыҥа Сиэр хотунтан / Тоҕус ый хонугун / Толорбокко эрэ / Иирээн эҥэрдэнэн, / Илбис төрүттэнэн, / Ийэтин иһиттэн /* ***Таас-килиэ оҕо*** */ Таралыйа түһээт...* [3: 24] ‘задолго до девятилунной поры / из чрева прекрасной хотун, / расторгнув утробу ее, / одержимо неистовством бунтовским, / выкатилось каменное дитя, / звонко, отрывисто хохоча, / пронзительно крича’. В этих примерах ребенка сравнивают с грациозным якутским ножом и твердым камнем. В эпосах жизнь ребенка начиная с утробы матери гиперболизирован, например, *биир хоноот биирдэннэ, икки хоноот иккилэннэ* ‘через день исполнился один, через два исполнился два’.

Таким образом, образные прилагательные в якутском героическом эпосе П.А. Ойунского «Дьулуруйар Ньургун Боотур»

встречаются часто. Данный способ используется для образного описания (различных) признаков предметов.

*Статья выполнена при финансовой поддержке Госзадание 2016. Регистрационный номер 34.3377.2017/ПЧ.*

**ЛИТЕРАТУРА**

1. Васильев И.Ю. Способы выражения сравнения в якутском языке. Новосибирск, 1986. 109 с.

2. Нюргун Боотур Стремительный. Якутский героический эпос. Воссоздал на основе народных сказаний Платон Ойунский. Якутск. Кн. изд-во, 1975. 432 с.

3. Ойуунускай П.А. Дьулуруйар Ньургун Боотур. Дьокуускай, 2003. 544 с.

4. Харитонов Л.Н. Современный якутский язык. Ч. 1. Фонетика и морфология / под. ред. Н.К. Дмитриева. Якутск: Госиздат ЯАССР, 1947. 312 с.

5. Эргис Г.У. Очерки по якутскому фольклору. М.: Наука, 1974. 402 с.

## ТАТАР СӨЙЛӘШЛӘРЕН ӨЙРӘНӘ БАШЛАУ ТАРИХЫ

*Ибатуллина Р., КФУ, II курс магистранты*

*Фән. җит. – филол. фән. канд., доц. М.Р. Саттарова*

Хәзерге вакытта тел белемендә диалектология алга киткән тармакларның берсе. Милли телебезнең җирле сөйләшләре галимнәр җитәкчелегендә тулы эчтәлекле махсус программа нигезендә Россиянең егермедән артык өлкә һәм республикаларында экспедицияләр уздыру юлы белән өйрәнелгән. Татар диалектологиясенең йөз елдан артык вакыт эчендә фән буларак үсеш-үзгәрешен яктырткан, казанган уңышларын бөрбетен итеп чагылдырган хезмәтләр шактый. Әлеге хезмәтләр тупланган материалларны бүгенге көн таләпләреннән, фәнни-теоретик фикернең үсеш дәрәҗәсеннән чыгып яңа күздән уздыралар. Моның өчен без күренекле тюрколог Л.Т. Мәхмүтовага бурычлы. Ул 25 ел буе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтының тел бүлеген җитәкли. Татар теленең 3 томлык аңлатмалы сүзлеге (1977-1981), диалектологик сүзлек (1969), диалектологик атлас (2 томда, 1989) кебек монументаль хезмәтләр аның җитәкчелегендә дөнья күрә. Бу хезмәтләр татар тел белемен тагын да югары баскычка күтәрә.

Үзенең тарихи үсешендә телләр нигездә өч баскыч үтәләр: 1) кабилә телләре, 2) халык телләре, 3) милли телләр.

Тел үсешенең беренче этабында тел һәм диалект гамәлдә аерылмый. Чынбрлыкта кабилә һәм диалект асылда бер-берсенә туры киләләр. Икенче этапта, бер яктан, халык теле белән, икенче яктан, диалектлар арасында принципиаль чик барлыкка килә.

Милли әдәби телләрнең барлыкка килү чоры өчен телнең

рәсми-әдәби формаларының җанлы сөйләү теленнән аерылуын җиңеп чыгу хас.

Татарлар төркем-төркем булып (яки компактлы булып) нигездә Идел буе –Урал алды төбәкләрендә һәм Себердә гомер итә. Биредә барлык татар халкының 3/2 гә якын өлеше (яки 65%ы диярлек) яши. Татарлар Урта Азия республикаларында, Мәскәү, Санкт-Петербург һәм башка шәһәрләрдә тормыш алып бара.

РФ төбәкләрендә һәм республикаларында яшәүче күп кенә төркем татарлар туган җирләрендә калган. Татар халкының территориаль яктан таралышы бер яктан саклану корылмалары, кирмәннәре төзүгә, Рус дәүләте каршындагы хәрби хезмәтләр өчен бүләкләүләргә һ.б. га бәйле булса, икенче яктан татарларның ирекле рәвештә буш җирләр эзләвенә, чукындыру сәясәтенә, сәүдә үсешенә һ.б.ларга барып тоташа.

Россиянең үзәк губерналарыннан татар халкының көнчыгыш, көньяк-көнчыгыш төбәкләргә күчеше XIX гасыр ахыры-XX гасыр башына кадәр дәвам итә. Әлеге күчешнең иң актив чоры XVI-XVIII гасырларга туры килә.

Татар диалеклары хакында беренче мәгълүматлар XVIII гасыр уртасына караган хезмәтләрдә күренә башлый. Бу рухи һәм материаль мәдәни кыйммәтләр барлыгы ачыкланган вакыт аралыгы исәпләнә. Г.Ф. Миллер, И. Георги, Ф.И. Страленберг, П. Паллас һ.б. кебек тарихчы-галимнәр үз хезмәтләрендә төрле төбәкләрдә, төрле җирләрдә гомер итүче татарларга бәйләнешле лексик материаллар туплый. Нәкъ шушы чорда гимназияләрдә һәм күп кенә уку йортларында татар теленә өйрәтә башлыйлар, татар телен камил белүче яңа кадрлар әзерлиләр. Бу бер яктан төрле өлкәләрдә христианлаштыру сәясәтен җәелдерү, тормышка ашыру өчен кирәк булса, икенче яктан Көнчыгыш, Урта Азия, Кавказ һ.б. лар белән дипломатик мөнәсәбәтләр урнаштыру өчен эшләнә. Шул рәвешле үзеннән-үзе татар телендәге уку ярдәмлекләренә, китапларга, үзөйрәткечләргә, сүзлекләргә ихтыяҗ килеп туа.

Татар теленә караган материалларны теркәү һәм аларга теге яки бу күләмдә фәнни аңлатма бирү Россия Фәннәр академиясе тарафыннан оештырылган, профессор Г.Ф. Миллер җитәкчелек иткән Себер экспедициясеннән башлана (1733-1743 еллар). Ул татар җанлы сөйләү теле материалларын җыю эшенең беренче адымын ясый. Аның “Себер тарихы” дигән зур күләмле хезмәтендә “себер татарларының барлык диалектларыннан җыелган лексикон”

бирелә; тел материаллары нигезендә шул халыкның тарихын ачуга омтылышлар ясала.

Шушы ук рәттә П.С. Палласның “Словарь всех языков и наречий” (СПб., 1787-1789) исемле хезмәтен дә күрсәтергә кирәк, анда төрле регионнарга караган татарча тәкъбирләр һәм сүзләр теркәлгән. И.М. Лепехин (1821: 147, 159), П.И. Рычков (1792; 1896) кебек рус галимнәренең сәяхәтнамәләрендә дә татар сүзләрен һәм этнографизмнарын табарга мөмкин. “Историко-географическое описание Пермской губернии, сочиненное для атласа 1800 года” (Пермь, 1801) исемле хезмәттә хәзерге Пермь өлкәсендә яшәүче төрки халыкның теле турында да мәгълүмат китерелә.

Шулай итеп, XIX гасырның азагында һәм XX гасыр башында татар диалектологиясенә фән буларак нигез салына, татар диалектларын һәм сөйләшләрен чагыштырып өйрәнү, төркемләү мәсьәләсе күтәрелә һәм беренче тәҗрибәләр ясала.

**ӘДӘБИЯТ**

1. Арсланов Л.Ш. Очерки по диалектологии и ономастике (избранные труды). Елабуга, 2009. 242 с.

2. Әхәтов Г.Х. Себер татарлары теле. 1 кисәк: Фонетик үзенчәлекләр. Казан: Татар. кит. нәшр., 1960. 70 б.

3. Гафаров И.Ә. Мишәрләр: Тарих һәм тел. Казан: Идел-Пресс, 2011. 256 б.

4. Җәләй Л. Татар теле диалектларын өйрәнү өчен кыскача программа // Совет мәктәбе. 1940. № 9. 45 б.

5. Махмутова Л.Т. Диалектологик сүзлек төзүнең төп принциплары // Татар теленең диалектологик сүзлеге. Казан, 1969. 272 б.

6. Насипов И.С. Татар диалектологиясе. Библиографик белешмә. Стәрлетамак, 2004. 155 б.

## Г. ТУКАЙ ИҖАТЫ ҮРНӘГЕНДӘ УКУЧЫЛАРДА МИЛЛИ МӘДӘНИ-ТАРИХИ КҮЗАЛЛАУ ФОРМАЛАШТЫРУ

*Исмәгыйлева Л., КФУ, I курс магистранты*

*Фән. җит. – филол. фән. канд, доц. Т.Ш. Гыйләҗев*

Әдәбият дигән олы диңгез инеш-елгаларны тәшкил иткән аерым шәхесләр иҗатыннан тора. Татар әдәбияты тарихында бай иҗади мирас калдырган бөек әдибебез Габдулла Тукайның урыны гаять югары. Г. Тукай иҗатының мәктәп укучыларында милли хис тәрбияләүдә, тарихи-мәдәни күзаллау формалаштырудагы ролен тикшерү эшебезнең фәнни яңалыгын билгели.

Гомуми урта белем бирү мәктәпләрендә Г. Тукай иҗатын өйрәнүнең максаты – шагыйрь мирасының халык тормышындагы тоткан урынын билгеләү, әсәрләре аша тормышны аңларга өйрәнү,

сүз сәнгатен рухи юлдаш итү. Буыннан буынга күчкән әдипнең иҗади мирасы бүгенге көннең бик күп һәм актуаль сорауларына җавап табарга ярдәм итә.

Шагыйрь иҗатын шәрехләүдә тәүге сукмакны салган тукайчы галим Җ. Вәлиди болай дип яза: “Тукаев үзенең күңел җимешләреннән балаларны да өлешсез калдырмады. “Юаныч”, “Алтын әтәч” һәм “Балалар күңеле” вә башкалар аның балаларыбызга иң зур һәдияседер (бүләгедер. – *Л.И.*). Ул шулар аркылы үзен халкына мәктәптән үк танытты. Хазир (хәзер. – *Л.И.*) Тукаевны белмәгән мәктәп баласы юк кебектер” [1].

Г. Исхакый үзенең күпсанлы тәнкыйди, публицистик мәкаләләрен Г. Тукайга багышлый. Алар арасында шагыйрьнең мәктәптәге роле мәсьәләсен калкытып куйган һәм авторның бүген дә заманча яңгырый торган бәя – хөкемнәрен гәүдәләндергән “Тукай мәктәптә” дигән язмасы аерым урында тора. Ул 1914 елда “Мәктәп” журналында басыла. Г. Исхакый әлеге мәкаләсендә Тукай иҗатының мәктәптәге роле мәсьәләсенә бәйле рәвештә “әдәбиятның мәктәптәге урыны, укытуның бурычлары, максатлары турында сүз алып бара” [3: 36]. Ә алар – балаларны тормышка әзерләү, дөреслекне төшенергә өйрәтү, балаларның рухына азык бирү, аларда югары әхлак сыйфатлары тәрбияләү, авторның үз сүзләре белән әйтсәк, “кеше хәлен, кеше кайгысын үз кайгысы иттереп уйлатырга өйрәтү” [1: 125]. Әдәбият дәресләрендә әлеге максат-бурычларга ирешү юлында каләме, бөтен тормышы, иҗтимагый-сәяси эшчәнлеге белән милләткә хезмәт иткән әдипләр иҗатын өйрәнү иң үтемле чара төсендә тәкъдим ителә. Шуларның берсе – һичшиксез, шагыйрь Г. Тукай.

Татар әдәбиятын укыту программасында Г. Тукай иҗатын өйрәнүгә сәгатьләр күп бирелә. Әдип иҗатына, аеруча, татар урта гомуми белем бирү мәктәбенең 10 нчы сыйныфы дәреслек хрестоматиясендә зур басым ясала. Бирелә Г. Тукайның “Тәэссер”, “Ана догасы”, “Таян Аллага”, дини фәлсәфә “Милли моңнар”, татар халкы тарихының шанлы һәм фаҗигале битләре “Дусларга бер сүз”, “И каләм!”, “Шагыйрь”, “Бер татар шагыйренең сүзләре”, “Сәрләүхәсез”, “Сорыкортларга”, “Государственная думага”, “Алтынга каршы”, “Милләтә”, “Үз-үземә”, “Кичке азан”, “Китмибез”, “Мөхәрриргә”, “Кызык гыйшык”, “Бәйрәм вә сабыйлык вакыты”, “Кыйтга” әсәрләре укучылар карамагына тапшырыла. Сайланма шигырьләр шагыйрь лирикасының төп

“Татар теленең диалектологик сүзлеге”ннән мишәр диалектындагы гарәп алынмалары барланды һәм әдәби телдәге сүзләр белән чагыштырып каралды. Тикшереп чыкканнан соң билгеле бер фикер барлыкка килде. Мәсәлән, *абыз* сүзе мишәр диалектында страшая сестра, ягъни апа мәгънәсендә йөрсә, әдәби телдә – укымышлы, абруйлы кешеләргә дәшкәндә кулланыла торган сүз; *асаба* – озын буйлы мәгънәсендә диалектта, әдәби телдә-җирле халык; *бәрәхәт* – күчтәнәч белән килүче – диалектта, ә әдәби телдә – муллык, барлык, матди иркелек чыганагы, файда, уңыш, табыш мәгънәсе; *мәзәк* – яшьләр кичәсе, әдәби телдә – шаярып, уйнап әйтелгән сүз, шаяру, уенчак сүз,кызык хәл; *халык* – нәсел, әдәби телдә – нинди дә булса илдә, дәүләттә яшәүче кешеләр. Әлеге сүзләр әдәби телдә, ягъни нигез телдә киң мәгънәдә кулланылалар. Мишәр диалектындагы сөйләшләрне тулысынча барлап чыкканнан соң ләмбрә сөйләшендәге гарәп алынмаларының мәгънәләре диалектта тараю очрагы иң еш күзәтелә дигән нәтиҗә барлыкка килде.

Хәзерге татар теле лексик байлыгы зур үсеш алган телләрдән санала. Анда йөзләрчәмең сүз бар, һәм ул көннән-көн төрле юллар белән үсә, байый.

Татар теленең лексикасы башка теллэрдән сүзләр алу исәбенә дә арта. Татарлар меңәр еллар буена төрле тел гаиләләренә караган халыклар белән тыгыз бәйләнештә яшәгәннәр.

Шулай итеп, әдәби телдә кулланыла торган гарәп алынмаларының лексик-семантик, фонетик һәм грамматик үзенчәлекләре шактый бай. Татар теленең көнбатыш диалектларында гарәп алынмалары чагыштырмача күп кулланыла. Диалектларда мәгънә тараю очраклары еш күзәтелүен күрдек. Алынмалар бер төрле әйтелеп, бер төрле язылсалар да, семантик яктан үзгәреш кичерәләр.

**ӘДӘБИЯТ**


1. Арабско-русский и русско-арабский словарь. Москва: Дом Славянской книги, 2014. 960 с.
2. Баязитова Ф.С. Татар-мишәр рухи мирасы. Гаилә-көнкүреш, йола терминологиясе һәм фольклор. Саранск: Татар газ., 2003. 285 б.
3. Баязитова Ф.С., Рамазанова Д.Б., Садыкова З.Р., Хәйретдинова Т.Х. Татар теленең зур диалектологик сүзлеге. Казан: Татар. кит. нәшр., 2009. 839 б.
4. Зәкиев М.З. Татар лексикологиясе: өч томда. Казан, 2015. Т. I. 352 б.


## ТАТАР ТЕЛЕНДӘ “ВАКЫТ” КОНЦЕПТЫ


*Мирҗанов Р., Түбән Кама, 20 нче урта мәктәп, X сыйныф*

*Җит. – И.Ш. Ишмөхәммәтов*


Телне мәдәни күренеш буларак өйрәнү бүгенге көндә бик актуаль. Татар телендә “ут”, “моң”, “сагыш” кебек концептлар тикшерелгән, алар буенча фәнни эшләр башкарылган, ә “вакыт” концепты әлегә кадәр тикшерелми кала бирә. Шуны истә тотып, үз алдыбызга “вакыт” концептының татар телендә чагылышын тикшерү максатын куйдык.

“Вакыт” сүзе, гарәп алынмасы булуга карамастан, татар теле тарафыннан тирән үзләштерелгән. Моңа дәлил буларак “Татар теленең аңлатмалы сүзлеге”ндә “вакыт” сүзенең 11 мәгънәсе китерелә [6: 228-229].

“Татарча-русча сүзлек”тә вакыт сүзенең 6 мәгънәдәге тәрҗемәләре китерелгән [7: 282-283].

Синонимнар сүзлеге нигезендә “вакыт” концептының синонимик рәте төзелде: *вакыт – чак; мәл; дәм; мизгел; момент; кавым; дәкыйка* [9: 30]. Безнең очракта доминанта булып, “вакыт”

сүзе үзе тора. Сүзнең мәгънә катламнары киң һәм бай. Ул татар теленең үз концептына әверелгән дип әйтә алабыз.

Дөнья тел картинасын анализлау өчен мәкаль һәм әйтемнәрне анализлау мөһим санала. Шуның өчен без “вакыт” компоненты булган мәкаль һәм әйтемнәрне барладык. Паремияләрне өйрәнү, беренчедән, мәдәният белән билгеләнгән телдәге мәгънәләрне ачыкларга, икенчедән, аеруча мөһим мәдәни стереотипларны формалаштыруның когнитив алымнарын карарга мөмкинлек бирә [2: 124]. “Вакыт” концепты татар теленең мәкаль-әйтемнәрендә актив чагылыш таба. Татар халык менталитетында “вакыт” компонентлы мәкаль-әйтемнәр милли дөнья картаинасының бер өлешен тәшкил итә. Н.С. Исәнбәтнең “Татар халык мәкальләре” китабында (I, III томнар) “вакыт” сүзе кергән 20 берәмлек китерелә [5: 758], [4: 297-298]. Интернет челтәрендә татар халык мәкальләре тупланмасында боларга өстәп тагын 5 мәкаль-әйтем очраттык [10]. Шагыйрь Г. Кандалыйның вакытның кадере турында әйткән “Якутлар табыладыр вакыт белән, вакытлар табылмыйдыр якут белән” сүзләре дә афоризмга әверелгән.

Г.Х. Әхәтовның “Татар теленең фразеологик әйтелмәләр сүзлеге”ндә “вакыт” концепты кергән 3 фразеологизм теркәлгән [1: 42]. Ә Н. Исәнбәтнең “Татар теленең фразеологик сүзлеге”ндә исә 10 фразеологик әйтелмә очратырга була [3: 212]. “Татар теленең аңлатмалы сүзлеге”ндә, боларга өстәп, түбәндәге фразеологизмнар урын алган: 1) *вакыт килер (җитәр)* – берәр нәрсә эшләр өчен мөмкинлек, уңайлы шарт тууга ышаныч белдергәндә әйтелә; 2) *вакыты җитеп* – картаеп, яшен яшәп, картлык көненә җитеп (гадәттә кеше үлгәннән соң әйтелә) [6: 229]. Болардан тыш “Татарча-русча сүзлек”тә “вакыт” концепты кергән 11 фразеологизмның тәрҗемәсе китерелгән [7: 283]. “Татарча-русча-инглизчә фразеологик сүзлек”тә боларга өстәп 9 фразеологик әйтелмәне очратырга мөмкин [8: 51-52].

Димәк, татар халкында “вакыт” сүзе “чор”, “дәвер”, “заман”, “чак”, “ара” төшенчәләре белән тыгыз бәйләнгән, ләкин, гомумән әйткәндә, “вакыт” ул – кисем, аралык.

Алынма сүз булуына карамастан, “вакыт” югары ешлыкка, күпмәгънәлелеккә ия; актив лексика; актив ясагыч нигезле сүз (вакытлы, вакытлы-вакытсыз, вакытлылык, вакытча, вакытлыча, вакытсыз, вакытсызлык, вакытына, вакытында). “Вакыт” бер составлы атау җөмләнең баш кисәге, шигырь исеме була ала.

“Вакыт” лексемасының синтагматик бәйләнешләре киң: вакыт – үтә, ага, бетә, туктап тора, чаба, уза, тәгәри, ычкына, ота, тиз тотыла, тия (тими), таба (тапмый), туры китерә, тыгыз һ.б.

Телдә вакыт берәмлекләрен аңлатучы сүзләр дә бик күп: секунд, минут, сәгать көн, тәүлек, атна, ел, мизгел, дәвер, чак, гасыр, чор, срок, дата, замана, таң, иртә, көндез, кич, төн һ.б.

Вакытны тасвирлаганда, аның хәрәкәт итүен чынбарлыктагы предмет-күренешләрнең хәрәкәте белән чагыштырып күрсәтәләр. Гадәттә, татар телендә вакыт су кебек ага, ком кебек коела, җил кебек исә, болыт кебек ага.

“Вакыт” концептының кулланылу ешлыгы, лексик-семантик вариантлары булуы аның татар дөнья тел күренешендә гаять мөһим урын алып торуын раслый. Әлеге концепт үз эченә татар халкының дөньяга булган карашлар системасын туплаган. Бу концептны репрезентацияләүче тел һәм сөйләм материаллары халык тарихын, халыкның тормышка мөнәсәбәтен ачыкларга ярдәм итә. “Вакыт” концепты милли концепт критерийларына туры килә.

Шулай итеп, “вакыт” концептын тикшерү барышында без аның татар теле дөнья күренешендә мөһим урын алуын, художестволы дөнья күренешен баетуга да зур өлеш кертүен ачыкладык. “Вакыт” концепты халыкның дөньяны танып белү үзенчәлекләрен, яшәү принципларын билгеләргә ярдәм итә.

**ӘДӘБИЯТ**


1. Әхәтов Г.Х. Татар теленең фразеологик әйтелмәләр сүзлеге. Казан: Татар. кит. нәшр., 1982. 176 б.
2. Җамалетдинов Р.Р. Тел һәм мәдәният: Татар лингвокультурологиясе нигезләре. Казан: Мәгариф, 2006. 351 б.
3. Исәнбәт Н.С. Татар теленең фразеологик сүзлеге. 2 томда. Т. I. Казан: Татар. кит. нәшр., 1989. 495 б.
4. Исәнбәт Н.С. Татар халык мәкальләре: мәкальләр җыелмасы: 3 томда. 2-нче басма. Т. I. Казан: Татар. кит. нәшр., 2010. 622 б.
5. Исәнбәт Н.С. Татар халык мәкальләре: мәкальләр җыелмасы: 3 томда. 2-нче басма. Т. III. Казан: Татар. кит. нәшр., 2010. 799 б.
6. Татар теленең аңлатмалы сүзлеге: 3 томда, Т. I. Казан: Татар. кит. нәшр., 1977. 476 б.
7. Татарско-русский словарь: В 2-х т. Т. I (А-Л). Казань: Магариф, 2007. С. 282-283.
8. Татарча-русча-инглизчә фразеологик сүзлек. Казан: Хәтер, 2010. 296 б.
9. Ханбикова Ш.С., Сафиуллина Ф.С. Синонимнар сүзлеге. Казан: Хәтер, 2001. 255 б.
10. https://tt.wikibooks.org/wiki/Татар_халык_мәкальләре#Вакыт-форсатны_кулдан_җибәрмәү

# ТАТАР ТЕЛЕ ДӘРЕСЛӘРЕНДӘ СҮЗЛЕКЛӘР БЕЛӘН ЭШЛӘҮНЕҢ МӨҺИМЛЕГЕ

*Мөхәммәтҗанова А., КФУ, II курс магистранты*
*Фән. җит. – филол. фән. канд., доц. А.Ф. Юсупов*

Сүзлекләр хәзерге көндә бик кыйммәтле истәлекләр булып саналалар. Сүзлек – сүзләр исемлеге. Билгеле, гадәттә сүзлектә сүзләр исемлеге генә бирелми, аларга аңлатмалар бирелә, мәгънәләре төшендерелә, ул сүзләрнең нинди әйберләрне, күренешләрне белдерүләре аңлатыла, сүзләрнең әйтелеше, язылышы, килеп чыгышы һ.б. хакында белешмәләр бирелә.

Сүзлекләр – кыйммәтле истәлекләр. Аларны төзү теориясен һәм практикасын лексикография өйрәнә. Барлык төр сүзлекләр дә ике төркемгә бүленә: филологик һәм энциклопедик сүзлекләр.

Филологик сүзлекләрдә сүз, аның мәгънә үзенчәлекләре, лексик-грамматик һәм башка сыйфатлары аңлатыла. Аларның аңлатмалы, орфографик, орфоэпик, терминологик, синонимнар сүзлеге һ.б. (бер тел сүзлекләре); русча-татарча, татарча-русча, русча-татарча-инглизчә һ.б. (ике яки берничә тел (тәрҗемәле) сүзлекләре) төрләре була [2: 39]. Энциклопедик сүзлекләр әһәмиятле предметлар, күренешләр, атаклы кешеләр, вакыйгалар һ.б. турында сөйлиләр [1: 88].

Хәзерге көндәге лексикографиянең казанышлары дип өр-яңа типтагы сүзлекләрне әйтеп үтәргә кирәк. Бу – омонимнар сүзлеге, антонимнар сүзлеге, орфоэпик сүзлек, ешлык сүзлекләре, кире (инверсион) сүзлекләр, грамматик дөреслек сүзлекләре, дөрес сөйләм сүзлекләре, телне, илне танып белү сүзлекләре, кыскартылмалар сүзлеге, синтаксик сүзлек һ.б. [3: 208]. Аларга ихтыяҗ зур һәм алар төзелә дә башладылар.

Мәктәпләрдә сүзлекләр белән төп эш лексикология бүлегендә башкарыла. Русча сөйләшүче балаларга татар теле дәресләрендә лексик – грамматик материалны аның сөйләмдә кулланылышына бәйләнешле рәвештә өйрәтергә тырышырга кирәк. Сүзлекләр белән эш нәтиҗәле булсын өчен, эшне 1 нче сыйныфтан ук башлау кулай. Моның өчен махсус сүзлекчәләр булдырыла. Һәр лексик теманы үткән чакта укучылар белән башта бишәр сүз языла. Тора-бара сүзләр күләмен арттырыла. Укучылар язарга өйрәнгәч, басма хәрефләр белән, әкренләп язма хәрефләр белән сүзләр язуны дәвам иттерелә.Уку елы ахырына укучыларга сүзлекләр тәкъдим ителә, кабинетта булган сүзлекләр белән танышу була.

Кызыксындыру максатыннан, укучыларга үзаллы эшләп карау өчен биремнәр бирелә. Шулай итеп, проблемалы ситуация туа: укучылар үзләренең сүзлекләр белән эшли белмәүләрен ачыклыйлар. Сүзлек белән эшләргә өйрәтү берничә этаптан тора:

1. Сүзлекләр белән танышу.
2. Яшь үзенчәлегенә карап, сүзлекләрне тәкъдим итү.
3. Кечкенә проектлар өстендә эшли башлау.
4. Фәнни-гамәли конференцияләрдә катнашу.

Укучылар төркемнәргә бүленә. Һәр төркемгә аерым проект эше тәкъдим ителә. Мәсәлән, “Кыргый хайваннар” темасын үткәндә, һәрбер төркемгә берәр хайван исеме бирелә. Алар башта бирелгән сүзнең төп лексик мәгънәсен ачыклыйлар, сыйфатлар ярдәмендә сыйфатлама төзиләр.

А) Төлке – урманда яши. Ул ит ярата. Төлкенең йоны кабарып тора. Аның койрыгы бик матур (2 нче сыйныф).

Б) Төлке – ерткыч җәнлек. Ул урман тычканнары, куяннар белән туклана. Ул бик хәйләкәр. Төлке җәй көне ябык була. Кыш көне төлке оя ясамый, кар өстендә йоклый (3 нче сыйныф).

Шулай итеп, сыйныфтан сыйныфка эш катлаулана бара. Югары сыйныфлар терминнар сүзлеге, диалектологик сүзлекләр белән эшлиләр.

Сүзлекләр белән эшләү укучыларга файдалы, мавыктыргыч шөгыль булырга тиеш. Дәресләрдә яңа сүзнең мәгънәсе әзер килеш бирелми, укучылар аны эзләп табалар, сүзтезмәләр, җөмләләр төзиләр. Башлангыч сыйныфларда башланган сүзлекчәләр әкренләп калыная, тулылана бара. Мәктәптә сүзлекләр белән эшне башлангыч сыйныфлардан ук оештырганда, укучыларда туган телебезне өйрәнүгә кызыксыну тәрбияләргә мөмкин.

Сүзлекләр татар теленең бердәм лексик нормалары эшләнүнең озын һәм дәвамлы процессын ачык күрсәтәләр. Татар әдәби теленең төп лексикасын, билгеле бер күләмдә архаизмнар, тарихи сүзләр, терминнар һәм лексик диалектизмнарны җыйнап биргән хәлдә, алар татар тел белеменә дә кыйммәтле өлеш кертәләр. Әлеге хезмәтләр татар теленең лексикасын фәнни яктан өйрәнү өчен ышанычлы чыганак булып торалар.

**ӘДӘБИЯТ**

1. Әхәтов Г.Х. Татар теленең лексикасы. Казан, 1995. Б. 88-91.
2. Җамалетдинов Р.Р. Татар һәм рус телләренең чагыштырма грамматикасы. Казан: Казан университеты нәшр., 2004. 39 б.
3. Сафиуллина Ф.С. Тел белеменә кереш. I кисәк. Казан: КДУ, 2001. 298 б.

# Г. ИСХАКЫЙ МӘКАЛӘЛӘРЕНДӘ МИЛЛӘТ ЯЗМЫШЫ ПРОБЛЕМАСЫ

*Муллахмәтова Л., Удмуртия Республикасының социаль-педагогика көллияте, III курс студенты*
*Җит. – Хәкимова В.Х.*

Г. Исхакый – әдәбиятыбызны яңа баскычка алып менгән иллегә якын хикәяләре, повестьлары, романнары белән билгеле язучы. Аларда татар тормышының төрле яклары, төрле проблемалары көн тәртибенә куела. Язучының әсәрләрендә милләт язмышы, аның киләчәге өчен борчылу кызыл җеп булып сузыла.

Шулай ук язучының биш йөздән артык язылган мәкаләләрендә дә милләт язмышы проблемасы төп урынны алып тора. Ләкин, кызганычка каршы, Г. Исхакыйның уникаль тарихи-мәдәни мирас ядкарьләре булып торган бу хезмәтләре тыела һәм рәхимсез цензурага хөкем ителә. Әдәбиятның 1985 елга кадәр өйрәнелмәгән рухи байлыклары арасында Г. Исхакыйның фәнни-публицистик мирасы аерым урын алып тора. Язучының мирасы, күпкырлы эшчәнлеге укучылар һәм тикшеренүчеләр игътибарын үзенең югары сыйфатлы булуы белән генә түгел, ә тарих барышын дөрес бәяләве, мәсьәләне үзенчә аңлавы, татар халкының милли дәүләтчелек төзүгә һәм үзбилгеләнүгә хокуклары өчен көрәшүе белән җәлеп итә.

Г. Исхакый 1893 елда Казанга килә һәм Күл буе мәдрәсәсенә укырга керә. Аның шушы елда «Тәрҗеман» газетасы белән танышуы безгә мәгълүм. Язучының фәнни- публицистик эшчәнлегендә кыйбласын табарга ярдәм иткән матбугат чарасы дисәк тә ялгыш булмас, чөнки 1903 елга кадәр егерме ел буе төрки халыклар өчен чыгып килгән бу бердәнбер газета 25 миллионнан артык кешенең милли үзаңын тәрбияләүдә зур эш башкарган. Газетаны бастырып таратучылар И. Гаспралы һәм З. Акчуриналар алдынгы карашлы татар зыялыларына милли мәгариф, мәдәният, диннең киләчәк тормышыбыз өчен нинди зур әһәмияткә ия икәнлеген аңлата белгәннәр.

1905 ел инкыйлабы татар матбугаты өлкәсенә зур үзгәрешләр алып килә. Инкыйлабка кадәрге чорда бер гасырга якын вакыт буенча газета- журнал чыгарырга рөхсәт ала алмаган татар зыялылары хәзер бу проблеманы җиңел хәл итәләр. 1905 елның 2 сентябрендә татар халкының беренче милли газетасы “Нур” чыга башлый. Ә 1905 ел ахырына дүрт матбугат органы барлыкка килсә,

1906 елда 16 яңа басма пәйдә була. 1905 елда туган “Казан мөхбире” (Казан), “Фикер” (Уральск), “Өлфәт” (Санкт-Петербург) кебек яңа газеталарга 1906 елда “Йолдыз”, “Азат”, “Таң йолдызы”, “Азат халык”,”Идел”, “Урал” һ.б. кебек 16 газета- журнал өстәлә. Ә 1905- 1907 еллар эчендә Россиянең 26 эре шәһәрендә җәмгысе 166 милли матбугат органы нәшер ителә.

Г. Исхакый 1906 елның 18 маеннан “Таң йолдызы” дигән газета чыгара башлый. Ул көндәлек татар матбугатында үз карашларын шактый ачык белдереп бара. 1905-1907 елларда ул төрле татар матбугатында барысы 75 мәкалә бастыра. Мәсәлән, "Хокукый дәүләт турында”, “Тел”, “Хөкүмәт һәм халык”, “Мәктәп-мәдрәсәләр”, “Оренбургтагы Хөсәеневләр мәдрәсәсе”, “Төрмә”, “Дума”, “Татар матбугаты” һ.б. Г. Исхакыйның бу чорда шактый нәтиҗәле эшләвенә дәлил булып тора.

Беренче рус революциясе җиңелеп, 1907-1912 елларда реакция көчәйгәннән соң Г. Исхакый татар халкының тормышын төрле яклап өйрәнә башлый. Аның өчен татар халкына 1552 елгы вакыйгалардан соң милләт буларак яңадан аякка басарга этәргеч биргән рухи- әхлакый ориентирларны билгеләү мөһим иде. Шул максат белән ул үзенең игътибарын татар халкының тормыш-көнкүрешенә, этнографиясенә, матди культурасына, рухи традицияләренә игътибар итә һәм 1909 елдан алып 1917 елга кадәр татар халкы тормышының үзечәлекле якларын үзенең мәкаләләрендә дә яктырта. Язучы фикеренчә, бай тарихка ия булган, кайчандыр чәчәк аткан милли дәүләте булган татар халкы беркайчан да инкыйраз корбаны булмаячак. Г. Исхакый үзенең төрле жанрда язылган һәм төрле тема чагылган күпсанлы мәкаләләрендә милләтнең киләчәген кайгырту, аңа янаган инкыйраз куркынычын киметү, милли яңарыш өчен татар халкының тарихи язмышы яссылыгында чагылдыра.

1913 елдан Санкт-Петербургта “Ил” исемле газета чыгара башлый. Ләкин ике елдан соң патша цензурасы аны яба. Берникадәр вакыттан соң бу газета Мәскәүдә “Сүз” исеме белән чыга башлый, соңрак “Безнең юл” дип үзгәртелә. Г. Исхакый үзе чыгарган газеталарда гына түгел, башка татар газета-журналларында үзенең бик актуаль темаларга язылган мәкаләләрен бастыра. Мәсәлән, “Бәянел хакта” аның “Гаяз” имзасы белән “Татар матбугаты” мәкаләсе басылып чыга. Ул үзенең мәкаләсендә милли газета-журналларының халыкның милли үзаңын үстерүдә әһәмияте,

аларның кирәклеге турында яза. Россиядә яшәүче барча халыкларның бертигез хокукка ия булырга тиешлегенә басым ясый. “Дин әһелләренең эшенә реформа” исеме астында “Япанчы” псевдонимы белән басылган мәкаләсендә дини реформалар ясау кирәклеге турында сөйли. “Хатын-кыз турында” мәкаләсендә җәмгыятьтә хатын-кызның роленә туктала. Язучы үзенең мәкаләләрендә эчүчелек бәласе темасын да яктырта. Шулай ук “Ил” газетасында Г. Тукайның үлеменә бер ел тулган көннәрдә “Милләт трагедиясе” мәкаләсен бастыра. Үзенең мәкаләсендә милләт язмышы турында тирән уйланулары, Тукай трагедиясе, аның бөеклеге, үлемсезлеге турында уйлана. Шулай ук “Сүз” газетасында урын алган “Безнең юл” мәкаләсендә татар милләтен югалудан сакларга кирәклегенә басым ясый.

**ӘДӘБИЯТ**

1. Хакимова В.Х. Кедра Митрей и Гаяз Исхаки: достойные сыновья своих народов. Ижевск, 2015.

2. Исхакый Г. Әсәрләр. 15 томда. Казан: Татар кит. нәшр.,1998-2015.

## «КЕДЕЙЛІК» КОНЦЕПТІСІНЕ ЖАТАТЫН АҚПАРАТТЫҚ ЛЕКСЕМАЛАРДЫҢ КОНЦЕПТІЛІК ҚЫЗМЕТІ

*Мырзағалиева А.С., М. Акмулла атындағы Башқұрт мемлекеттік педагогикалық университеті, II курс магистранты*

*Ғыл. жет. – филол. ғыл. канд., өлк. укыт. Г.Р. Ижбаева*

**«Кедейлік» концептісі** «Байлық» концептісіне қарама-қарсы ең басты концептінің бірі. Кедей болушылық, жарлылық, тапшылық, жетіспеушілік мәніндегі этномәдени менталдық ұғымды білдіреді. Кедейліктің пайда болуының негізгі себептері – экономикалық дағдарыс, жалақы мен зейнетақы минимумының төмендігі, халықтың әлеуметтік тұрғыда нашар қорғалуы. Материалдық кедейлік рухани жұтаңдыққа ұласады [1: 125].

А.Н. Самойловичтің пікірінше, парсының *геда, гедай* сөзінен шыққан *кедей* сөзі Жетісу жерінде бұдан 900 жыл бұрын пайда болған.

Кедейлік әлемнің барлық елдерінде бұрын да болған, қазір де бар. Абайдың айтуынша, «байлықты, кедейлікті жаратқан – құдай, бай қылған, кедей қылған құдай емес деп, нанып ұқсақ болар, әйтпесе жоқ» [3: 412].

*Кедейлік* ұғымының негізінде *жоқ, жоқтық* ұғымы жатыр. Оның концептілік өрісі туралы 2-сызбаны қараңыз.



“Кедейлік” концептісінің концептілік өрісі
(дәстүрлі сөздер)
2-сызба.

**Жоқ концептісі** «жоқшылық» мәнінде «Кедейлік» концептісінің негізінде жатқан, қарапайым сөзбен берілетін этномәдени ұя, негізгі менталдық ұғым. *Жоқ концептісі* «жоқтық» мәнінде кеңістікте бір нәрсенің жоқ екенін білдіретін, бар концептісіне қарама-қарсы концепт. Ақпараттық модельдері: тұрақты тіркестер: *Алты аласы, бес бересі жоқ. Амал жоқ. Жоқ болды. Жоқтан бар етті. Ай дейтін әже, қой дейтін қожа жоқ. т.*б.; мақал-мәтелдер: *Жылқыда өт жоқ, құста сүт жоқ. Құрық тимес құлын жоқ, қырықтық тимес қозы жоқ. Жоқ концептісі* «мақұлдамау» – бір нәрсені, пікірді құптамау, теріске шығару, мақұлдамау мәніндегі этномәдени менталдық ұғымды білдіреді. Мысалы: *Жоқ, біз олай қылмадық, ұзақтай шулап, қарғадай қарқылдап, ауылдағы боқтықтан ұзамадық* (Абай).

**Құл концептісі** «құқықсыз» мәнінде этномәдени менталдық ұғымды білдіреді. Лингвистикалық түсінігі бойынша, *«құл»* – «құлдық, феодалдық дәуірде басында еркі жоқ, барлық құқықтан айрылған, иесінің толық меншігіндегі адам» [2: 232]. *Құл* – қазақтың патриархаттық қоғамынан белгілі. *Құл* сөзінің лингвистикалық код (лексика-семантикалық мағынасы) негізінде туған мәдени-тарихи түсінігі бойынша, *құл концептісі* халықтық өлшемде әлеуметтік деңгейдің ең төменгі сатысында тұрған адамға қатысты символдық ұғымды білдіреді. Концептінің бұл сипаты *құлдық, құл-құтан, құлшылық, құлшар* (құлдың баласы) т.б. лексикалық бірліктерден; *Баталы құл арымас, батасыз құл жарымас.* т.б. мақал-мәтелдерден айқын көрінеді. *Құл концептісі* «пенде, пендешілік» мәнінде тірі жан, адам және кіріптар, біреуге тәуелді деген этномәдени ұғымды бейнелеп білдіреді. *Құдай құлым десе, пайғамбар үмбетім демеске шарасы бар ма?* (А.Шамкенов). Бұл мысалда құл концептісі құдайдың құлы, адам, адамзат мәнін білдіріп тұр. Көне түркі ескерткіштерінде осы мағынада [3: 464].

**Малай концептісі** «жалшылық» мәнінде байларға жалданып күн көретін, есігінде жүретін қызметші, жалшы деген

лингвистикалық түсініктен шыққан этномәдени менталдық концепті болып табылады. Қазан революциясына дейінгі Қазақстанда жиі қолданылған. *Байдың малайы – ашылмаған талабы, малайлық, малайшылық* т.б. сөз қолданыстардан концептінің тілдік моделін көруге болады. *Малай* татар тілінде бала, ер бала.

**Жарлы концептісі** кедей, жоқ-жітік деген лингвистикалық түсініктен шыққан «жоқшылық, жетімсіздік» мәніндегі этномәдени менталдық ұғымды білдіреді. *Жарлы* М.Қашқарида тек «кедей» мағынасында емес, әрі «бақытсыз», «жәбірленген» мәнінде берілген [4: 51]. Жарлы концептісінің ақпараттық деректері қазақ мақалдарынан айқын көрінеді: *Жарлы болсаң, арлы бол. Баймын деп мақтанба, жарлылық бар. Малға жарлылық –жарлылық, ақылға жарлылық – сорлылық* т.б. Концептінің мәні *жарлы-жақыбай, жарлы-жалшы, жарлылық, қара қасқа жарлы* т.б. тіл бірліктерінен де көрінеді.

**Қарашекпен концептісі** «жарлылық» мәніндегі әлеуметтік ұғымды бейнелейді. Лексикалық мағынасы егін, пішен шабу шаруашылығымен айналысушы шаруа. Ақпараттық моделі: *Қарашекпендер, қарашекпенді* негізінен қоныс аударушы орыс шаруаларын (крестьянин) осылай атаудан шыққан. XIX ғасырдың екінші жартысында орыс шаруаларының Қазақстанға қоныс аударып келуіне байланысты көшпелі қазақтардың жартылай отырықшылыққа ауыса бастаған кезінде туған [4: 412]. Қарашекпендердің үлгісімен қазақтар пішен шабу, егін салу, қора салу жұмыстарымен шұғылданған.

Қорыта келгенде, жоғарыда талданған когнитивтік ақпараттар қазақ тіліндегі «Қоғам» макротобына кіретін микротоп «Кедейлік» концептісін қалыптастырып, оған тірек болатын танымдық тіл бірліктері болып табылады. Бұлардың бәрінің басын қосып ұйытқы болып, бір концепті аясына біріктіріп тұрған қазақ қоғамында ежелден белгілі «Кедейлік» концептісі. Оған кіретін тіл бірліктері концептінің компоненттері ретінде өрісін жасайды.

**ӘДЕБИЕТ**

1. Самойлович А.Н. Богатый и бедный в тюркских языках // Известия АН СССР. Отделение общественных наук. 1936. № 4. С. 21-66.

2. Қасым Б. Когнитивті лингвистиканың теориялық негіздері // Қазақ тілі мен әдебиеті және инновация мәселелері. Алматы, 2008. Б. 5-9.

3. Толыбеков С.Е. Кочевое хозяйство казахов в XVII – начале XX века (Политико-экономический анализ). Алма-Ата: Наука КазССР, 1971. С. 464.

4. Ислам. Энциклопедический словарь. Москва: Наука, 1991. 318 с.

# ОСОБЕННОСТИ ИНДИВИДУАЛЬНО-АВТОРСКОГО СТИЛЯ ДЖЕРОМ К. ДЖЕРОМА В ПОВЕСТИ «ТРОЕ В ЛОДКЕ, НЕ СЧИТАЯ СОБАКИ»

*Намакаева З., КФУ, студент II курса*
*Науч. рук. – канд. пед. наук, доц. М.Е. Яшина*

Джером К. Джером (1859-1927) – английский писатель, автор романов, пьес, рассказов, в которых с добродушным юмором, нередко с налетом сентиментальности, повествуется о невзгодах незадачливых обывателей. Произведения Джерома К. Джерома наполнены живым юмором. Писатель неплохо знал быт ремесленников, городских служащих. Его любимый образ – разоренный мелкий буржуа, надеющийся вернуть утраченное, разбогатеть, уверенный, что он будет рано или поздно вознагражден за свои добродетели и страдания. Но самым известным произведением писателя стала повесть «Трое в лодке, не считая собаки».

Тема нашего исследования является **актуальной** так как, разработка вопросов, связанных с основными стилями речи и их функционированием в современном английском языке на материале юмористической повести Джерома К. Джерома «Трое в лодке, не считая собаки» остается малоизученной.

Изучение, теоретический анализ и обобщение методической литературы, самого произведения Джерома К. Джерома «Трое в лодке, не считая собаки» и русскоязычного перевода.

Целью исследования выявить использованные в произведении Джером К. Джерома «Трое в лодке, не считая собаки» стилистические фигуры, которые передают индивидуально-авторский стиль писателя.

Исследования состоит в возможности использования материалов отечественных и зарубежных ученых и выводов по творчеству Джером К. Джерома в дальнейшей работе по исследованию творчества рассматриваемого автора.

Исследование заключается в допустимости использования представленных материалов на лекционных и семинарских занятиях студентов высших учебных заведений, а также на занятиях учащихся старших классов лицеев и гимназий.

Феномен индивидуально-авторского стиля присущ всем видам творческого самовыражения. Стиль может быть не только индивидуальным, но и характерным для определенного периода истории или географической местности. Однако и внутри общего сти-

листического направления эпохи Возрождения, можно легко инфицировать манеры письма Рембрандта или Рубенса.

Индивидуальный стиль писателя, неповторимый, как почерк, позволяет нам узнавать работы по совокупности используемых приемов и визуальных элементов, таких как – манера, конечное решение, выбор сюжетов и техника письма. Никого не удивляет, что, допустим, в художественных произведениях стиль занимает не менее значимое место, чем в других видах искусства. Логично было бы предположить, что писатель или поэт, в своих произведениях использует вполне определенный и присущий только ему набор слов, выражений и оборотов, стихотворный размер и ритм.

1. Целые предложения, которые выступают в качестве фразовых эпитетов. Пример:

*There is a sort of, Oh-what-a-wicked-world-this-is-and-how-I-wish-I-could-do-something-to-make-it-better-and-nobler expression about Montmorency that has been known to bring the tears into the eyes of pious old ladies and gentlemen.*

*Monmorensinin gözlerınde «Ah nekadar kötü bir dünya ben nasil onu güzelleştirebilirim acaba» diyen ifade vardı ve o köpek dindar bey ve bayanlarda gözyaşı döküyordu.*

2. Джером широко использует в произведении как индивидуально-стилистические, так и общеупотребительные метафоры. Например: *We had intended to push on to Wallingford that day, but the sweet smiling face of the river here lured us to linger for a while. O gün bizim Wallingford'a gitmeye niyetimiz vardı, ama nehir tatlı bir tebessüm atarak bizi kalmaya zorladı ve biz gidemedik.*

3. Джером использует олицетворение для изображения природы, которая наделена человеческими чертами: *«We have had a pleasant trip, and my hearty thanks for it to old Father Thames».*

4. Оксюморон – Стилистическая фигура: *That is the only way to get a kettle on to boil up the river. If it sees that you are waiting for it, it will never even sing. Nehir'de kaynar su bulamnın tek yolu budur. Eğer çaydanlık sizin kaynar suyun ıslanmasını sabırsızla beklediğinizi görürse, asla kaynamaz.*

Мы сделали попытку рассмотреть художественный стиль и его функционирование в современном английском языке на примере произведения Джером К. Джером и нами было отобрано 4 единицы лексических приемов.

В языке художественной прозы преобладание одних элементов над другими зависит от жанра литературного произведения. Путем исследования, мы обнаружили, что Джером К. Джером прибегает к использованию таких приемов, как: метафора, олицетворение, фразовые эпитеты.

Проанализировав оригинальное произведение и предоставив вариант нашего перевода, мы пришли к выводу, что перевод художественного текста требует от переводчика творческого подхода, умения учитывать все его особенности и комбинировать все доступные ему средства получения адекватного перевода.

## РУС ТЕЛЕННӘН КЕРГӘН АЛЫНМА СҮЗЛӘРГӘ КУШЫМЧАЛАР ЯЛГАУ МӘСЬӘЛӘСЕ

*Нәбиева Р., КФУ, IV курс студенты*

*Фән. җит. – филол. фән. канд., доц. Р.Р. Сәлахова*

Һәрбер телнең бик күп гасырлар дәвамында формалашып килгән үзенчәлекле лексик фонды бар. Әлеге фондның составына кергән сүзләр төрле тарихи чорларда формалашып, телнең хәзерге сүзлек составын барлыкка китергәннәр һәм сүзлекләргә теркәлгәннәр. Һәр телнең сүзлек байлыгын өйрәнү бик әһәмиятле һәм актуаль мәсьәләләрнең берсе булып санала, чөнки һәрбер сүз – тарихның тере шахите, күренекле бер ядкәре.

Хәзерге җәмгыятебездә урнашкан социаль-мәдәни шартларда безнең татар әдәби телебезгә башка телләрдән, бигрәк тә русчадан күп кенә алынма сүзләр актив рәвештә үтеп керәләр. Әлеге процесс бүгенге көндә бик интенсив бара. Төрле мәдәният вәкилләре белән үзара тыгыз элемтәләрдә тору һәм икетеллелек шартларында яшәү моңа уңай җирлек тудыра, төрле милләтләрнең тел, сөйләм культураларының интеграциясенә китерә.

Татар теле тарихы мәсьәләләре И.А. Абдуллин, М.И. Әхмәтҗанов, Р.Г. Әхмәтьянов, М.Н. Ногман, А.Х. Нуриева, Ф.М. Хисамова, В.Х. Хаков һ.б. хезмәтләрендә җентекләп өйрәнелгән һәм тикшерелгән. Бу өлкәдә эзләнүләр бүгенге көндә дә дәвам итә. Татар теле лексикасының чит телдән кергән сүзләр хисабына тулылануы һәм үсүенә килгәндә, бу проблема татар тел белемендә шактый яхшы өйрәнелгән: Ә.М. Ахунҗанов, Г.С. Әмиров, И.Ш. Әүхәдиев, С.А. Бурнашева, Й.А. Вәлитова, М.И. Мәхмүтов, М.З. Зәкиев һ.б. хезмәтләре әлеге проблеманы яктыртуга багышланган.

Алынма сүзләргә кушымчалар ялгаган очракларда билгеле бер кагыйдәләргә таянып эш итәргә кирәк. Әлбәттә, сүз татар теленең төп закончалыгы – сингармонизм законы турында бара. Әгәр дә сүз нечкә сузык авазлардан торса, нечкә кушымча, ә инде калын сузыклардан торса, калын кушымча ялгана. Сингармонизм законына буйсынмаган сүзләрнең соңгы иҗеге ниндигә тәмамланса (нечкә булса, нечкә ...), сүзгә дә шундый кушымча ялгана. Сүзнең язылышына түгел, ә әйтелешенә игътибар итәргә кирәк. Шушы кагыйдәләргә нисбәтле, рус теле аша кергән алынмаларга кушымчалар ялгану үзенчәлекләрен дә икегә бүлеп карарбыз:

I. Алынмаларга калын кушымчалар ялгану очраклары:

1. Кайбер нечкә тартыкка тәмамланган сүзләр калын төрләнешкә керәләр:

**арь** тезмәсенә тәмамланган сүзләр: фонарь-лар, букварь-дан, рыцарь-лар, алтарь-га һ.б.;

**сть:** повесть-лар, повесть-та, ләкин извесь-ләр, известь-не;

**тань:** пристань – пристань-нар, пристань-га;

**дарь:** календарь-да, сударь-дан, государь-ның һ.б.

**тарь:** секретарь-ны, инвентарь-лар, спортинвентарь-лар, вратарь-га, янтарь-дан, госсекретарь-ның һ.б.

**ерь:** лагерь-га, лагерь-лар, лагерь-ны, пионерлагерь-дан һ.б.

**орь:** якорь – якорь-лар, якорь-га.

Нечкә тартыкка бетеп тә калын төрләнешкә кергән әлеге сүзләргә бер иҗекле тартым кушымчасының нечкә төре (якор-е, лагер-е), ике иҗекле тартым кушымчасының беренче иҗеге – нечкә, икенчесе калын булуын билгеләп үтәргә кирәк (якор-е-быз, лагер-е-быз). Тартым кушымчасы ялганганда, сүздәге соңгы тартыкның нечкәлеген күрсәтә торган ь билгесе төшеп кала, аның вазыйфасын тартым кушымчасындагы нечкә сузык үти.

Мәсәлән: Лагер-ем – лагер-е-быз

Лагер-ең – лагер-е-гыз

Лагер-е – (лагерьлары)

2.-ий кебек хәрефләр тезмәсенә беткән алынмаларга калын кушымчалар ялгана: командующийны, планетарийга, сенарийга – сценариена, санаторийга – санаториена, гербарийга – гербариена, Каспийга, Чайковскийдан, дендрарийда, Горькийны, крематорийга.

Сүзләргә тартым кушымчасы ялганганда, [й+ы] авазлары иҗек башында икесе бер хәреф – е хәрефе белән белдерелә:

сценарий+ы – сценарие

санаторий+ы – санаторие

гербарий+ы – гербарие

3. –ей авазларына беткән алынмаларга калын кушымчалар ялгана: музей-га, юбилей-да, хоккей-ны, ләкин еврей-чә һ.б.

4. –е, -ье, -ью һәм –и сузыгыны тәмамланган алынма сүзләргә дә калын кушымчалар ялгана: кафе-га, отелье-да, жюри-лар, интервью-ны, такси-да, калибри-ны һ.б.

5. –и хәрефенә тәмамланган алынма сүзләргә калын кушымчалар ялгана: калибри-га, такси-да, жюри-га, бумази-ны һ.б.

II. Алынмага нечкә кушымчалар ялгану очраклары:

1. Нечкәлек билгесенә (ь) тәмамланган ай атамаларына нечкә кушымчалар ялгана: февраль-дә, апрель-дә, июнь-дә, июль-дә, сентябрь-гә, октябрь-дә, ноябрь-гә, декабрь-дә

2. Үзләреннән соң һәрвакыт нечкә кушымча таләп итүче аваз һәм иҗекләргә беткән алынмалар:

**ль:** спектакль-гә, циркуль-нең, профиль-профиленә һ.б.

**эль:** дуэль-гә, дуэль-дә.

**ть:** нефть-не, верфе-нә һ.б.

**аль:** деталь-деталенә, педаль-педаль-гә, фестиваль-фестиваль-нең һ.б.

**ень:** мишень-гә, бюллетенен-нән һ.б.

**оль:** тополе-нә, пароль-нең, короле-нә.

**юль:** вестибюль-дә, кастрюль-гә һ.б.

**ель:** никель-не, дизель-дән, порфель-дә, табеле-нә һ.б.

3. Соңгы иҗекләрендә –ия, -ие булган сүзләргә нечкә кушымчалар ялгана: армия-гә, партия-се, экскурсия-дә, бактерия-ләр, консерватория-дә, сочинение-се, расписание-не, предприятие-ләр, переферия-дә, композиция-се һ.б.

4. –ея аваз кушылмасына тәмамланган алынма сүзләргә гадәттә нечкә кушымчалар ялгана: идеясенә, ассамблеясенә, батареясен, оранжереясенә (әмма аллеясына, галлереясына, лотореясына, Кореясына).

Рус теле аша кергән алынма сүзләргә кушымчалар ялгаган очракларда, билгеле бер үзенчәлекләрне дә истә тотарга зарур:

1. завод, пароход, клуб, митинг кебек алынма сүзләрдә соңгы аваз саңгыраулаштырып әйтелә, шунлыктан бу сүзләргә юнәлеш, чыгыш, һәм урын-вакыт килешендә саңгырау аваздан башланган кушымчалар ялгана: заводта, пароходка, клубтан.

2. –ия, -ие, -ль кебек хәреф тезмәләренә беткән алынмаларга гадәттә нечкә кушымчалар ялгана: фамилиянең, учреждениегә.

-ль –гә тәмамланган сүзгә тартым кушымчасы ялганганда, сүз ахырында ь төшеп кала: моделе, моделем, моделебез, моделегез, ләкин III зат, күплек сан тартым кушымчасы ялгаганда, ь билгесе саклана: модельләре.

3. секретарь, календарь кебек алынма сүзләрнең I, II, III зат тартым кушымчалары нечкә – секретарем, календарең, ә килеш кушымчалары калын була: секретарема, календарењны.

4. Икеләтелгән с, л, м тартыкларына тәмамланган алынма сүзләргә шундый ук тартыктан башланган кушымча ялганган очракларда, ике тартык кына языла: металл + лы – металлы, кристалл + лар – кристаллар, класс + сыз – классыз, стресс + сыз – стрессыз. Әлеге сүзләргә тартым кушымчасы ялганган очракларда, икеләтелгән с, л, м кебек тартыкларның берсе төшеп кала: металы.

5. Смоленск, Ульяновск кебек –ск авазларына беткән сүзләргә килеш кушымчалары алдыннан –и өстәлә: Смоленскига, Ульяновскидан һ.б.

6. Алынма сүзләргә кушымча ялгаганда, аваз үзгәреше мәсьәләсендә төрлелек күзәтелә: темп-темпы, ләкин тип-тибы, һ.б.

а) темп-темпы кебек мисалларда татар теленең тартым кушымчасы ялганганда да, сүз азагында п саклана.

б) тип-тибы кебек мисалларда п тартыгы б белән чиратлаша, бу чиратлашу язылышта да чагылыш таба.

Бу сүзләр бер орфографик принцип нигезендә язылырга тиешләр, ләкин әлеге очракта татар теленең кагыйдәләр системасында алынмаларда аваз чиратлашуы билгеле бер нормага, тәртипкә салынмаган. Алынма сүзләргә кушымчалар ялгаганда килеп чыккан кыенлыклар әле моның белән генә чикләнми. Ике янәшә урнашкан тартыкка тәмамланган сүзләргә кушымчалар ялгаганда, аларны тартым белән төрләндергәндә билгеле бер системалалык юк. Әйтик, продукт, пропуск, киоск, отпуск, диск, прииск, нерв, лозунг, консерв сүзләрен, тартым белән төрләнмәгәндә дә, продукты, отпускы, пропускы, киоскы, дискы, прииска, нервы, лозунгы, консервы формасында куллану урынлы булыр иде, чөнки аларның рус телендәге формасына тартым яки инкаръ итү кушымчалары ялгап әйтү артикуляцион яктан да, мәгънә ягыннан да уңышлы чыкмый. Мәсәлән, әлеге сүзләргә – сыз/-сез кушымчалары ялганганда, аларның артикуляцион яктан

әйтелешләре авырая: пропуск-сыз, диск-сыз, киоск-сыз, отпуск-сыз. Шуңа күрә бу сүзләр пропускысыз, отпускысыз, дискысыз рәвешендә табигыйрәк яңгырый.

Әлеге сүзләрне килеш белән төрләндергәндә дә, тамыр белән килеш кушымчасы арасына ы сузыгы сорала: отпуск-ы-ның

Менә шул якларны искә алганда, әлеге сүзләрне язганда бердәм орфографик кануннарны истә тотып язу кагыйдәләрен булдыру уңышлы булыр иде. Югыйсә, әлеге өлкәдә төрлелек хөкем сөрә. Моны дәлилләү максатыннан, без әдәби әсәрләргә дә күз салдык: ...Һичбер кешене пропускысыз үткәрмәгез, пропуск сорагыз (Ф. Сәйфи-Казанлы). *Отпуска алдым* (Ә. Еники). – Сез, – диде, – вакытлы отпускка китәсез (М. Мәһдиев). Балык консервасын ашатканда, кояш иңә башлаган иде (М. Мәһдиев). *Агай борылып керде дә консерва тартмасын ачарга кереште. ...безнең анда виноларыбыз, консерваларыбыз бар* (М. Гали). *Нервлары кузгалган кешенең аппетиты бик яман ачылып китә, имеш* (Ә. Еники). *Хәбиб, син арыгансың, нервыларың да кузгалган* (Ә. Еники). *Әллә җәннәт сельпосыннан / Продукты ташыйлар алар?* (Ш. Галиев).

Алынма сүзләрнең күбесе график принцип нигезендә чыганак телдәгечә язылса да, алар телебезнең морфологик күрсәткечләрен кабул итәләр һәм сүзъясалыш процессында да бик актив катнашалар. Вакытлы матбугат битләрендә әлеге күренешкә бик күп мисаллар табарга мөмкин. Әлеге максаттан, без «Мәгариф» журналына күзәтү ясадык. «*Толерантлык сүзе һәр телдә үзгә мәгънә төсмеренә ия. Мәсәлән, инглиз телендә толерантлык – шәхесне яки ситуацияне каршылыксыз кабул итәргә әзербулу; француз телендә – икенче бер шәхеснең иреген,үз-үзен тотышын, сәяси һәм дини карашларын хөрмәт итү, кытай телендә – башкаларга карата игътибарлы булу, киң күңеллелек күрсәтү*». Мисалдан күренгәнчә, толерантлык сүзе нигезгә –лык кушымчасы ялгану юлы белән ясалаган (толерант+-лык). Әлеге сүз рус телендә толерантность буларак кулланыла. Татар теленә үтеп кергәч, ул берникадәр үзгәреш кичергән, ягъни татар теленең морфологик күрсәткечләрен кабул итеп, яңа лексик берәмлек ясаган.

Нәтиҗә ясап әйткәндә, алынмаларга татар телендә кушымчалар ялгау мәсьәләсе бүгенге көндә бик аз өйрәнелгән икәнен дә ассызыклап китү зарур. Бу өлкәдә әле ачыкланып бетмәгән моментлар бик күп. Мәсәлән, темп сузе тартым белән

төрләнгәндә аның нигезендә п хәрефе сакланып кала (темпы), ә тип сүзендә аваз чиратлашу күренеше күзәтелә (Тип-тибы).

Алынма сүзләргә кушымчалар ялгану мәсьәләсе бу очракта басым үзгәрешләре, аваз чиратлашуы мәсьәләләре, фонетик үзгәрешләр һәм орфографик закончалыклар һәм нормалар нигезендә махсус рәвештә каралырга лаек. Без әлеге теманы нәкъ тә менә шушы принциплар кысаларында яктыртырга тырыштык.

**ӘДӘБИЯТ**


1. Абдуллина Р.С. Хәзерге татар теленең орфографиясе һәм орфоэпиясе: югары һәм урта махсус уку йортлары студентлары өчен уку әсбабы. Казан: Мәгариф, 2009. 239 б.
2. Алпаров Г.Х. Сайланма хезмәтләр (татар грамматикасы һәм гомуми тел белеме мәсьәләләре). Казан: Татгосиздат, 1945. 330 б.
3. Ганиев Ф.Ә. Хәзерге татар әдәби телендә сүзьясалышы: төзәт. 3 нче басма. Казан: Мәгариф, 2009. 271 б.
4. Мифтахов Б.М. Татар орфографиясе һәм пунктуациясенең кыен очраклары. Казан: Татар. кит. нәшр., 1970. 160 б.
5. Сафиуллина Ф.С. Тел дигән дәрья бар... Казан: Татар. кит. нәшр., 1979. 136 б.


## М.МӘҺДИЕВНЕҢ "БЕЗ – КЫРЫК БЕРЕНЧЕ ЕЛ БАЛАЛАРЫ"Н УРТА МӘКТӘПТӘ ӨЙРӘНҮ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ


*Нигъмәтҗанова А., КФУ, Алабуга институты, V курс студенты*

*Фән. җит. – филол. фән. канд., доц. Г.Ф. Даутов*


Татар әдәбиятына фәнни игътибар соңгы берничә дистә елда, чыннан да, бермә-бер арта: яңа китаплар бастырылып чыгарыла, фәнни хезмәтләр языла. Әмма әдәби мирасны балаларга җиткерү юллары, төгәлрәк әйткәндә, татар әдәбиятын укыту методикасына кагылышлы хезмәтләр әлегәчә бик аз дәрәҗәсендә. Шул рәвешле, мәктәптә татар әдәбиятын өйрәнүнең эффектив юлларын эзләү хәзерге методика фәненең төп бурычларының берсе булып кала. Әлеге фәнни эшебез кысаларында Мөхәммәт Мәһдиевнең "Без – кырык беренче ел балалары" әсәрен мәктәптә өйрәнүне тикшерербез. Бу повесть әдипне талантлы язучы итеп таныткан, геройлары картайса да, әсәре үзе мәңге яшь калган үзенчәлекле әдәби ядкяр. Әсәрнең теле дә җиңел аңлашыла, урта мәктәпнең беренче баскычларында ук, ягъни бишенче, алтынчы сыйныфларда ук тәкъдим ителә ала.

Билгеле булганча, дәреснең нәтиҗәлелеге күп кенә факторларга бәйле булып, укытучы шәхеснең компетентлылыгы, дәресне дөрес оештыра белүе, сөйләм үзенчәлекләре, укучыларга

мөнәсәбәте дә зур роль уйный. Фәнни эшебезне башкару дәвамында безне проблеманың гамәли чишелеш ягы кызыксындырды, без интернет челтәрендә мөгаллимнәрнең сайтларында урнаштырылган дәрес планнары, конспектлар белән таныштык. Тулаем караганда, тәкъдим ителгән эшләр уңай тәэсир калдырды, укытучылар кызыклы презентацияләр белән дәресләрне җанландыралар, әсәрнең әһәмиятен кызыклы алымнар аша ассызыклыйлар. Әмма кайбер аспектлар бездә каршылыклы хисләр уятты. Мәсәлән, бер укытучы дәрес-презентациясендә мондый фикер җиткерә: "үткәрелгән проблемалар бүгенге көндә дә бик актуаль, чөнки төп тема – авыр сугыш елларында тылдагы тормыш вакыйгалары" [2]. Безнең фикеребезчә, әсәрнең әһәмияте, актуаль яңгырашы андагы тормышка, яшәүгә мәхәббәтнең ачык яңгырашы белән аңлатыла, бүгенге чор белән актуальлекне сугыш чоры тылы тормышы сурәтләнү белән аңлату бик үк дөрес түгел. Беренчедән, мондый аңлату укучыны ышандырмаячак, ышандырган очракта исә укучыда хәзерге әдәбиятта сугыш авырлыгы, тыл тормышын сурәтләгән әсәрләр генә актуаль икән, дигән дөрес булмаган караш формалашачак. Икенчедән, укытучы дәресне сугыш чоры һәм хәзерге балаларны чагыштырып, хәзерге балаларның рәхәт тормышта яшәп тә белемгә омтылмавын тәнкыйтьләүне алга сөрә, повестьнең кыйммәтен дә шунда күрә: "Без – кырык беренче ел балалары"н укыган һәрбер өлкән сыйныф укучысы үзен әсәрдәге яшьтәшләре белән һәм авыр сугыш еллары белән хәзерге рәхәт тормышны чагыштыра ала. Әлеге повесть аларга бу яктан үрнәк булырлык! "Без – кырык беренче ел балалары" әсәре хәзерге яшьләрне бүгенге рәхәт тормышның кадерен белергә өйрәтә" [2]. Эшнең корылышы белән тамырдан килешмибез, уйлавыбызча, әсәрнең юмор белән өртелгән яңгырашын узган буынны мактап, хәзерге буынны тәнкыйтьләү белән бозарга ярамый.

"Без – кырык беренче ел балалары" повестен татар мәктәпләрендә җиденче сыйныф укучылары белән өйрәнү үзенчәлекләренә тукталыйк. Программа буенча моңа ике сәгать вакыт бирелеп, берсе әдипнең тормыш юлы һәм иҗатына күзәтү өчен, икенчесе – әсәрне укып анализлау өчен каралган. Безнеңчә, шунысы әһәмиятле: биографияне өйрәнү дәресендә төп басым әдипне әдәбиятта үзенчәлекле юл табуга этәргән фактлар белән танышуга төшәргә тиеш. М. Мәһдиевнең "Без – кырык беренче ел балалары" повестен өйрәнүгә әзерлек буларак әдип биографиясен

өйрәнгәндә, язучының кайларда белем алуы, педагогик эшчәнлегенә игътибар итү дә мөһим. Әсәрдәге вакыйгалар Арча педагогия училищесына бәйле булганлыктан, биография өйрәнү дәресендә әлеге уку йортының фотосурәтләрен, училище укытучылары белән М. Мәһдиевнең очрашу мизгелләрен сурәтләгән фотолар, слайдлар белән баету да максатка ярашлы.

Алга таба дәреснең төп вакыты әсәрне укып анализлауга бирелә. Билгеле булганча, язучының үзенчәлекләрен искә алып, бер әсәрне өйрәнү образлар бирелешен анализлау юнәлешендә, икенчесе – бирелгән проблемаларны чишелеш үзенчәлеге юнәлешендә алып барыла. "Ике аспектка игътибар бирү кирәк: 1) вакыйгаларның сугыш чоры фонында бару ("Миләрдә ике-өч кенә сыр бар. Беренчесе – сугыш, икенчесе – ашау" фразасын анализлау өстендә эш алып барыла); 2) повесть үрнәгендә укучылар язучының индивидуаль стиле турында төшенчә алуы. Бу яктан повестьтә юмор тудыру чараларын анализлау максатка ярашлы. Мәсәлән, юмор тудыру чарасы буларак бүлекләрнең исемнәре өстендә эшләргә мөмкин: "Онегин су алырга чират тора", "Гренландиядә тәмәке үсә", "Император Веспасиан чәй эчә" һ.б.лар. Шулай ук, юмористик ситуация хасил итүдә фонетик чараларның ролен өйрәнергә мөмкин. Бу яктан "Гренландиядә тәмәке үсә" бүлегендә сурәтләнгән вакыйгаларны искә алу урынлы. Мисал итеп, рус теле укытучысының Гыйззәтуллиннан "Что было задано на дом?" соравына җавабын языйк: "*– Назание да ном... Надано за дом... Занадо за ном... – дип озак газапланды, тирләде*" [1: 38].

Шул ук бүлектә Гыйззәтуллин түбәндәге география, зоология дәресләрендә дә хаталар ясый: ярымшарлар картасын – шарымъярлар картасы; елга хламидомонадасын – елга Хәмидулла анасы; саф һаваны – хаф сава дип әйтә. Әлеге урыннарны укып анализлау да балалар өчен кызык һәм дәреснең танып белү максатына ирешү өчен нәтиҗәле алым булып тора.

Гомуми йомгак ясап, шуны искәртик: М. Мәһдиев иҗаты мәктәп программасында лаеклы урын ала, аның уйландыра торган әсәрләре зур тәрбияви көчкә ия булып торалар, җитди проблемаларны чишү ихтыяҗын күз уңына китереп бастыралар.

**ЛИТЕРАТУРА**

1. Мәһдиев М. Әсәрләр. К.: Мәгариф, 2005. 271 б.
2. Презентация на тему "Без – 41 нче ел балалары". URL: https://infourok.ru/prezentaciya-na-temu-po-tatarskomu-yaziku-mmdiev-bez-nche-el-balalari-539163.html

# “КӨЗ” СҮЗЕНЕҢ ЛЕКСИК-СЕМАНТИК МӘГЪНӘЛӘРЕ
## (мәкаль һәм әйтемнәр мисалында)

*Нуретдинова И., КФУ, II курс магистранты*
*Фән. җит. – филол. фән. канд., доц. Г.Ф. Җамалетдинова*

Дөнья тел картинасын анализлау өчен паремияләрне, ягъни мәкаль һәм әйтемнәрне анализлау мөһим дип исәплиләр.

Паремияләр халыкның культура һәм иҗтимагый тарихын, этнографиясен өйрәнү ягыннан күп кенә материаллар бирә алалар. Мәкальләрдә халыкның көнкүреше, материаль культурасы, гадәт, йола этнографиясе, хокукы һәм башка мөнәсәбәтләре бик конкерт сызыкларда чагыла һәм кайберләре турыдан-туры берәр тарихи кеше авызыннан әйтелгән булулары белән халыкның ул вакыйгага мөнәсәбәтен ачу ягыннан да беренче кул материал була ала.

Беренче карауга каршылыклы күренгән мәкальләр аша без татар халкының рухи йөзе, психологиясе турында шактый кызыклы һәм эзлекле фикерләр ясый алабыз. Материаль культурасы хакында гына түгел, рухи өйзе, психикасы турында да бик мөһим бер сурәтләмә хасил итә алабыз. Мәкальләрнең гореф-гадәт, көнкүреш кагыйдәчелеге урынын тотып килүе аның бер өлеше әхлакый норма буларак роль уйнап килүен дә күрсәтә.

Паремияләр халыкның сөйләм телендә барлыкка килгәннәр. Алар халыкның дөнья күзаллавын, фикер йөртү ысулын һәм башка үзенчәлекләрен чагылдыра. Шуңа күрә алар телнең милли колоритын сурәтли.

Ел фасыллары, универсаль (күпкырлы) категория саналган, вакыт төшенчәсе, вакыт категориясе экспликациясен, табигый вакыт буларак, конкрет реальләштерү (тормышка ашыру) һәм турыдан туры кешенең дөньясы белән бәйле буларак, теләсә-кайсы халыкның дөнья картинасында мөһим урын алып тора.

Кешенең дөньяны темпораль күзаллаулары – ул, шәхеснең күз алдына китерү көче (ә ул үз чиратында дөньяны фәлсәфи аңлау белән катлаулана) ярдәмендә тудырылган, реаль вакытны чагылдыручы аерым бер форма.

“Көз” татар халкының дөнья тел картинасында “көз” лексемасының, чыгарылма (производные) “көзге”, “көз алдыннан”, “көзгечә”, “көзен” һәм башка сүзләре аша реальләшә.

Еш кына татар сөйләм телендә көз язга капма-каршы куела, яки яз белән чагыштырыла. Мәсәлән: “Көзге көннән язгы төн яхшы”, “Яз белән көз ала бия белән йөриләр” һ.б.

Көз лексемасы еш кына “салкын ел фасылы” буларак та телгә алына, ә антиномия түбәндәге принцип буенча төзелә: көз – “уңыш, байлык”, “пычрак, дымлылык”. Татар милли характерының мөһим үзенчәлеге булган татарлык билгесе дип еш кына ихтыярсыздан барлыкка килгән, көз белән бәйле, моңсулык, кайгы, сагыну хисләрен атыйлар. Һәм шунысын да әйтергә кирәк, еш кына көзге депрессия, көзге күңел төшенкелеге, эч пошу, кәефсезлек, һава торышы (коры, суык, салкын, яңгыр, җил һ.б) мотивлары да барлыкка килә. Мисалларга тукталып китик:

**Моңсулык, сагыну хисләре, көзге күңел төшенкелеге:**

а) Көз килеше җәеннән билгеле.
ә) Саран мәхәббәт көзге кояш кебек кадерле.
б) Гашыйкка яз да яз, көз дә яз.
в) Көзен шиңсә, язын чәчәк атар.
г) Көтә-көтә көз булыр.
д) Хатын-кызның күңеле көзге болыт шикелле.
е) Егетлек – гөлбестан, картлык – көзге кырау һ.б.

**Кыр эшләре, уңыш җыю, муллык, ашлык:**

а) Көзге катык – көмеш кашык;
Язгы катык – ярык кашык.
ә) Көз көне азык ал.
б) Күз өчен яз яхшы,
Авыз өчен көз яхшы.
в) Көзге ашлыкны көлгә чәч.
г) Көзге ашлыкны көлгә чәч,
Язгы ашлыкны бозга чәч.
д) е) Яз сөрсәң, көз урырсың һ.б.

Һава торышы (коры,суык, салкын, яңгыр, җил):
а) Көзге суыктан саклан.
ә) Көз килеше җәеннән билгеле.
б) Бер карлыгач белән яз булмый,
Бер болыт белән көз булмый.
в) Язгы җил – рәхәт бирүче,
Көзге җил – һәлак итүче.
г) Көз җир сөр, кыш кар сөр.
д) Тычканнар кибән астында торсалар, көз коры булыр.
е) Бозлар көз көне шадра булып катса, ашлык яхшы булыр.
ё) Искечә 1 сентябрьдә җылы булса, бөтен көз җылы булыр.

**Кошлар белән бәйле билгеләр:**

а) Көз киткән каз яз кайтыр.

ә) Тургай түбәннән очса, көз кыска булыр.

б) Бытбылдык Питрау алдыннан сузып кычкырса, көз озын булыр.

в) Әгәр кыр казлары, көз көне киткәндә, биектән очып китсәләр, кыш салкын булыр, ләкин ашлык яхшы булыр.

Татар дөнья тел картинасында көз образы лингвистик чаралар ярдәмендә дә формалаша. Алар үз чиратында лингвокультурологик төшенчәләр аша мәкаль, мәкаль нигезендәге сынамышлар, бәйрәмнәр һәм гореф-гадәтләрдә реализацияләнә.

**ӘДӘБИЯТ**


1. Телия В.Н. Русская фразеология. Семантический, прагматический и лингвокультурологический аспекты. М.: Языки рус. культуры, 1996. 288 с.
2. Корнилов О.А. Языковые картины мира как производные национальных менталитетов. М.: ЧеРо, 2003. 349 с.
3. Исәнбәт Н. Татар теленең фразеологик сүзлеге. Казан: Татар. кит. нәшр., 1989. Т. III. 495 б.


## КОНЦЕПТ ЦВЕТА В СВЯЩЕННОМ КОРАНЕ: ЛИНГВОКУЛЬТУРОЛОГИЧЕСКИЙ АСПЕКТ


*Нуруллаев А., Лесосибирский педагогический институт – филиал СФУ, студент V курса*

*Науч. рук. – канд. филол. наук, доц. Н.А. Мазурова*


Цвет в Исламе – это важнейшая категория мусульманской идеологии. красный, насыщенный синий или совершенно черный – это, несомненно, является отличительной чертой исламской колористики, в то время как у европейской культуры и восточной фундаментальной можно наблюдать смешанные цвета (красно-черный, желто-зеленый): أَلَمْ تَرَ أَنَّ اللَّهَ أَنْزَلَ مِنَ السَّمَاءِ مَاءً فَأَخْرَجْنَا بِهِ ثَمَرَاتٍ مُخْتَلِفًا أَلْوَانُهَا ۚ وَمِنَ الْجِبَالِ جُدَدٌ بِيضٌ وَحُمْرٌ مُخْتَلِفٌ أَلْوَانُهَا وَغَرَابِيبُ سُودٌ

«Неужели ты не видишь, как Аллах ниспосылает с неба воду, посредством которой Мы взращиваем плоды различных цветов. В горах также есть различные тропы – белые, красные и совершенно черные» (сура «Ан-Намль», аят 45).

В Коране символика цвета достигла своего апогея. Как известно, исламская культура запрещает изображения человека или животного, именно поэтому цвет стал ключевым художественным средством в выражении взглядов мусульман. Белый, черный, зеленый, синий, красный, желтый – все это многообразие цветов несет в себе отличающую друг от друга образность, глубинный смысл.

**Белый** считается первым в Исламе – это цвет небесной чистоты и святости. Он несет в себе благо для человека. Сура «Аль-Бакара», аят 187:

أَتِمُّوا ثُمَّ ۚ الْفَجْرِ مِنَ الْأَسْوَدِ الْخَيْطِ مِنَ الْأَبْيَضُ الْخَيْطُ لَكُمُ يَتَبَيَّنَ حَتَّىٰ وَاشْرَبُوا وَكُلُوا الْمَسَاجِدِ فِي عَاكِفُونَ وَأَنْتُمْ تُبَاشِرُوهُنَّ وَلَا ۚ اللَّيْلِ إِلَى الصِّيَامَ

«Ешьте и пейте, пока вы не сможете отличить белую нитку рассвета от черной, а затем поститесь до ночи».

Сура «Аль-Араф», аят 108: لِلنَّاظِرِينَ بَيْضَاءُ هِيَ فَإِذَا يَدَهُ وَنَزَعَ

«Затем он вытащил руку, и она стала белой (цвета молока, светящейся) для тех, кто смотрел на нее».

В церемонии погребения белый цвет считался символом сопровождения в последнюю жизнь.

**Зеленый** цвет считается главным, священным в Исламе – это цвет Рая в культуре мусульман, покоя и безопасности. Также он был одним из любимых цветов Пророка, выражающим единение человека и природы. Сура «Аль-Инсан», аят 21: خُضْرٌ سُنْدُسٍ ثِيَابُ عَالِيَهُمْ طَهُورًا شَرَابًا رَبُّهُمْ وَسَقَاهُمْ فِضَّةٍ مِنْ أَسَاوِرَ وَحُلُّوا ۖ وَإِسْتَبْرَقٌ

«На них будут зеленые одеяния из атласа и парчи. Они будут украшены серебряными браслетами, а Господь их напоит их чистым напитком».

**Синий** считается спокойствием в Исламе – это цвет ночи и смерти. Также использовался в церемонии погребения, как и белый цвет. Сура «Та Ха», аят 102: زُرْقًا يَوْمَئِذٍ الْمُجْرِمِينَ وَنَحْشُرُ ۚ الصُّورِ فِي يُنْفَخُ يَوْمَ

«В тот день подуют в Рог, и в тот день Мы соберем грешников синими (синеглазыми)».

**Желтый**, второй в Исламе – это цвет радости, золота, солнца. Сура «Аль-Бакара», аят 69: يَقُولُ إِنَّهُ قَالَ ۚ لَوْنُهَا مَا لَنَا يُبَيِّنْ رَبَّكَ لَنَا ادْعُ الُوا النَّاظِرِينَ تَسُرُّ لَوْنُهَا فَاقِعٌ صَفْرَاءُ بَقَرَةٌ إِنَّهَا

«Он сказал, что эта корова светло-желтого цвета. Она радует смотрящих на нее».

Сура «Аль-Мурсалат», аяты 32-33: كَالْقَصْرِكَأَنَّهُ بِشَرَرٍ تَرْمِي إِنَّهَا صُفْرٌ جِمَالَتٌ «А он бросает искры, подобные замку, который выглядит словно желтые верблюды».

**Красный,** третий в Исламе – это цвет, который является символом огня, света и крови, которая несет в себе жизнь.

Сура «Ас-Саффат», аят 78: كَالدِّهَانِ وَرْدَةً فَكَانَتْ السَّمَاءُ انْشَقَّتِ أَفَإِذَا

«И вот небо разверзнется и станет красным, как кипящее масло (или покрасневшая кожа; или расплавленный свинец)».

Сура «Аль-Анам», аят 29: سُجِّرَتْ الْبِحَارُ وَإِذَا

«…Когда моря станут красными».

**Черный цвет** несет двоякое значение в Исламе: положительное и отрицательное. В первом случае – это цвет тайны мироздания, недаром священный камень, который является частью Каабы в Мекке черного цвета, а с другой стороны, он может являться символом нечистой совести, грязных мыслей и грехов.

Сура «Аль-Аля», аяты 4-5: وَالَّذِي أَخْرَجَ الْمَرْعَىٰفَجَعَلَهُ غُثَاءً أَحْوَىٰ

«Который произрастил зеленые луга, потом поверг их в сухое, потом в черное состояние».

Арабская культура отличающаяся от других. Она открывает новый пласт восприятия и ощущения мира и в этом, несомненно, ее неоспоримая ценность. Конечно, она имеет свою ограниченность, но это, ни есть нечто негативное – наоборот, колористика позволила отточить и довести знания до относительного совершенства, а также она достигла предела своего развития в исламской художественной культуре. Нечто новое уже не способно в ней появиться – это драгоценный камень в сокровищнице мусульманского духа.

**ЛИТЕРАТУРА**

1. Коран. Перевод смыслов. М.: Эксмо, 2014. 688 с.

## С. ДАНИЛОВ САХА СИРИГЭР ТЫЛБААС САЙДЫЫТЫГАР КЫЛААТА

(«Чолбон» сурунаал матырыйаалынан)

*Олесова М., Северо-Восточный федеральный университет им. М.К. Аммосова, магистрант I курса*

*Науч. рук. – канд. филол. наук, доц. И.В. Собакина*

Семен Петрович Данилов – саҥа үйэ, саҥа олох, саҥа саха ырыаһыта. Кини саха норуотун кутун-сүрүн дириҥник иэйэн этэр чахчы улахан суруйааччы, сүдү поэт. Кинини биһиги суруйааччы эрэ курдук буолбакка, талааннаах тылбаасчыт быһыытынан эмиэ билэбит. Кини киһи быһыытынан дьону, киһини хайдах эрэ биллибэтинэн бэйэтигэр тардар, уһулуччу номоҕон, ис киирбэх майгылааҕа. Семен Петрович Данилов бүтүн айымньытынан уонна салайааччы быһыытынан дьаныһан туран мөккүспүт биир мөккүөрүнэн төрөөбүт литэрэтиирэбит ырын кэҥэтии, кини киэҥ далааһыннаах, дириҥ эҥсиилээх буолуутугар дьулуһуу этэ.

1926 с. “Чолбон” литэрэтиирэлии сурунаал айыллан, бэчээттэнэн тахсыбыта. Бу сурунаалга Семен Данилов “Литэрэтиирэлэр доҕордоһуулара – норуоттар доҕордоһуулара”

диэн бүтүн сойуустааҕы хамсааһыны тэрийбитэ. “Друзья-поэты” диэн суруйааччы атын норуот суруйааччыларын айымньыларын сахалыы тылбааһын хомуйан таһаарбыт кинигэлээх. Кинигэҕэ аата да этэринии, суруйааччы чугастык билсэр, доҕордуу табаарыстарын үлэлэрэ киирбиттэр. Ол табаарыстара нуучча, украина, чуваш, армян, киргиис, тувин, калмык, узбек, латыш, татаар, дагестан суруйааччылара [1: 111].

“Чолбон” сурунаалга уопсайа 1385 тылбаас айымньы бэчээттэммит. Манна жанр араас көрүҥүттэн проза быдан баһыйар эбит. Семен Петрович Данилов 62 тылбаастаабыт айымньыта бэчээттэммит. Бу саамай үрдүк көрдөрүү буолар.

Кини араас омук суруйааччыларын айымньыларын тылбаастаабыт. Ол курдук нуучча суруйааччыларыттан: А.С. Пушкин, Ю.И. Шамшурин, М.Ю. Лермонтов, П. Дорошко, Л. Украинка, С. Шевков, М. Львов, Р. Гамзатов, иран суруйааччыларыттан: Джавахири, башкир суруйааччыларыттан: М. Карим, Г. Рамазанов, бурятия суруйааччыларыттан Д. Жалсараев, Ш. Нимбуев, Нигерия суруйааччыларыттан: А. Нету, Чехия суруйааччыларыттан: С. Костка Нейман, Я. Смрек, Ф. Бранислав, саха суруйааччыларыттан: С. Шевков айымньыларын тылбаастаабыт. С. Данилов ордук 1978 сыллаахха умсугуйан олорон тылбаастаабыта.

Кини тылбаастыырыгар тыл этигэн ньымаларын хайдах таба туттар эбитий диэтэххэ маннык:

Тыыннааҕымсытыы: *ночные тротуары – түүн үөһэ чуумпурбут суол, неповторимый свет – атынныын алтыспат уот*. Түүҥҥү уулуссаны киһилии тыыннаан, аймалҕана суох уулусса туругун көрдөрөр, хатыламмат уоту кимниин да сыһыаннаспат диэн ис хоһоонноох тылбаастаабыт.

Эпитет: *любовь – сырдык таптал, стремился к свету – улуу сырдыгы көрдүүбүн*. Тапталы сырдык иэйии курдук көрөр, сырдыкка талаһыыны үрдүктүк саныыра көстөр.

Гипербола: *это слезы и кровь несгибаемой Польши – дойдум хараҕын уута, хаана халаанныы хальйдын*. Польша хараҕын уутун, хаанын сааскы халаан уутугар майгыннатан, тыл суолтатын күүһүрдүбүт.

Метафора: *любил – күн санаа, это я Марию полюбил – миэхэ күн буолара Мария*. Бу Семен Данилов ураты ньымата дии саныыбын. Таптал уобараһын үрүҥ күҥҥэ тэҥниирэ киһи кутун долгутар. Тэҥнэбил: *душой робея жду смущенно – оҕолуу кэмчиэрэ,*

*кыбыста оҕонньор туох диирин күүтэбин*. Сэмээр кыбыстар санааны кыра оҕоҕо тэҥнииир.

Ханыыласпыт тыллар: *и ленивою рукою подымает он окно – аҥнар-бохтор онтон аанын арыйар*. Оҕонньор бытаан, сыылба хамсаныытын Семен Данилов ханыыласпыт тылынан солбуйбута саха тылын уус-уран тылларынан баайын дакаастыыр.

Семен Данилов тылбаастыырыгар төрөөбүт тылын мэлдьи өрө тутара, ураты солбуктарын киһи олус сэҥээрэ ааҕар. Семен Данилов тылбаас сайдыытыгар өҥөтө улахан. Кини баар буолан тылбаас саха сиригэр бу күҥҥэ дылы салгыы сайда турар.

**ЛИТЕРАТУРА**

1. Данилов С.П. Друзья-поэты. Очерки и переводы. Якутск, 1963. 111 с.

## СЛОВЕСНОЕ УДАРЕНИЕ В ЯКУТСКОМ И ХАКАССКОМ ЯЗЫКАХ

(в сравнительно-сопоставительном аспекте)

*Портнягина Л., Северо-Восточный федеральный университет, магистрант II курса*

*Науч. рук. – докт. филол. наук, проф. И.Е. Алексеев*

Целью настоящей работы является выявление определения экспериментально-фонетическими методами акустические параметры словесного ударения некоторых двусложных слов якутского и хакасского языка, детерминирующие его природу.

Словесное ударение – это выделение одного из слогов фонетического слова по какому-либо параметру или комплексу параметров. Потенциальными характеристиками ударения в общей фонетике принято считать показатели квантитативности, интенсивности, тональности и напряжённости, которые в отдельных языках сочетаются в различных комбинациях.

В данной работе применена комплексная методика, включающая как субъективные методы аудитивного наблюдения автора и учета показаний информантов, так и методы экспериментально-фонетического исследования. Регистрация экспериментального материала на электронные носители осуществлялась с использованием диктофона, последующая обработка – с помощью компьютерной акустической программы SpeechAnalyzer. По результатам фонемной сегментации и последующей обработки акустических показателей будут выявлены количественные параметры просодических

коррелятов ударения: ЧОТ, длительности, формантной структуры гласных и интенсивности слогообразующего гласного.

В якутском языке ударение постоянное. Как отметил О.Н. Бетлингк, в своем труде «О языке якутов» ударение в якутском языке всегда падает на конечный слог слова. То же встречал также и Миддендорф [1: 256]. Например, хак. *арғыс 'товарищ, попутчик'* як. *аргыс* (ГС-СГС ~ ГС-СГС).

Длительность произнесенного хак. *арғыс* 57 мс, тональность составляет 202-179-197-185-170-237-208 Гц, движение ч.о.т. – нисходяще-восходяще-нисходяще-нисходяще-восходяще-нисходящее, интервал составляет от –м.3 до-ч.4-б.2. А длительность як. *аргыс* равна 108 мс, тональность 211-224-214-203-249-287 Гц. Итак, по итогам анализа выявлено, что словесное ударение в якутском языке тонально-динамическое и падает на конечном слоге. В як. *аргыс* и в хак. *арғыс* ударение падает на последний слог.

В труде Л.Н. Харитонова «Современный якутский язык» отмечено, что не нужно смешивать ударение с долготой гласного. Ударение основывается на силе и высоте тона, а долгота основывается на длительности произношения гласного. Но долгий гласный может быть в любой части слова, а ударение падает на последний слог: хак. *патыр 'богатырь'* як. *Баатыр* (СГ-СГС ~ СЃ-СГС).

Длительность хак. *патыр* равна 56 мс, при этом долгота*а* – 16 мс, тональность слова составляет 208-234-187-229-212-317-240-233-255-247-225-253-391 Гц, движение ч.о.т. – восходяще-нисходящее. А длительность як. *батыр* 88 мс, при этом долгота *аа* – 29 мс, тональность – 205-235-293 Гц, движение ч.о.т. – восходяще-восходящее, интервал составляет от –б.2 до –б.3.

В данном случае в первом слоге широкий гласный удлиняется долгими гласными *а~аа*. Не смотря на это в як. *баатыр* и хак. *патыр* ударение падает на последний слог.

Также гласный заменяется на дифтонг *ӧ~үө*. Например, хак. *чӧкей 'сметана'* як. *сүөгэй* (СГ-СГС ~ СГ˥ -СГС).

Отсюда мы видим замену узкого краткого гласного на дифтонг. Длительность хак. *чӧкей* составляет 73 мс, при этом долгота *ӧ*– 22 мс, тональность 226-187-208-237-223-243 Гц, движение ч.о.т. – нисходяще-восходяще-восходяще-нисходяще-восходящее, интервал составляет от –м.3 до –б.2.А як. *сүөгэй* имеет длительность 108 мс, при этом долгота *үө* – 37мс, тональность 254-223-266-222-202,

движение ч.о.т. – нисходяще-восходяще-восходяще-нисходящее, интервал составляет от –б.2 до –м.2.

Кроме главного, т.е. основного ударения, падающего на последний слог, появляются еще второстепенные ударения, падающие на первый или серединный слог. Это основывается на силе и высоте тона, а долгота или дифтонг основывается на длительности произношения гласного.

В заключении на основании слуховых наблюдений делается вывод, что в якутском языке основное ударение всегда падает на последний слог и может иметь второстепенное ударение. Также в хакасском языке ударение в слове падает на последний слог. Однако, на основе изложенного экспериментального материала в зависимости от тонического или музыкального характера как и в других тюркских языках ударение не всегда переходит на последний из них в слове.

**ЛИТЕРАТУРА**

1. Бетлингк О.Н. О языке якутов. Новосибирск, 1990. 646 с.
2. Убрятова Е.И. Исследования по синтаксису якутского языка. Новосибирск, 1976. 214 с.
3. Харитонов Л.Н. Современный якутский язык. Часть. Фонетика и морфология. Якутск, 1947. 313 с.

## ҚАЗАҚ ЕРТЕГІЛЕРІНІҢ ТӘРБИЕЛІК МӘНІ МЕН ТАҒЫЛЫМДЫҚ МАҢЫЗЫ

*Птимбаева Асель, Қ.Жұбанов атындағы Ақтөбе өңірлік мемлекеттік университеті, I курс студенты*
*Ғыл. жет. – Г.С. Обаева*

Ұлы Абай бала тәрбиесінде – ауыз әдебиетінің маңызды орын алатынын меңзеп, былай дейді: «Мен егер заң қуаты қолымда бар кісі болсам, адам мінезін түзеп болмайды деген кісінің тілін кесер едім, қандай адам баласы болсын, ол кішкене күнінде ауыз әдебиетімен сусындаса, онда ол адам өз тілін, елін, жерін сүйеді» [1: 13]. Ауыз әдебиетінің ең бір көрнекті саласы – ертегі жанры.

Ертегісі болмайтын ел жоқ әлемде. Бірақ әр елдің, әр халықтың ертегілері – сол халықтың сарқылмас рухани қазынасы. Әр ертегі арқылы өткен ата-бабаларымыздың ой-қиялдарын, тұрмыс-салтын, тіл байлығын білеміз. Әр ертегі тұнып тұрған тәрбие құралы. Ертегі балалардың ой-өрісін, дүниетанымын кеңейтеді. Оларды адамгершілікке, еңбекке, тапқырлыққа, сүйіспеншілікке, сезімге баулу ісінде шешуші орын алады. Ертегіде

қиял мақсатты түрде пайдаланылады, сондықтан ол әсерленіп, ғажайыпқа айналады және біршама өзінше дамып отырады. Ертегіде ғажайып қиял адамның күнделікті көріп жүрген заттары мен құбылыстарын саналы түрде басқаша етіп көрсетеді, жанрды ғажайыптың бейнелеуіш құрал ретінде қолданылады [2: 63].

Ертегі – бұл ой бесігі, біздің, яғни балалардың өмірінде оның орны бөлек. Кішкентайынан ертегі тыңдап өскен балалардың қиялы жүйрік болады. Ертегі – бұл ойлау ләззаты, ал ертегі шығара отырып, баланың ойлауға өз қабілетін орнықтырады, сол арқылы өзінің ар-намыс сезімін орнықтырады. Қазақ ертегілерінің не үшін қажет екенін әдебиет зерттеушісі ғалым А. Байтұрсынов «Ертегінің қадірі қанша деп сұрағанда, керектігіне қарай жауап беріледі. Ертегінің керек орындары: халықтың ұмытылған сөздері ертегіден табылмақ. Олай болса, ертегі тіл жағынан керек нәрсе; 2. Бала әдебиеті жоқ жерде баланың рухын, қиялын тәрбиелеуге зор кедергі бар нәрсе. Баланы қиялдауға, сөйлеуге үйретеді; 3. Бұрынғылардың сана – саңлау, қалып-салты жағынан дерек беруші үшін керегі бар нәрсе» – деп айтқан болатын [3: 73]. Қазақ халық ертегілері мейірімділікке, адалдыққа, әділеттікке, еңбек сүйгіштікке, тазалыққа, достыққа, әдептілікке үйретеді. Жамандықтан, қулықтан, өтіріктен, зұлымдықтан аулақ болуға тәрбиелеу жолын алға қояды. Әрдайым татулық, ынтымақ жеңетінін көрсетеді.

Батырлық ертегілер мен батырлар жыры ел қорғау жолындағы батырлардың ерлік істерін дәріптей отырып, ел бірлігі мен жұрт тыныштығын сақтап қорғау азаматтық парыз екенін нықтап, жас ұрпақты елжандылыққа, Отан сүйгіштікке тәрбиелейді. Адамгершілік жақсы қасиеттерді қалыптастыруға болады. Жақсы істерге ұмтылдыру, жаман қылықтардан аулақ жүру, өнегелі мәдениетті азамат болуға тырысу адамдардың өзіне байланысты. Сондықтан адамгершілікке кір келтіретін мінездер: әдепсіздік, жеңілтектік, екі жүзділік т.б сыналады. Балалардың ой-өрісін кеңейтіп, дүние сырын молырақ танытатын ертегілер бала ұғымын, түсінігін, дүниетанымын кеңейтеді. Тіл ұстартып, ұштай түседі, ойлау мен қиялын дамытады. Мысалы: «Қаңбақ шал» ертегісінде қауқарсыз шалдың ақылмен жеңуі, дәулердің күші көп, ақылы аздығы тыңдаушыны қызықтырып, тіпті ертегіні баяндаушыға қосылып айтып кеткісі келетіндей әсерге бөлейді. Халқымызда қай тақырыпта да табылатын, тілге жеңіл, жүрекке жылы тілек ертегілері қаншама?! Ол ертегілер арқылы бала өз халқының тілін,

мәдениетін дәстүрін біледі және ой-өрісі қиялы дамиды және адамгершілікке тәрбиеленеді. Мысалы, «Жақсымен жолдас болсаң, жетерсің мұратқа, жаманмен жолдас болсаң, қаларсың ұятқа» деген мақалды, «Жаман дос жолдасын жолда қалдырар» деген мақалдарды «Екі дос» желісінен оқуға болады.

Алдаркөсе жайындағы қазақ айтатын аңыз ертегілер де көпке мәлім, алыс заманнан келе жатқан әңгімелер. Асан-қайғы жайындағы аңыздардан бұның тегі, түрі, мазмұн-мағынасы мүлде бөлек, өзінше көп тапқырлық ерекшелігі бар күлдіргі аңыздар. Аңыз ғана емес, Алдаркөсе туралы қызық әңгімелер – тұрмыс-салт ертегілерінің ішіндегі күлдіргі, халықтық сатиралы ертегілер. Алдаркөсе жайындағы аңыздар жалғыз қазақта емес, сыбайлас, туыстас өзбек, қарақалпақ, түрікмен елдерінде бар. Онда да Алдар бір пішінде күлдіргі алдағыш, мазақшы болып көрінеді. Алдаркөсе сараң байды, қу шайтанды алдайды, алтын егіп берем деп, өзі Алдардың қарындасы боп Алаша ханды алдап, масқаралайды. Алдаркөсе әңгімелерінің негізгі тақырып-мазмұнын алсақ, бұл көпшілік бұқара, қалың еңбекші ел санасы тудырған шығармалар. Сол көпшіліктің бір уақыт сараң, жеміт, сасық байға арналған таптық, қоғамдық мысқылын білдіріп, Алдардың Шықбермес Шығайбайды алдап, мазақ еткенін көрсетеді. Алдар жайындағы өте өткір күлдіргі, шебер әңгіменің бірі осы. Бұнда көпшілік бұқара дүниеқоңыз, шірік, арам байдың сұм құлқынын өлтіре мазақ етеді. Алдаркөсе арқылы діннің қараңғы нанымдарына шабуыл жасайды.

Алдаркөсе әңгімелеріне ұқсайтын шығарманың бірі – Жиренше әңгімелері. Бұның да дәлді қай заманда туғаны мәлім емес. Бұнда да Алдар әңгімесе сияқты, алғашқы шыққан түрінен кейіннен қосылған қоспа, жамау көп. «Бай баласы мен жарлы баласы» атты қызықты ертегі арқылы еңбек адамның кез келген қиыншылықты жеңуге үйрететіні және өмірлік тәжірибесі арқылы жеңіске жететінін көреміз және «Еңбек етсең ерінбей, тояды қарның тіленбей» деген мақалды дәлелдей түседі. «Мақта қыз бен мысық» ертегісі өте тартымды, қызықты. Бұл ертегіде мақта қыздың досы мысыөқ мақта қыздың тілін алмай қатығын төгеді де, оны қайтарып беру үшін көптеген адамдарға жолығып, көп қиыншылық көріп барып, қатықты төлей алады. Бұл жерде адамды әрбір іс-қимылына жауап беруге, үйренуге тәрбиелейді.

Жалпы, адамгершілік тәрбиенің нәтижесі адамдық тәрбие болып табылады. Адамгершілік тақырыбы мәңгілік. Ол ешқашан

ескірмек емес. Жас ұрпақтың бойына адамгершілікті сіңіру ертегі арқылы беріледі. Сан ғасырлар бойы ауыз әдебиетіндегі ұрпақтан-ұрпаққа мұра болып келген халықтық тәрбиенің өнеге-үлгілері осы уақытқа дейін өзінің педагогикалық мүмкіндіктерінің мәні зор екендігін дәлелдеп келеді. Халық ауыз әдебиетінің ішіндегі балаларға ең жақыны ол ертегі болмақ.

**ӘДЕБИЕТ**


1. Әуезов М. Ертегілер. I том. Алматы: Жазушы, 1988. Б. 13.
2. Сауытбеков С. Тағылым тегі. Көкшетау, 2003. Б. 63.
3. Байтұрсынов А. Ақ жол. Алматы: «Жалын», 1991. Б. 73.


## ЛЕКСИКАЛЫҚ СИНТАГМАТИКА МЕН НОРМА МӘСЕЛЕСІ


*Рақымғалиева А., М. Акмулла атындағы Башқұрт мемлекеттік педагогикалық университеті, II курс магистранты*

*Ғыл. жет. –пед. ғыл. док., проф. Р.Г. Давлетбаева*


Лексикалық норма мен лексикалық синтагматика тілдік жүйеде бір-бірімен тығыз байланыста болады. Бұл туралы Б. Сағындықұлы: "Сөздің бір-бірімен тіркесе алу қабілетін анықтауда лексикалық мағына мен грамматикалық форма ғана қатынасып қоймайды, баршаға ортақ тілдік норма да өз үлесін қосады", – деп жазады [1: 101]. Тілдің дамуына байланысты тілдік нормаларда дамып, өзгеріп отырады. "Жалпы тілдік норма мүлде өзгермейтін құбылыс емес, қоғамдағы түрлі қарым-қатынастың өзгеруіне байланысты тілдік норманың өзгеретін тұстары болады" [2: 133]. Лексиканың нормалануы үнемі тілдің лексикалық жүйесінде жүріп жатады, Р. Сыздықтың жазуынша, "лексиканың нормалануы дегеніміз белгілі бір ұғымда бір сөздің қалыптасуы; синонимдер қатарын түзейтін единицлардың әрқайсысының семантикалық реңктері мен стильдік аясының айқындалуы; сөздердің тіркесу типтерінің тұрақталуы, қоғам, заман өзгерістеріне байланысты "басы артық" болып қалған сөздердің әдебиеттен ығысуы немесе пассивтенуі; жаңа сөздер мен кірме сөздердің реттелуі, бір жағынан орнығуы т.б. жататыны белгілі" [3: 155].

Лингвоэкология аясында нормаларды қарастырған Н. Уәли: "сөз мәдениеті" ұғымы тілдік норма, этикалық норма, коммуникативті норма деп аталатын норманың үш типін қамтиды. Тілдік нормалар: орфоэпикалық норма, орфографиялық норма, лексика-фразеологиялық норма, грамматикалық нормалар", – деп жіктейді [4: 22]. Стилистикалық норма мен лексикалық норма тығыз байланыста болады, яғни стилистикалық норма стильдік

қолданысты реттеуші өлшем болады. Лексикалық норма жеке сөздің мағынасы мен формасының өзгеруіне қатысты болады, яғни жеке сөздің өзі тұлғалық өзгеріске түсіп, соның ықпалынан басқа сөздермен лексикалық синтагматика құралғанда норма реттейді не өзі де өзгеріп дамиды. С.Г. Тер-Минасова лексикалық синтагматиканың бұзылуының мынадай жағдайларын келтіреді:

а) лексикалық сәйкессіздік: нервті психология, принципиалды туыстық құбылыстар т.т.; б) стилистикалық сәйкессіздік: ұзын тұра жауынгерлер, 2-ші "а" жаушылары т.т.; в) коллокациялы сәйкессіздік: өлімді жаза, уақытша көктем, бидайдай бидайлар т.тт; г) плеонастикалық сәйкессіздік: біріккен ынтымақтасу, бастамалы бастама т.т; д) тіркесетін мүшелердің әртектестігі: ол менің қалыңдығыма үйленді, бұл авторларды зерттеу және еліктеу дұрыс болар т.т.

Лексикалық синтагматика табу, эвфемизм сөздердің лексикалық нормаға сай үйлесуінен көрінеді. Ә. Ахметов былай дейді: "Әйел адамдарға тән табиғи физиологиялық процестердің бірі – бала көтеру. Солай бола тұра, о баста құрсақ көтерген әйел адам болсын, ішінде төлі бар ұрғашы мал болсын, екеуіне де тең қолданыла беретін әрі түркі тілдерінің көбіне ортақ *"буаз"* деген сөз қазіргі кезде жартылай табуға айналып тек малға байланысты ғана қолданылады. Ал әйел адамдардың ондай жағдайларын қазақтар *екіқабат, аяғы ауыр* немесе *жүкті* дейді", – деп нақтылайды [5: 119]. Ұлттық мәдениетке қатысты сөздердің байланысуына құралған лексикалық синтагматиканы лингвомәдени синтагматика деп атауға болады. Лексикалық синтагматика әртүрлі ракустарда, өзгерістерде келіп, қолданысқа түскенде, бірқатар факторлардың әсерінен туындайды, сондықтан нормаға сай құралмауы мүмкін. Лексикалық синтагматика бұзылса, лексикалық норма реттеп, жалпы қолданысқа түсірмей, тежеп отырады, яғни Р. Сыздық жазғандай *"қыпша жіп, қыпша саусақ* деп айтпаймыз... саңлақ самолет, саңлақ машина дегенге ауыз бармайды" [6: 231]. Қазақ грамматикасы авторлары лексикалық тіркесімділікте екі түрлі шектеу – лексикалық және семантикалық шектеулер болады дей келе, былай дейді: "Лексикалық тұрғыдан келгенде, мағыналас сөздердің нәзік реңктерінің айырмашылығына байланысты бірінің орнына екіншісін қолдану жаңсақ көрінеді. Мәселен, *жабу – бекіту – құлыптау* сөздерін ауыстырып жұмсау мағыналық қателікке ұрындырады. Оның себебі мынада: жабу кезінде есікті тақап итеруді ұғамыз; бекіту болса, оны темірмен не ағашпен итеріп қою жеткілікті; ал құлыптауда құралдың

аты аталып тұрғанындай, кілт салынуы ұғынылады: *Тарс жауып есігін, Бекең қайтып келеді (Мұқышев); Ысқақ есікті сыртынан бекітті де, әлдеқайда кетіп қалды (Баязитов); Ұрыдай аңдап басқан вагондарға Құлыптап лық толтырып қойды екен не? (Тұрсын-Заде)*" [7: 585].

Қорыта келгенде лексикалық синтагматика мен лексикалық норма тілдің лексикалық жүйесінің дамуына байланысты өзгеріп, түрленіп, дамып отыратын құбылыстар. Лексикалық мағынаның синтагмалық қасиеті концептіде бейне құрайды, сондықтан сөз-синтагмалар концептінің құрылымдылық үлгілері болып, концептіде көрініс табады. Теңеулерде немесе басқа лексикалық бірліктерде өзара байланыс денотаттық және сигнифаттық жағдайлардан туындайтын денотаттық, сигнифаттық, коннотаттық бөліктердің қатынасуына байланысты орын алады.

**ӘДЕБИЕТ**

1. Сағындықұлы Б. Қазіргі қазақ тілі. Лексикология. І-б. Алматы: Қазақ университеті, 2003. 101 б.

2. Дүйсембекова Л.С. Қазақ ресми-қағаздар тілі: Филол. ғыл. докт.ы. дис. қолж. Алматы , 2006 133 б.

3. Сыздықова Р. Қазақ әдеби тілінің тарихы. Алматы: Ана тілі, 1993. 155 б.

4. Уәли Н. Қазақ сөз мәдениетінің теориялық негіздері: Филол. ғыл. докт.ы. дис. Автореф. Алматы, 2007. 22 б.

5. Ахметов Ә. Түркі тілдеріндегі табу мен эвфемизмдер. Алматы, 1995.

6. Нұрмұқанов Х. Сөз және шеберлік. Алматы: Ғылым, 1997. 231 б.

7. Оразов М. Қазақ тілінің семантикасы. Алматы: Рауан, 1991 б. 585 б.

## ТАТАР ТЕЛЕНДӘ СӨЙЛӘМ ЭШЧӘНЛЕГЕН БЕЛДЕРГӘН ФИГЫЛЬЛӘРНЕҢ ХАЛЫК АВЫЗ ИҖАТЫНДА КУЛЛАНЫЛЫШ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ

*Ризванова Э., КФУ, III курс студенты*

*Фән. җит. – филол.фән.канд, доц. Р.Р. Сәлахова*

Фигыль лексикасын мәгънәсе буенча төркемләү – шактый катлаулы эш, чөнки фигыльнең мәгънәсе үтә гомуми, үтә киң, һәм аның нигезендә объектлар арасындагы мөнәсәбәт ята. Шулай булуга карамастан, фигыльләр сүз буларак өйрәнелергә тиеш, чөнки шунсыз фигыльдәге категорияләрнең мәгънәсен һәм функциясен бөтен тулылыгы һәм тирәнлеге белән аңлап булмый. Фигыль лексикасы фәндә лексик-семантик төркемчәләргә бүлеп өйрәнелә: хәрәкәт фигыльләре, эшне, эмоциональ халәтне белдергән фигыльләр һ.б.

Төрки телләрдә фигыльләрнең мәгънә төркемчәләрен Н.К. Дмитриев башлап өйрәнгән. Ул татар телендәге сөйләү,

фикерләү, эш һәм хәрәкәт фигыльләренең төп лексик берәмлекләрен тикшергән. Шулай ук Ф.А. Ганиев, Л.М. Васильев, Г.К. Кулиев, Э.В. Кузнецова кебек тел белгечләре төрле классификацияләр тәкъдим иткәннәр. Э.В. Кузнецованың “баскычлап тиңләштерү алымы” (“метод ступенчатой идентификации”) иң уңышлы классификацияләрдән санала. Әлеге классификация фигыльләрне, төп мәгънәләреннән чыгып, ике зур төркемгә – эш-гамәл һәм хәл-торыш фигыльләренә аеру һәм алар эчендәге төркемчәләрне билгеләү, өченче төркем итеп кешенең тормышында бөтен эшчәнлегендә зур урын тоткан мөнәсәбәтләрне белдерә торган фигыльләр төркеменә аерып чыгаруга нигезләнгән. Әлеге классификация нигезендә эш-гамәл фигыльләре төркеменә акыл, иҗтимагый һәм сөйләм эшчәнлеген белдергән фигыльләр, хәрәкәт фигыльләре һәм яңгыраш фигыльләре керә. Без исә соңгы төр фигыльләргә тукталып, аларның татар фразеологизмнарында кулланылышын тикшереп үттек.

Сөйләм эшчәнлеген белдергән фигыльләр үз эчендә түбәндәгеләрне ала: төп, сөйләмнең характеры һәм эчтәлегенә бәйле, хәбәр итү, сөйләшүне, ягъни сөйләм вакытында контактка керүне белдерүче, сөйләү эчтәлегендә боеру (каузация) мәгънәсе булган, бәяләү, эмоциональ мөнәсәбәт белдерүчеләр, сөйләмнең төрлечә яңгыравына ишарә итүче; Дип фигыле белән килүче, дәшмәүне белдерүче фигыльләр. Мисалларга тукталыйк:

– төп фигыльләр: әйтү, сөйләү. Мәсәлән: *1. Аның булдыклылыгын, уңганлыгын, һәр эшне белүен, кешеләргә карата игелекле булуын бөтен тирә-як исләре китеп сөйли икән (“Зөһрә йолдыз”); 2. Мин аз әйтсәм, син күбен аңла (әйтем жанры);*

– сөйләмнең характеры һәм эчтәлегенә бәйле ф.: алдау, карышу. Мәсәлән: *Шүрәле кешене адаштырырга, кара урман эченә алдап кертергә бик ярата (“Шүрәле”);*

– хәбәр итү ф.: ант итү, йөрәкне ачу, Мәсәлән: *1. Коръән белән ант итәм (антлар жанры); 2. “Үзеннән-үзе үләр, без әти каршында да, Тәңре каршында да гөнаһлы булмабыз, – дип сүз куешканнар (“Йосыф китабы”);*

– сөйләшүне, ягъни сөйләм вакытында контактка керүне белдергән ф.: сөйләшү, гайбәт сату, каршы төшү, исәп итү. Мәсәлән: *Идел буйлап бик югары меңәләр дә сөйләшәләр: “Әйдә, суга йомычка салабыз. Йомычка кайда әйләнә, бөтерелә, – шунда утырабыз”, – диләр;*

– бәяләү ф.: каһәр салу, ачу тоту, ачулану, гаеп итеп калмагыз (гаепләмәгез). Мәсәлән: *– Алар мине каргарлар бит, җизнәкәй? – Каргышы карга башына, балдызым-ялгызым (“Җизнәкәй” шаян җыры);*

– эмоциональ мөнәсәбәт белдергән ф.: гафу үтенү, битенә бәреп әйтү. Мәсәлән: *1. Гафу ит. Гафуың белән сату ит (әзер җаваплар жанры); 2. Ходаем, гафу әйләсәң, рәхмәт дәрьясында йөзәм (“Гафурым сән” мөнәҗәте);*

– сөйләмнең төрлечә яңгыравына ишарә иткән ф.: кычкырып салу. Дип фигыле белән килүче ф.: ... дип әйтеп әйтү, дип сөйләү. Мәсәлән: *1. Юри, кешеләр җылан, ерткыч күп дип сөйли торган куркыныч урманнарга Зөһрәне коры утыннар җыярга җибәрә икән үги анасы (“Зөһрә йолдыз”); 2. “Аллаһы әкбәр! Аллаһы әкбәр! Аллаһы әкбәр!” – дип кычкырып, хәзәр патшасы белән сугышканнар;*

– дәшмәүне белдергән ф.: дәшмәү, авызга су кабу, әйтмәү, сөйләмәү. Мәсәлән: *Ташка язмаганны сөйләмә.*

Нәтиҗә ясап әйткәндә, сөйләм эшчәнлеген белдерә торган фигыльләр мәгънә белдерү ягыннан татар телендә, шул исәптән, халык авыз иҗатында зур урын алып торалар. Алар тормыш-көнкүрештә иң еш кулланыла торган сөйләм эшчәнлеге процессын атыйлар. Сөйләм эшчәнлеген белдергән фигыльләр аналитик формада, ягъни янәшә ике яки икедән артык сүздән торган формаларда кулланыла. Тагын бер мөһим үзенчәлек: күп кенә фигыльләр үзләре аңлаткан мәгънәләре белән туры килмиләр. Шулай итеп, мәгънә ягыннан әлеге фигыльләр телдә мөһим урын тота һәм тормыш-көнкүрештәге сөйләм эшчәнлеге процессының төрле төрләрен билгелиләр.

**ӘДӘБИЯТ**

1. Хисамова Ф.М. Татар теле морфологиясе. Казан: Мәгариф, 2006. 335 б.
2. Татар грамматикасы. Т. II. М.: ИНСАН, Казан: ФИКЕР, 2002. 448 б.
3. Татар халык иҗаты: Хрестоматия. Казан: Мәгариф, 2004. 479 б.

## ТАТАР ТЕЛЕНДӘГЕ ПРАГМАТОНИМНАРНЫҢ ЭТНОМӘДӘНИ ПОТЕНЦИАЛЫ

*Сабирова Э., КФУ, I курс магистранты*

*Фән. җит. – филол. фән. докт., проф. Г.Р. Галиуллина*

Номинатив берәмлекләр төркеме буларак, прагматонимнар рус, инглиз, алман, шул исәптән татар теле материалының төрле аспектларында өйрәнелә. Ләкин рус телендә дә, татар телендә дә прагматонимнарың «ризык атамалары» төркеме кысаларында милли үзенчәлекләрен ачыклау буенча эшләнгән махсус хезмәтләр

юк. Моннан тыш татар прагматонимнарының мәгәриф өлкәсендә этномәдәни потенциалын билгеләү бөтенләй өйрәнелмәгән булып санала. Фәнни мәкаләбезнең актуальлеген беренчедән, этномәдәни карашларның лингвокультурологик моделен төзү, хәзерге филологиянең төп юнәлешләренең берсе булуы; икенчедән, тел семантикасында миллилекнең доминант үзенчәлекләре чагылуы аз өйрәнелгән булуы; өченчедән бүгенге көндә эшләнгән татар телен укыту методикаларында татар теленең этномәдәни потенциалын прагматонимнар аша ачу бөтенләй каралмаган булуы билгели.

Эшебезнең өйрәнү объекты – хәзерге татар телендәге прагматонимнарның «ризык атамалары» төркеменең этномәдәни потенциалы. Өйрәнү предметы – татар прагматонимнарының этномәдәни потенциалын гомуми белем бирү оешмаларында татар теле дәресләрендә ачу.

Фәнни мәкаләбезнең максаты булып татар телендәге прагматонимнарның этномәдәни потенциалын ачу тора.

Әлеге максатыбызны тормышка ашыру өчен без түбәндәге бурычларны куйдык:

- Прагматонимнарның типологик характеристикасын һәм милли-мәдәни үзенчәлекләрен тасвирларга;
- Прагматонимнарны татар теле дәресләрендә этномәдәни компетенцияне тормышка ашыру юнәлеше буларак анализларга.

Укучыларга татар теленнән сыйфатлы белем бирү өчен коммуникатив, лингвистик, этномәдәни компетенцияләргә таянырга, телгә өйрәтүне мәдәният, заманча технологияләр, бүгенге көндә актуаль булган үзгәрешләр белән тыгыз бәйләнештә алып барырга кирәк. Әлеге мәкаләбездә без этномәдәни компетенцияне күз уңында тотабыз.

Этномәдәни компетенция – укучыларга телнең милли мәдәниятне чагылдыру формасы булуын аңлату. Тел чаралары ярдәмендә халыкның милли үзенчәлекләрен сурәтләү мөмкинлегенә басым ясала. Төрле текстлардан халык авыз иҗаты үрнәкләрен, тарихи лексиканы аерырга, аларның төрләрен һәм мәгънәләрен ачыкларга өйрәтү максат итеп куела. Татар милләтенең дөньяны танып белүен чагылдырган төп төшенчәләр, аларның сүздә, сүз мәгънәсендә чагылыш үзенчәлекләре өйрәтелә, татар халык иҗаты үрнәкләрендә сүзнең кулланылыш, төшенчәләрне бирү мөмкинлекләре анализлана [1:7].

Татар мәдәниятенең үзенчәлекләргә тулырак күзәтү ясау өчен без прагматонимнарны түбәндәге төркемчәләрне аерып чыгардык: 1) Милли мәдәниятне, тарихны чагылдыра торган атамалар*: «Сөембикә» торты, «Болгар» чәк-чәге, «Тулпар» туңдырмасы, «Ак Барс» колбасасы* һ.б. 2) Мөселманнарның дини карашларын чагылдыручы прагматонимнар: *«Рамазан» колбасасы, «Җомга» колбасасы, «Сәдәка» чәе, «Хәергә» чәе, «Мәрьям» чәе* һ.б.

Чын татарча милли атамалардан тагын *«Болгар» чәк-чәге, «Болгар» минераль суы* прагматонимнарын китерергә мөмкин. Татарлар тарихында зур урын алып торган Болгар шәһәренең атамасын прагматонимнар ролендә куллану да халкыбызның милли күзаллаулары, үткән тарихы хакында сөйли. *«Сандугач» торты, «Карлыгач» конфеты* прагматонимнарында татар халкы фольклорында традицион булган мифологик кош образлары кулланылган. Шулай ук әлеге кош образлары татар халкының бик күп җырларында кулланыла. Татар халкы кызларның матурлыгын тасвирлаганда түбәндәге чагыштырулардан файдалана: кыз – күбәләк, күгәрчен, сандугач, кызлар күзе – кара карлыган, кара карлыгач, таң йолдызы, чәч – кара ефәк, теш – ак кар, йөз – бөрлегән, тулган ай, буй – тал, һ.б. Тулпар мифологик персонаж исеме *«Тулпар» туңдырмасы* атамасында очрый. Тулпар образы татар, башкорт, кыргыз һәм казах мифологиясендә канатлы ат буларак мәгълүм. Борынгы грек мифологиясендәге Пегас белән тәңгәлләшә. Тулпар әкиятләрдә киңәшче һәм батырның ярдәмчесе буларак сурәтләнә [2: 111].

Югарыда саналган атамаларда, бер яктан, халкыбызның милли үзаңы, дини ышанулары, икенчедән, ислам дине кануннары нигезендә яшәү рәвеше, шуңа омтылышы чагылыш таба. Шунысын да искәртергә кирәк: әлеге товар атамаларының милли колоритны яктыртуы татар теленнән белем бирүнең этномәдәни потенциалын арттыруда мөһим роль уйный.

Күренгәнчә, татар прагматопонимикасы илдәге сәяси-иҗтимагый вакыйганы, күпмилләтле республикабызның мәдәни-рухи тормышын, дини гореф-гадәтләрне, милли йолаларны чагылдыра алуы ягыннан да әһәмияткә ия һәм игътибарга лаек ономастик тармак булып тора. Беренче чиратта, тел системасы милли үзаңга ия һәм психологияне аңлаган, заман таләпләренә җавап бирерлек күпкырлы шәхесләр тәрбияләүгә юнәлгән булырга тиеш. Икетеллелек, глобальләштерү шартларында татар теленә

башка теллəрдəн кергəн сүз һəм аерым конструкциялəр еш кулланыла. Аларның сөйлəм телендə һəм матур əдəбият телендə урынсыз кулланылуын искəртеп, халыкта туган теленə ихтирам тəрбиялəү – этномəдəни лексиканың мөһим бурычы. Тулаем алганда, прагматопонимика ландшафтында чын милли атамалар чагыштырмача күп түгел. Шуңа карамастан, прагматонимнарны татар теле дəреслəрендə куллану укучыларга милли тəрбия бирүдə, татар хылкының мəдəни-рухи тормышы, йолалары, ышанулары белəн таныштыруда мөһим урын алып тора.

**ƏДƏБИЯТ**


1. Галиуллина Г.Р., Шəкүрова М.М. Татар телендə гомуми төп һəм урта белем бирү мəктəплəре өчен ана теленнəн программа (10-11 нче сыйныфлар). Казан, 2013 36 б.

2. Галиуллина Г.Р. Татарские личные имена в контексте лингвокультурных традиций. Казань: Изд-во Казан.гос. ун-та, 2008. 352 с.


## БАЛАЛАРДА ТƏНКЫЙДИ ФИКЕРЛƏҮНЕ ҮСТЕРҮЧЕ ТЕХНОЛОГИЯ БУЛАРАК ƏДƏБИ ТƏНКЫЙТЬ


*Сабирҗанова Д., КФУ, I курс магистранты*

*Фəн. җит. – филол. фəн.канд., доц. Т.Ш. Гыйлəҗев*


Бүгенге көндə иҗтимагый, сəяси, мəдəни вəзгыятьтə белем бирү оешмалары, шул исəптəн гомуми урта белем бирү мəктəплəре яңарыш чорын кичерə: программалар үзгəрə, танып-белүнең яңа технологиялəре кулланыла, дəрес эчтəлеге, формасы үзгəрə. Əлбəттə, укытучыларга, балаларга да башка талəплəр куела. Балаларда тəнкыйди фикерлəү формалаштыру – бүгенге көннең төп мəсьəлəлəреннəн берсе. Димəк, бүгенге көндə мəктəп балаларыннан тəнкыйди фикерлəү, мəстəкыйльлек сорала. Нəрсə ул тəнкыйди фикерлəү? “Тəнкыйди” фикерлəү, беренче карашка, “тəнкыйди фикер йөртү, тəнкыйть күзлегеннəн карау” дип кабул ителə. Лəкин белем бирү системасында бу төшенчə, үз мəгънəсен киңəйтеп, стандарт булмаган фикерлəүне, укытуның иң югары дəрəҗəдə камиллəшүен ассызыклый. Г. Селевко фикеренчə, тəнкыйди фикерлəү – интеллектуаль (гамəли) эшчəнлек төре: мəгълүматны кабул итү, төшенү, хəтердə калдыру, иҗади, интуитив фикерлəү кебек психологик төшенчəлəрне ала. Тəнкыйди фикерлəүнең концептуаль үзенчəлек төрлəре: белем бирүнең эчтəлеге аның күлəмен яки мəгълүматның санын түгел, бəлки укучының бу мəгълүмат белəн тулысынча идарə итə алуын хуплый: танып белү, үзлəштерү, аңлау, гамəлдə куллану; белем алуда мөстəкыйль

рәвештә күнекмәләр булдыру; коммуникатив эшчәнлеккә нигезләнгән икеяклы процесс; танып-белүдә үтеләсе материалның уңай һәм тискәре якларын ачу; төгәл билге.

Тәнкыйди фикерләү технологиясенең төп критерийлары: укучы белән укытучы арасында киртә, “барьер” юк. Алар әңгәмәдә, укыту эшчәнлегендә икесе дә тигез хокуклы; укытучы мәгълүмат чыганагы түгел, ә юнәлеш, юл күрсәтүче буларак карала. Аның укыту эшчәнлеген мавыктыргыч итеп оештыруы зарури.

“Тәнкыйди” фикерләүне формалаштыруда галимнәр тарафыннан төрле технологияләр тәкъдим ителә, ләкин аларны сайлаганда, мәктәп программасы, эчтәлеге белән бәйләү проблемасы алга килеп баса. Менә бу шартларга тулаем җавап биргән технология – ул татар әдәбият фәненең бер тармагы булган әдәби тәнкыйтьне, аның мөмкинлекләрен куллану. Мәгълүм булганча, “тәнкыйди фикер, карашлар тарихы урта гасырларны иңләп, борынгы чорга, халык авыз иҗатына барып тоташса да, әдәбият белеменең бу тармагы, фән буларак, XX гасыр башында калыплаша һәм әдәби хәрәкәттә күп мәсьәләләргә бәя биреп, мөнәсәбәт белдереп, татар сүз сәнгатенең сыйфат яңарышында, күтәрелешендә зур роль уйный башлый” [1: 3]. Ул милли сүз сәнгате, татар иҗтимагый фикер үсешенә нисбәтле барлыкка килә. Әдәби тәнкыйтьнең фәнни нигезләрен формалаштыруда XX йөз башының барлык каләм ияләре көч сала.

“Укый белүче, тормышта һәм эшчәнлектә белемнең һәм үзбелем үзләштерүнең әһәмиятен аңлаучы, алган белемнәрне гамәлдә кулланучы” шәхес тәрбияләүгә юнәлдерелгән бу технология бары тик, әдәбият дәресләре кысаларында гына тәкъдим ителә [4: 11]. Шулай ук аны, укучының үз үсешен тәэмин итү нияте белән, сыйныфтан тыш эшләрдә, электив курсларда куллану максатка ярашлы. Туган (татар) әдәбияты дәресләрендә тәнкыйди язмаларга мөрәҗәгать итү нәтиҗәсен Т. Гыйләҗев болай билгели: “Укучыларны өстәмә гыйльми-тәнкыйди материалдан, төрле белешмәлекләрдән файдаланырга өйрәтү фәнни фикерләү сәләте, иҗадилык, һәм эзләнү кебек сыйфатлар һәм күнекмәләр формалаштыруга китерә” [2: 94].

Бер төркем рус галимнәре тарафыннан әлеге технологияләрне куллана тәҗрибә тупланган [3]. Нәрсәдән гыйбәрәт соң ул технология? Ул әдәби әсәрләрне укыр алдыннан сорау төзү һәм шушы сораулык буенча балаларны әдәби әсәрне

кабул итүгә әзерләү. Мораль, эстетик, әхлакый нормалар буенча һәрбер укучының үзенең фикере бар: балада шушы фикер (сораулыктан соң) туарга тиеш. Аннан әсәр укыла башлап, һәр яңа бүлек (фикер, абзацтан) соң фикер алышу, сораулар бирү, әдәбиятта башка аналогик мисаллар эзләү, уртак һәм аермалы якларын күрсәтү таләп ителә. Соңгы, өченче этапта, әсәр буенча фикер алышканнан соң, балага чагыштырып, үз фикеренә якынын табуга, аны дәлилләүгә мөмкинлек бирү өчен, төрле авторларның тәнкыйди мәкаләләре укыла. Бу технологияне практикада еш кулланып, укучыларны әдәби тәнкыйть жанрлары белән таныштыргач, өлкәнрәк сыйныфларда бер әсәрне укыганнан соң, тәнкыйди мәкалә яздыртыла. Кечкенә сыйныфларда белемнәрне, фикернең үсешен тикшерү максаты белән бу эш иң гади – ирекле иншадан яисә эсседән башлана. “Тәнкыйди фикерләү” технологисе “сингапур методикасы” кулланылган дәресләрдә дә бик уңышларга китерә. Ул федераль дәүләт белем бирү стандартлары таләпләренең структурасына, эчтәлегенә туры килә. Дәрес эчтәлеге шушы этаплардан гыйбарәт: оештыру, кызыксындыру, акыл штурмы, кластер төзү, төшенү, рефлексия, кластерга кайту, практик эшне башкару, йомгаклау. Укытучы балага шушы информацияне җиткерүдә төрле алымнарга, дәрес типларына мөрәҗәгать итә ала. Эссе, ромашка блум, акыл штурмы алымнары – барысы да әдәби әсәр укуга кызыксыну уята һәм укучыларның иҗади сәләтен, үзкамилләшүен үстерүгә ярдәм итә.

Димәк, тәнкыйди фикерләү формалаштыруда әдәби тәнкыйтьнең роле бик зур. Шуның белән татар әдәбиятын укытуның югары баскычына күчемлелек тә тәэмин ителә.

**ӘДӘБИЯТ**


1. Гыйләҗев Т.Ш. Рецензияләрдән тәгъзияләргә: XX йөз башы татар әдәби тәнкыйте. Казан: Татар. кит. нәшр., 2008. 254 б.
2. Гыйләҗев Т.Ш Г. Ибраһимовның “Яшь йөрәкләр” романын өйрәнүдә әдәби-тәнкыйди материал // Материалы республиканской научно-методической конференции “Взаимодействие школы и вуза в реализации приоритетных направлений развития школьного образования: опыт, проблемы и перспективы” (16-17 пареля 2015 года). Казань: Ихлас, 2015. С. 92-95.
3. Ельцова В.С. Изучение литературно-критических статей в средней школе как методическая проблема. М.: Просвещение, 2014. 186 б.
4. Мөхәммәтҗанова А.Х., Камаева Р.Б. Татар теле һәм әдәбият укытучысына ярдәмгә: ФДББС турында белешмәлек һәм терәк схемалар: методик ярдәмлек. Казан: ТРМҮИ, 2015. 68 б.
5. https://yandex.ru/clck/jsredir?bu=uniq1516879883232175941&from=yandex (мөрәҗәгать итү вакыты: 25.01.18.)

# Г. ТУКАЙ ӘСӘРЛӘРЕНЕҢ ТӘРБИЯВИ ӘҺӘМИЯТЕ

*Сагирова А.,Спас р-ны, Болгар урта мәктәбе, X сыйныф*
*Җит. – Р.Г. Хәбибуллина*

Милли горурлыгыбыз булган бөек шагыйребез Г.Тукай сабыйның күңеле язылмаган ак дәфтәр белән тиңләгән һәм шундый юллар язып калдырган:

Пакь җаның, һәм пакь тәнең – барлык вөҗүдең пакь синең;
Саф фәрештә валчыгысың, йөзләрең ап-ак синең! [2: 185].

Сөекле шагыйребез иҗат иткән әсәрләрнең яшь буынны тәрбияләүдә тоткан урынын бәяләп түгел. Г. Тукайның әсәрләре укучыларда кешелеклелелек, хезмәт сөючәнлек, туган җиргә, туган телгә, халкыбызга һәм аның тарихына хөрмәт тәрбияли.

Халкыбызның олуг шагыйре Г. Тукайның бай иҗат мирасы шактый үзенчәлекле. Ул кешеләргә, халкыбызга әдәп, әхлак кебек изге сыйфатларны өйрәтү максатыннан мәсәлләр, балаларга хезмәт, эстетик, экологик тәрбия бирүче тирән эчтәлекле шигырьләр, поэмалар иҗат иткән. Мәсәлән, “Кызыклы шәкерт” шигырендә балаларны кечкенәдән эшкә өйрәнеп үсәргә,тырыш булырга ялкауланмаска өйрәтә: “Ах, җүләр маэмай! тырыш яшьләй, зурайгач җайсыз ул: Картаеп каткач буыннар эш белү уңайсыз ул” [2: 49]. “Эшкә өндәү” шигырендә киләчәк картлык көнен каршылау өчен дә сабыйларга кечкенәдән тырышырга, хәстәрләнергә киңәш бирә: “Яшьлегеңдә күп тырышсаң, эшкә бирсәң чын күңел, каршыларсың картлыгыңны бик тыныч һәм бик җиңел” [2: 69]. Мәктәп укучысының төп хезмәте – ул белем алу. “Син әле үс һәм укы күп, шунда аңларсың барын; мәгърифәт нуры ачар күп нәрсәләрнең ялганын”, – дип мөрәҗәгать итә ул балаларга ”Сабыйга” шигырендә [2: 64]. Тукай баланың ихтыяр көчен “Эш беткәч уйнарга ярый” шигырендә бик яхшы сурәтли. Кояшның, сандугачның, алмагачның чакыруына “Юк”, – дип җавап бирә малай. Дәресләрен әзерләп бетергәч, бала уйнарга чыга. “Йә, кем чакырды, дип мине? Әйдә, кем уйный? Тәмам иттем хәзер әзер мин дәресеми?” [2: 46]. Бу шигырь балаларда хезмәткә хөрмәт, аның өчен җаваплылык хисләре тәрбияләүгә, шулай ук ваемсызлык сыйфатын искәртүгә булыша. Г. Тукай нәниләрне бик яраткан, бик матур, мавыктыргыч, аңлаешлы әкиятләр язып калдырган. Шуларның берсе – “Су анасы” әкияте. Бу әкиятендә шагыйрь алдашмаска, ялганламаска, гел дөрес сөйләргә киңәш биргән.

Кеше – табигатьнең аерылгысыз бер өлеше. Ул табигатьтән башка бер генә минут та яши алмый; аңа су, һава, азык-төлек, торак, җылылык һәм яктылык кирәк. Шуңа күрә дә табигатькә мөнәсәбәт, кешеләргә мөнәсәбәт кебек үк, гуманлы, шәфкатьле булырга тиеш. Балаларда табигатькә мәрхәмәтле караш кечкенәдән үк тәрбияләүдә “Шүрәле” поэмасының әһәмияте бик зур. Әсәрне укыганда, үзеңне шул табигать кочагын да дип күз алдына китерәсең, үз туган ягыңа икенче күз белән карый башлыйсың. “Кара нинди гүзәл икән минем торган җирем”, – дип сокланасың.

Туган ил бала өчен бишектән, әти-әни йорты бусагасыннан, авыл янындагы тугайлардан, урамда үсеп утыручы каеннан, язын ак чәчәккә төренә торган шомырттан, басуларда җыр сузучы тургайлардан башлана. Шагыйрьне илһамландыручы – табигать. Туган ягына мәхәббәтне дә Тукай табигатьне сурәтләүдән башлый. Ул эчкән суга зур әһәмият бирә. Кешенең бөтен гомере су белән бәйле. Бер “кечкенә генә инеш” саф су белән тәэмин итеп тора.

Г. Тукай үз ягының урманнарына чын күңелдән гашыйк. Ул яхшы белә: урман саф һава чыганагы да, бетмәс – төкәнмәс байлык та. Кырлай урманнарының матурлыгы, сихри тылсымы аның күңелендә мәңгелеккә уелып калган.

Шагыйрь үзенең “Исемдә калганнар” әсәрендә “Бу Кырлай авылы минем дөньяга иң элек күзем ачылган урыным...” дип юкка гына язмагандыр [2: 303]. Чынлап та, табигатьнең бөтен гүзәллеген ул шушында тойган: урманында җиләк җыйган, болынында аунаган, суында коенган, печән җыешкан, туйганчы уйнаган – чапкан. Шагыйрь фикеренчә, урман – саулык, байлык сандыгы. Г. Тукай үз иҗатында табигатькә ямь өстәүче, аны җанландыручы кошларга зур урын бирә, аларны гөнаһсыз фәрештәләр белән тиңли. “Карлыгач”, “Кошларга”, “Кошчык”, “Күгәрчен”, “Фатима белән Сандугач” шигырьләре аша шагыйрь балаларны кечкенәдән үк кошларны яратырга, аларга мәрхәмәтле булырга өнди. Кошларның табигатькә бик күп файда китерүенә басым ясый, аларның иркендә генә матур итеп сайрый алуын әйтә. Үсеп килүче буында табигатькә, аның “тере почмагына” карата мәрхәмәт иясе тәрбияләргә омтыла. Иң кечкенә балаларга язылган “Бала белән күбәләк” шигыре балага гомерлек үгет-нәсыйхәт булырлык. “Бул яхшы, рәнҗетмә һәм тимә син миңа!” [2: 48].

Шагыйрь хайваннар дөньясына да битараф түгел. Аларны ул дуслары, ярдәмчеләре дип саный. Һәркемгә билгеле булган

“Гали белән Кәҗә” шигыре үзе генә дә чын дуслыкның, мәхәббәтнең үрнәге булып тора. Табигатьтәге көчсез хайваннарны кызгана шагыйрь, кешеләрне бәгырьсезлектә гаепли. “Бичара куян” әсәрендә бүре куянның балаларын ашап китә, соңыннан әнкә куянны аучы ата. Ата куян ялгыз кала һәм аның өчен дөньяның яме, яшәүнең мәгънәсе бетә. Автор фикеренчә, явызлык, ерткычлык бәхетсезлек китерә. “Мияубикә” шигырендә шагыйрьне яшь буынның киләчәге борчый. Аларда нинди хисләр өстенлек итәр: мәрхәмәтлелекме, кешелексезлекме? Автор шул мәсьәләләргә туктала. Кеше кайвакыт үзе кылган эшләре турында эш узгач кына уйлана, ләкин инде соң була. Кеше үзен корткычлардан, күсе-тычканнардан саклап торган песинең кадерен белми, аны рәнҗетә, песи үлә. Чын дусты аңа хыянәт итә [1: 23].

Балада үз милләтенә уңай караш, аның белән горурлану, туган теленә мәхәббәт хисләре тәрбияләү – төп бурычларның берсе. *Гыйззәтем, кадрем, йөрәк бәгърем, куанычым, шатлыгым* дигән нинди ягымлы, матур сүзләр белән эндәшә ана үзенең яраткан сабыена [2: 45]. Сөекле шагыйребез “Туган тел” шигыре телебезгә мәхәббәт хисләре тәрбияли.

Татар халкының гимнына әйләнгән “Туган тел” җыры балаларга милли тәрбия бирүдә зур роль уйный. “И туган, и матур тел!” – дип телебез ачылган көннән алып гомеребезнең ахыргы минутларынача Тукай безнең белән. Ул безнең җаныбызда, кылган изге гамәлләребездә.

**ӘДӘБИЯТ**

1. Мәгариф. 1999. № 7. Б. 74-76.
2. Тукай Г. Сайланма әсәрләр. Шагыйрь турында истәлекләр. Казан: Хәтер, 2002. 511 б.

## Х. ТУФАН ИҖАТЫНДА МОТИВЛАР

*Садриева Р., КФУ, I курс магистранты*
*Фән. җит. – филол. фән. канд., доц. Н.М. Йосыпова*

Х. Туфан – татар поэзиясен лирик-фәлсәфи шигырьләр, югары сәнгати дәрәҗәдәге шигъри үрнәкләр белән баеткан шагыйрьләребезнең берсе. Укучыларны тирән фикер йөртергә өйрәтү, икенчел эчтәлекнең мәгънәсенә төшенергә өйрәтү, анализ үзенчәлекләренә төшендерү юлында Х. Туфан иҗаты иң үзенчәлекле шигъри мирасның берсен тәшкил итә.

1.Формановская Н.И. Русский речевой этнкет: лингвистический и методический аспекты. М., 1982. 245 с.

2. Муратов С.Н. Устойчивые словосочетания в тюркских языках. М.: Вост. лит., 1961. 200 с.

## М. МӘҺДИЕВНЕҢ “ТОРНАЛАР ТӨШКӘН ҖИРДӘ” ӘСӘРЕНДӘ САННАР СИМВОЛИКАСЫ

*Хисамова А., Казан, 180 нче полилингваль гимназия, X сыйныф*

*Җит. – Р.М. Мозаффаров, Р.Ә. Абдуллина*

Борынгыдан кешелек фикерләве, танып-белү, ышануының чагылышы булган саннар символикасы дөнья тел картинасының бер фрагменты булып тора һәм ул конкрет бер халыкның милли-культура өлкәсен баетучы семантик күренеш буларак яши.

Символ буларак, саннар яшерен мәгънәләре белән һәрвакыт үзләренә тартып торалар. Саннар кулланышын дөнья тел картинасына бәйләп карау, аны культурологик аспектта ачыклау перспектив һәм **актуаль** юнәлеш булып тора. Әлеге юнәлештә эзләнүләр бер яктан, кешенең характерында яткан универсаль, ягъни бөтен халык өчен хас, икенче яктан, милли специфик үзенчәлекләрне табуга, билгеләүгә мөмкинлек тудыра. Автор фикерен, уй-ниятләрен җиткерү һәм ачып бирүдә алар шулай ук мөһим чара булып хезмәт итәләр.

Бу аспекттагы кызыксынуларны без Татарстанның халык язучысы, галим, мөгаллим М. Мәһдиев иҗатында да ачык күрәбез. Әдипнең бу юнәлештәге кызыксыну, уйлану, эзләнүләре әдәби әсәрләренә дә йогынты ясамый калмаган, дип уйлыйбыз.

М. Мәһдиевнең саннар символикасы белән кызыксынуы очраклы түгел. Үз иҗатында, бигрәк тә истәлекләргә нигезләнеп язган әсәрләрендә ул саннарны күп файдалана. Бу аның стиленә хас төгәллек, вакыйга-күренешләрне чынбарлыкка максималь якын, тәфсилле итеп язуы белән дә бәйле. Әйтик, әдип “Торналар төшкән җирдә” әсәренең “Яшьтәш! Бер сөйләшеп куныйк...” бүлегендә 35 тапкыр төрле төркемчәдәге сан куллана. Еш кына саннар М. Мәһдиев иҗатында мәгълүмати вазифага гына түгел, эмоциональ-экспрессив әһәмияткә ия. “Хикмәтле сан”нарга бәйле деталь-күренешләрне автор әсәрләрендә аеруча яратып, тәфсиләп сурәтли. “Төлке уйный торган орлар...” бүлегендә маш дигән җирне

болайрак тасвирлый: “Кайтканда, без элдертеп кенә маш яныннан уздык. “Маш” – биек дигән сүзме соң? **Кырык** метрлар чамасындагы биеклектә салынган вышкаларны бездә маш дип йөртәләр... Маш **җиде** секциядән тора һәм аны **җиде** баскычлы дип йөртәләр иде... Озын-озын чыршы бүрәнәләрне тимер кучтил белән ялгап **җиде** бүрәнә биеклеге салынган очлы бер корылма зәңгәр күккә ашкан да шомлы сызгырып утыра иде” [2: 28]. Шул рәвешле “җиде” санының кабатлануы сурәтнең тәэсирлеген, яңгыраш-аһәң гармониясен тәэмин итә: “Безнең авылга дөньяның дүрт ягыннан нәкъ **җиде** юл кайтып керә. Һәр **җиде** юлдан кайтканда, авыл, минем туган йортым **җиде** төрле булып күренә” [2: 201].

Символик санны автор бүлек исеменә дә чыгара. Әйтик, повестьта “Җиде аршынлы бүрәнә белән...” исемле бүлек бар: “**Җиде** аршынлы бүрәнә белән китереп төрттеләрмени. Алты-**җиде** адым алга сөрлегеп барып төштем: күтәрелеп карасам, теге, нәсел тәкәсе меринос икән” [2: 116]. Ни өчен нәкъ менә җиде аршынлы, дигән сорау туа? Әдип бу детальне тормыш-көнкүрешнең үзеннән алган булса кирәк. Элек заманда авылда күпчелек йорт бураларының озынлыгы уратча җиде аршын булган. Моңа дәлил итеп Әхмәт Фәйзинең Тукайга багышланган әсәреннән әлеге җөмләне китерергә була: “Шуңа күрә шушы **җиде аршынлы өй** һәм аңа терәп салган өч стеналы кечкенә келәт белән канәгатьләнде” [7].

Кырык санын М.Мәһдиев халык авыз иҗатындагы кебек (“кырык тапкыр әйткән”, “кырыкмаса кырык эш”) күп дигән мәгънәне белдереп куллана. Алда китерелгән мисалда да автор маш (биек мәгънәсендә) дип йөрткән вышкаларның озынлыгы **кырык** метр, ди. Икенче бер урында ул болай яза: “Бу дуслык без мәңгегә аерылганчы – **кырык** ел буена дәвам итте” [2: 180].

Ә менә өч саны аша әдип текст тукымасында, киресенчә, аз дигән мәгънә төсмерләрен җиткерә: “Дөньяда юньле **өч** профессия бар: икмәк үстерү, умарта корты асрау һәм юл төзү” [2: 173].

“Герман җире яшел үлән” исемле бүлектә исә өч саны аеруча еш очрый. “Өч” санының кабатлануы текстка эмоциональ төсмер өсти, күренешләр арасында ассоциатив бәйләнешләр тудыра: “Герман көе” безнең авылга кинәт килеп керде... Моның нибары **өч** җыры бар иде сыман... “Герман” диюгә, авылның **өч** карты искә төшә... **Өч** җан... Мәрфуганың агач табагына табельщик **өч** чүмеч өйрә сала, хисапчы яшел эмаль зур табактан **өч** кисәк ит

алып, чап итеп Мәрфуга табагына ыргыта... Галимша абзый уйный, бу көйгә **өч** кеше берьюлы бии...” [2: 174-177].

Шулай итеп, М. Мәһдиев символик саннарга бәйле күзәтү-чагыштыруларында күп халыкларның көнкүрешендә уртак эш-гамәлләр, ышану, гореф-гадәтләрнең булуын, болар нәтиҗәсендә охшаш лексик берәмлекләр, гыйбарәләр тууын билгели.

М. Мәһдиев иҗатында, бигрәк тә истәлекләргә нигезләнеп язган әсәрләрендә саннарны күп файдалана. Бу аның стиленә хас төгәллек, вакыйга-күренешләрне чынбарлыкка максималь якын, тәфсилле итеп язуга бәйле. М. Мәһдиев аеруча “җиде” санын еш куллана: җиде баскычлы, җиде адым, җиде аршынлы, җиделе лампа, җиде юл һ.б. “Күп” мәгънәсен белдергәндә, әдип “кырык” санын куллана, капма-каршы мәгънә исә текст тукымасында “өч” саны аша төсмерләнә. Еш кына повестьнең аерым өлешләрендә саннарның кабатлануы күзгә ташлана. Шул рәвешле автор сурәтнең тәэсирлеген, яңгыраш-аһәң гармониясен тәэмин итә, күренешләр арасында ассоциатив бәйләнешләр тудыра. (Әйтик, “Герман көе”нә өч җыр – авылның өч фронтовик карты). Шул ук вакытта танып-белү, чынбарлыкны тасвирлау барышында һәр халыкның дөнья тел картинасы милли образларга, төшенчәләргә ия икәнлеге дә аңлашыла.

**ӘДӘБИЯТ**

1. Мәһдиев М. Сайланма әсәрләр. Т. 3. Казан: Тат. кит. нәшр., 2009. 480 б.

2. Мәһдиев М. Сайланма әсәрләр. Т. 5. Казан: Тат. кит. нәшр., 2009. 431 б.

3. Телия В.Н. Метофоризация и ее роль в создании языковой картины мира // Роль человеческого фактора в языке: Язык и картина мира: сб. науч. тр. М., 1988. С. 35-44.

4. Хайруллина Р.Х. Фразеологическая картина мира: от мировидения к миропониманию. Уфа, 2001. 241 с.

5. Фәйзи Ә. Кечкенә Апуш (“Тукай” романының балалар өчен эшкәртелгән варианты). // http://gabdullatukay.ru/in-art/in-literature/novels/ehmet-fejzi-kechkene-apush.

## ТАТАР ТЕЛЕНЕҢ КУШМА ҖӨМЛӘЛӘРЕНДӘГЕ *–ЛЫК* КУШЫМЧАСЫ

*Хисияма Ю., Токио чит телләр университеты аспиранты*

*Җит. – С. Кадзама*

Татар грамматикаларында исем яки сыйфаттан исем ясагыч *–лык* кушымчасы (мәсәлән: *күз-**лек**, яшь-**лек***) турында тасвирланган. Ләкин, кушма җөмләнең (Бу мәкаләдә “кушма җөмлә” – гомуми лингвистикада кулланыла торган “subordinate

clause” сүзенә туры килгән термин буларак кулланыла) төп сүзенә ялганып килгән *–лык* кушымчасы (мәсәлән: *Зояның укучы түгел-**лег**-ен беләм.*) әле җитәрлек дәрәҗә тикшерелмәгән. Бу мәкаләнең максаты – татар теленең кушма җөмләләрендәге *–лык* кушымчасының нинди очракта кулланылуын, ни дәрәҗәдә очравын һәм аның функциясен ачыклау.

Әлеге мәсьәләне без корпус һәм информант (Бу мәкаләдә “төп сүз” – гомуми лингвистикада кулланыла торган “head” сүзенә туры килгән термин буларак кулланыла) ярдәмендә тикшердек: интернетта эшләп килгән “Татар теленең язма корпусы” сайтын (алга таба “корпус”) кулланып, *-лык* кушымчалы кушма җөмләләрне җыеп алдык һәм *-лык* кушымчасының нинди сүзләргә ялгануын һәм аның кулланылу ешлыгын тикшердек. Аннары, корпустан алынган җөмләләрдән *–лык* кушымчасын алып буламы юкмы икәнлеген информанттан сорадык.

Корпустан алынган җөмләләрне тикшергәч, *-лык* кушымчасының түбәндәге сүзләргә ялгануы ачыкланды:

1. Исем фигыльләр: *Авторның бу эшендә Ай әйләнгәндәге үзтирбәнеш амплитудасы шундый зурлыкка китерелә, бу зурлыкны күзәтүләрнең хәзерге көндәге ысуллары нигезендә табып булмау-**лыг**-ын күрсәтүгә тагын бер омтылыш ясала.*

2. Сыйфат фигыльләр: *Сезнең “Сөләйман” мәчетенә укырга килгән-**лег**-егезне ишетеп, мин бик шатландым, дусларым* (*-ган* формасы); *Аның шырпылырак икәнен дә беләбез, һавалырак икәнен дә беләбез, “Мин – даһи!” диебрәк яза торган-**лыг**-ын да беләбез* (*-а торган* формасы); *Пленар утырышта төбәкләрдәге вәзгыятьне, проблемаларны бәян иткән, алга таба нәрсә булыр-**лыг**-ын фаразлаган чыгышлар яңгырар дип өметләнәбез* (*-ыр* формасы); *Хәер, санап карагач, Алмазның 2024 елда һич тә “пенсионер көрәшче” яшендә булмаячак-**лыг**-ы ачыкланды үзе* (*-ачак* формасы).

3. Бәйләвечләр (Бу мәкаләдә “бәйләвеч” – гомуми лингвистикада кулланыла торган “copula” сүзенә туры килгән термин буларак кулланыла). *Минем робот икән-**лег**-емне Гөлнур гына белә* (*икән*); *Синең дә сыер савучы булырга каршы түгел-**лег**-еңне әйтермен* (*түгел*).

4. Модаль сүзләр: *Кеше безнең кибеттә кайда нәрсә бар-**лыг**-ын белмәскә дә мөмкин* (*бар*); *Бүлмәдә тәртип юк-**лыг**-ын үзем дә беләм* (*юк*); *Мин аларга ярдәмем өчен генә кирәк-**лег**-емне аңлыйм* (*кирәк*); *Әмма миңа тагын бер барырга кирәк-**лег**-ен*

*тойдым* (*кирәк*); *Анда минем ничек йокларга, кайчан уянырга, ничек атларга, хәтта ничек суларга тиеш-**лег**-ем – барысы да күрсәтелгән* (*тиеш*); *Әлеге очрак һәрберебезнең мондый хәлгә дучар булырга мөмкин-**лег**-ебезне дәлилли кебек* (*мөмкин*).

5. Башкалар: *Аның белән 2009 елдан бирле аралашмыйбыз, шуңа күрә аның кайда-**лыг**-ын әйтә алмыйм* (сорау алмашлыклары); *Татарстан хөкүмәте башлыгы, республика президенты вәкаләтләре бирелгән Рөстәм Миңнеханов Казандагы транспортның бик күп-**лег**-ен һәм юл челтәренең камил булмавын иң зур проблема буларак атады* (сыйфатлар); *Әниебез телевизордан ишетеп беләдер инде теплоходның батканын, тик Зөһрәнең анда-**лыг**-ын әле белми* (урын-вакыт килешле сүзләр).

Корпус анализы нәтиҗәләре күрсәтүенчә, кушма җөмләдәге *–лык* кушымчасының кулланылу ешлыгы түбәндәгечә:

1. Исем фигыльләр: үрнәкләр бик аз, гомумән *–лык* кушымчасыз форма кулланыла;

2. Сыйфат фигыльләр:

-*ган* формасы: -*лык* кушымчасыз форма күбрәк очрый;

-*а торган* формасы: үрнәкләр бик аз, гомумән *–лык* кушымчасыз форма кулланыла;

-*ыр* формасы: -*лык* кушымчасыз форма күбрәк очрый;

-*асы* формасы: -*лык* кушымчасы ялганмый;

-*ачак* формасы: үрнәкләр бик аз, гомумән *–лык* кушымчасыз форма кулланыла.

3. Бәйләвечләр:

*икән*: -*лык* кушымчасыз форма күбрәк очрый;

*түгел*: -*лык* кушымчалы форма күбрәк очрый.

4. Модаль сүзләр:

*бар, юк*: -*лык* кушымчалы форма күбрәк очрый;

*кирәк, тиеш*: -*лык* кушымчалы форма күбрәк очрый;

*мөмкин*: -*лык* кушымчасыз мөмкин түгел.

5. Башкалар:

Сорау алмашлыклары: -*лык* кушымчасыз мөмкин түгел;

Сыйфатлар: үрнәкләр бик аз, -*лык* кушымчасыз мөмкин түгел;

Урын-вакыт килешле сүзләр: үрнәкләр бик аз, -*лык* кушымчасыз мөмкин түгел.

Күренгәнчә, нинди сүзгә ялгануына карап, -*лык* кушымчасының кулланылу ешлыгында аерма бар һәм күп очракта ул ялганырга да ялганмаска да мөмкин.

*-лык* кушымчасының функциясенә килгәндә, татар грамматикаларында сыйфат фигыльнең *–ган* формасына *–лык* кушымчасы ялганып ясалган *–ганлык* формасы турында, аның үткән заманга мөнәсәбәтле эш-хәлне белдерүе [1: 235], процессның үтәлгән булуына басым ясарга кирәк булганда уңышлырак яңгыравы аңлатыла [2: 241]. Ersen-Rasch *икәнлек* сүзе турында, аның *икән* сүзенә караганда язма телдә күбрәк очравын һәм дәвамлы хәлне белдергәндә кулланылуын аңлата [3: 151].

Ләкин, информант әйтүенчә, "*Әгәр телисең икән, Ләйләгә минем кем-**лег**-емне әйтмә.*" җөмләсенең "*кемлегемне*" сүзен "*кем икән(лег)емне*", "*кем булуымны*", "*кем булганлыгымны*" сүзләре белән алыштырып булса да, "*кем булганымны*" белән алыштырып булмый. Димәк, *-ганлык* формасындагы *–лык* кушымчасы – үткән заманга мөнәсәбәтле *–ган* формасына ялганып, хәзерге эш-хәлне белдерүче форманы ясау ролен үти. Бу яктан, *-ганлык* формасына ялганган *–лык* кушымчасының функциясе – Ersen-Rasch аңлаткан *икән* сүзенә ялганган *–лык* кушымчасыныкына охшаш булып тора.

Информант әйтүенчә, түбәндәге җөмләләр *–лык* кушымчасыз мөмкин түгел: *Бүгенге финанс кризисы – моның шулай булган-**лыг**-ы күрсәткече*; *Чуаш зиратларындагы баганаларга төшерелгән билгеләрнең язумы түгелме икән-**лег**-е мәсьәләсен галимнәр ул вакытларда артык тикшереп тормаганнар.* Күренгәнчә, бу җөмләләрдә кушма җөмлә – 2 нче төр изафә бәйләнешенең беренче компонентын тәшкил итә. Мондый конструкциядә *–лык* кушымчасы – кушма җөмләнең синтаксис ягыннан исемгә якын булуына басым ясау функциясен башкара.

**ӘДӘБИЯТ**


1. Закиев М.З. и др. Татарская грамматика. Т.II. Морфология. Казань: Академия наук Татарстана, 1993. 397 с.
2. Хисамова Ф.М. Татар теле морфологиясе. Казан: Мәгариф, 2006. 335 б.
3. Ersen-Rasch, Margarete I. Tatarisch: Lehrbuch für Anfänger und Fortgeschrittene. Wiesbaden: Harrassowitz, 2009. 239 s.
4. "Татар теленең язма корпусы" сайты// http://corpus.tatfolk.ru/index_tt.php


## XX ГАСЫР АХЫРЫНДА БАСЫЛГАН ТАТАРЧА-РУСЧА СҮЗЛЕКЛӘР


*Хөснуллина Г., КФУ, II курс магистранты*

*Фән. җит. – филол. фән. канд., доц. Р.С. Нурмөхәммәтова*


Ике телле (тәрҗемәле) сүзлекләр һәр телдә дә киң таралган сүзлекләрдән санала. Алар төрле вариантта эшләнә. Мәсәлән,

балалар бакчасына, урта мәктәп аудиториясенә, югары мәктәпкә атап махсус эшләнгәннәре дә бар. Алар уку-укыту характерын алалар. Соңгы елларда бу төр сүзлекләрне эшләү тагын да үсә бара, чөнки мондый сүзлекләр шул телдә сөйләшүчеләр тарафыннан гына түгел, шул халык яшәгән башка илләрдә дә чыгарыла башлый.

Тәрҗемәле сүзлекләрдә барлык баш сүзләр дә ярым калын шрифт белән әлифба тәртибендә урнаштырыла. Бер үк сүзнең төрле сүз төркеменә караган очраклары да күрсәтелә. Бер иҗекле сүзләрдән кала, барлык сүзләргә дә басым куела. Тәрҗемә ителәсе сүз янында сүз төркеме күрсәтелә, шулай ук кушымчалары да бирелә. Мондый сүзлекләрнең бурычы – укучыны иң кирәкле, иң әһәмиятле материал белән тәэмин итү.

XX гасырның II яртысында 5 татарча-русча сүзлек басыла: Татарча-русча сүзлек (1950); Татарча-русча сүзлек (1966); Татарча-русча сүзлек (1988); Татарча-русча сүзлек (1995); Татарча-русча сүзлек (1998).

СССР фәннәр академиясенең Казан Тел, әдәбият һәм тарих институты 1950 елда 20 мең сүзне үз эченә алган татарча-русча сүзлек чыгара.

1966 елда Мәскәүнең "Советская энциклопедия" нәшриятында "Татарско-русский словарь" басылып чыга. Сүзлек үзенең төгәллеге, тыгызлыгы, куллану өчен уңайлыгы белән аерылып тора. Сүзлек югарыда әйтелгән шул ук Институт хезмәткәрләре тарафыннан төзелгән [2: 34].

XX гасырның 90нчы еллары татар лексикографиясенең күтәрелеш чоры дип атала ала. Нәкъ менә шушы вакытта күптөрле терминологик, тәрҗемәле һ.б. сүзлекләр төзелә башлый. Ике дистә ел вакыт үткәннән соң, 1988 елда татар җәмәгатьчелеге кулына яңа "Татарча-русча сүзлек" ала. Профессор Ф.Ә. Ганиев редакциясендә чыккан бу сүзлек лексикографик тәҗрибәсе зур булган галимнәр тарафыннан (Ф.Ә. Ганиев, И.А. Абдуллин, М.Г. Мөхәммәдиев, Р.Ә. Юналиева) төзелгән. Аның нигезен "Татар теленең аңлатмалы сүзлеге" тәшкил итә һәм анда актив кулланылыштагы 25 мең сүз теркәлгән. Аның төп максаты – татар сүзләренең русчага дөрес һәм төгәл тәрҗемәсен бирү. Шуның белән беррәттән, анда сүзләрнең грамматик һәм мәгънәви табигатен һәм кайбер фразеологик берәмлекләрне теркәү дә күз алдында тотыла.

Сүзлектә иҗтимагый тормышта яңарак урын алган төшенчәләрне белдерүче яңа сүзләр дә теркәлгән: *лавсан*, *кримплен*,

*рентабельле, күбәйтү аппараты* һ.б. Сүзлектә бай фразеология, татар халкының тарихына, гореф-гадәтләренә, мәдәниятенә, милли бәйрәмнәренә, дини ышануларга, аш-су һәм башка өлкәләргә караган төшенчәләр урын алган, кайбер очракларда аларга кыскача аңлатма да бирелгән.

Сүзлек соңгы гасырда татар телендә булган сыйфат үзгәрешләрен дә ачык чагылдыра: күп сүзләрнең рус сүзләре белән алышыну закончалыгын күрергә мөмкин. Кызганыч хәл, без күп сүзләребезне оныта барабыз, булганнарын саклый белмибез икән. *Катаракта* сүзе кергәнче халыкта *кылау* сүзе таралган булган; *франт* сүзе урынына элек *кәрбәз* сүзен кулланганнар; *каштан – кәстәнә, осетр – бикрә, капюшон көрәпәлә* дип йөртелгән; *цикорий* урынына *күнаяк, һиндыба* кулланылган һ.б.

Бу сүзлектә яңалыклар шактый: 1) фигыль формалары, элекке сүзлекләрдән аермалы буларак, -рга/-ргә формасында бирелә. Авторлар аны үзенең мәгънәсе һәм кулланылышы ягыннан тулысынча рус инфинитивына туры килә дигән караштa торалар; 2) сүзлектә лексик берәмлекләргә морфологик характеристика бирелә, ягъни теге яки бу сүзнең кайсы сүз төркеменә каравы күрсәтелә; 3) предикатив (хәбәрлек) сүзләр дигән сүзләр аерып күрсәтелгәннәр; 4) сүзләрнең мәгънәви характеристикасы тагын да камилләшкән, сүзләрнең мәгънәләре тагын да арта төшүе күрсәтелгән; 5) тезмә сүзләр һәм фразеологик берәмлекләр төгәл аерылган. Яңа сүзлектә сүзнең шәрехнамәсе өч кисәктән тора: баш сүз бирелгән, аның мәгънәләре теркәлгән, аннан тезмәләр китерелгән, аннан соң фразеология теркәлгән; 6) рус һәм татар сүзләренең омоним очракларында *к, г* янына калынлык билгесе өстәп, тирән тел арты авазларын биргәннәр: *аркъа – арка, болгъар – болгар* һ.б.; 7) сүзлеккә кайбер регуляр формалар да теркәлгән: *агар, исемле, нишләмәк, сап-салкын, сап-сары* һ.б. Алар рус телендә теге яки бу яңа лексик берәмлек булып тәрҗемә ителгән очракта гына китерелгән.

Сүзлеккә ике кушымта бирелгән. Беренчесендә – Татарстанның географик атамалары исемлеге, икенчесендә актив кулланыла торган татар исемнәре бирелгән һәм аларның русчага транскрипциясе күрсәтелгән.

1988 елгы сүзлек халык арасында тиз тарала. 1995, 1998 нче елларда аның икенче, өченче басмалары дөнья күрә.

Сүзлекләр, җәмгыятьнең көзгесе буларак, шул үсеш-үзгәрешләрне объектив рәвештә теркәп барганнар. Алар татар теле фонетикасын, лексикасын фәнни яктан өйрәнү өчен ышанычлы материал бирәләр һәм яңа, тагы да камилләшкәнрәк татарча-русча сүзлекләр төзү өчен ныклы нигез булып торалар.

**ӘДӘБИЯТ**


1. Нурмухаметова Р.С. Татарча-русча сүзлекләр тарихына кыскача күзәтү (XX гасыр) // Прикладные аспекты сопоставительной лингвистики: обучение иностранному языку с опорой на родной язык: материалы II международной научно-практической конференции. Казань: Отечество, 2015. С. 75-78.
2. Сафиуллина Ф.С., Зәкиев М.З. Хәзерге татар әдәби теле: Лексикология, фразеология, фонетика, графика һәм орфография, орфоэпия, сүз ясалышы, морфология, синтаксис. Казан: Мәгариф, 1994. 320 б.
3. Татарско-русский словарь: Ок. 25 000 слов / И.А. Абдуллин, Ф.А. Ганиев, М.Г. Мухамадиев, Р.А. Юналеева; Под.ред. Ф.А. Ганиева. Казань: Тат. кн. изд-во, 1988. 462 с.
4. Татарча-русча сүзлек / Төз. Р.Газизов, Н.Исәнбәт һәм Г.Ишмөхәммәтов. Казан: Татгосиздат, 1950. 340 б.
5. Татарча-русча сүзлек. М.: Советская энциклопедия, 1966. 864 б.


## ЧУВАШИЯ ҖИРЛӘРЕНДӘ ЯШӘГӘН ТАТАРЛАРНЫҢ АКТУАЛЬ ПРОБЛЕМАЛАРЫ


*Хөснетдинова Ә., Чувашия, Шыгырдан,1 нче мәктәп, XI сыйныф*

*Җит. – З.Ш. Мтеева*


Борынгы заманда кайбер халыкларда колның хәтерен югалтыр өчен башына чи тире кидергәннәр. Тире, кипкән саен башны кысып, колны түзә алмаслык газапларга дучар иткән. Кол үзенең кем икәнлеген дә, кайдан, кайсы нәселдән булуын да хәтерләмәс хәлгә килгән.

Без үзебез дә шул хәлгә калмас өчен, үзебезнең тарихыбыз белән кызыксынырга тиеш дип уйлыйм һәм үземнең эшем итеп татар халкының килеп чыгышын һәм Чувашия татарларының теле, язмышы турында эзләнүләр алып барырга телим.

Минем кулыма “Советская Чувашия” дигән гәҗит килеп эләкте. Анда чуаш галиме тарафыннан “татар тарихын ачыкламыйча чуашларныкын белү кыен” дигән фикер язылган. Дөресе дә шулай, чөнки безнең яктагы татарлар гомер-гомергә дус, тату яшәгәннәр, тыгыз мөнәсәбәттә булганнар.

Һәр милләт кешесе үзенең килеп чыгышы, үз халкының тарихын белергә тырыша. Авылның, өлкәнең тарихын, халыкның гореф-гадәтләрен, мәдәниятен, динен тирәнтен белү бик мөһим.

Халкым күпме изелсә дә үзенең ана телен саклап калды. ә милләтнең саклануы турыдан- туры телгә бәйле. Мин үзем Татарстан белән читтәш булган Чувашия җирлегендә яшим. Бу як татар халыкларының теле, җыры, моңы да бер үк.

Чуваш Республикасы 18 мең 300 кв. км. җир били. ә татарлар саны 3% чамасы. Башкалабыз Чебоксар шәһәреннән алып төрле авыл һәм районнарда безнең милләттәшләребез яши. Ә үзебезнең Батыр районнында саф татар авыллары җидәү: Шыгырдан, Кыр Бикшеге, Озын Куак, Кзыл – Камыш, Татар Согыты, Кызыл Чишмә һәм Татар Тимәше.

Бу авылларда милләтебезнең матур гореф-гадәтләре, телебез сакланып калган. Ләкин шулай да милләт язмышы хакында уйланулар бүгенге көнгә кадәр дәвам итә. Татар милләтенең киләчәге бармы? Ул өметлеме? Чуваш җирлегендә адашып калган милләттәшләребез үз ана телләрен югалтмаслармы? Чуваш халыклары белән беррәттән татар халкы лаеклы урын алырмы? Менә шушы мәсьәләләр бүгенге аек акыллы яшь буынны, шул исәптән мине дә, борчый.

Бүгенге көндә телне саклау проблемалары үзенә зур игътибар таләп итә. “Кешенең борынгыдан килгән гуманлы карашларына, гореф – гадәтләренә, еллар буена сыналып килгән тормыш тәҗрибәсенә хилаф килердәй, аны рухи, әхлакый яктан рәнҗетердәй башбаштаклык ахыр чиктә табигатькә дә зарар булып төшәр”, – дип язган халык язучысы Г. Бәширов.

Татар милләте турындагы кайсы гына проблемаларны алма, аларның һәркайсын актуаль дияр идем мин.

Кайсыбер ата-аналар нәрсәгә соң ул татар телен белергә, яшьтән үк чит телне өйрәнә башларга кирәк дип уйлыйлар. Мин бу фикер белән килешмим. Чөнки бала ана телендә аң, белем һәм тәрбия ала, шул телдә төпле генә иттереп фикер йөртә. “Кешене ана теленнән аеру, яңа туган баланы ана сөтеннән аерып ясалма сөт белән тукландыруга тин”, – дип фикер йөртә Айдар Халим.

Тагын бер актуаль проблема катнаш гайләләр булып тора. Тел бит ул милләт белән бергә туа, бергә үсә, бергә үлә.

Катнаш никахлар бүген гадәти хәлгә әверелде. Мәхәббәт күңелләргә иңгәч, сөйгән кешеңнең нинди диндә булуын уйлап тормыйсың. Иң мөһиме – бер-береңне ярату кебек тоела. Әмма мондый катнаш никахларның күбесе телне бетерүгә китерә. Бала ата-ана тәэсиренә дучар булып, чит телдә аралашырга мәҗбүр була.

Тел – буыннан-буынга ана сөте белән күчә килгән иң мөкатдәс бер мирас. Менә шул байлыкны, хәзинәне кадерләп саклап калу безнең бурычыбыз. Әмма Татарстаннан читтә, башка төбәкләрдә, чит илләрдә яшәп яткан телләрен, гореф-гадәтләрен югалтмаган татарлар, үзләренең мирасын яшь буынга тапшыра алырмы? Шул буын кешеләре динне, телне саклый алырмы?

Чөнки мәктәптә югары сыйныф укучыларының татар теле һәм әдәбияты дәресләре укыту сәгатьләренең саны кыскарды. Бу мәсьәлә дә татар теленең үсешенә бик зур киртә булып тора. Әгәр татар телен бетерүгә юл куйсак, тора-бара туган телебез бөтенләй юкка чыгачак. Ә тел белән бергә тарих та, мәдәният тә һәм тел белән бәйле булган башка нәрсәләр дә юкка чыгачак.

Тагын бер проблема булып татар телевидениясе тора. Бездә бары бер канал гына татар телендә күрсәтә. Бу ТНВ каналы. Вакыт-вакыт анысы да юкка чыга.

Үзебезнең Батыр районында гына ике татар мәктәбе ябылды. Кызыл-Чишмә һәм Татар Тимәш авыл балалары күрше чуваш авылларына укырга йөрергә мәҗбүр ителделәр.

Ә мин үзем татар баласы, барлык телләргә дә хөрмәт белән карыйм. Рус телендә әйбәт сөйләшәм, инглиз, чуваш телен өйрәнәм. Ә туган телем – татар телем, анам теле булганы өчен ул миңа аеруча якын. Мин аның киләчәге өчен һич тә битараф була алмыйм. Ул миңа тудырган анам кебек, туган җирем кебек якын. Шуңа күрә аның киләчәге матур буласына ышанам.

Нәтиҗә ясап шуны әйтәсем килә: тел – милләт сакчысы. Тел бетсә-милләт тә бетә. Минемчә, татар теленең киләчәге бары тик бездән генә тора. Безнең аңа карашыбыз битараф булмас. Чөнки туган телебез – үзе бер сихри дөнья. Туган телебез – безнең тарихыбыз. Без һичшиксез, әлеге тарихны дәвам итүчеләр, ана телен саклаучылар булырбыз. Чөнки без туган телебезне яратабыз.

**ӘДӘБИЯТ**


1. Батыревская энциклопедия. Чебоксары: Чувашия, 2005. 373 с.
2. Зәкиев М.З. Татар теленең барлыкка килүе. Казан, 1977. 208 б.
3. Фәхреддин Р. Болгар вә Казан төрекләре. Казан. 1993. 240 б.


## НАЦИОНАЛЬНЫЕ ОБРЯДЫ В ТВОРЧЕСТВЕ Б. УРМАНЧЕ


*Шадрина С., Буинский р-он, Больше-Фроловская СОШ, X класс*

*Рук. – Г.Т. Исмагилова*


Баки Идрисович Урманче (1897-1990) – основоположник татарского изобразительного искусства, первый татарский худож-

ник столь масштабного дарования, живописец, график, скульптор, монументалист, театральный художник, сумевший внести неоценимый вклад в развитие основных видов изобразительного искусства Татарстана, во многом определивший становление татарского изобразительного искусства в 1920-е годы и его развитие во второй половине XX века. По праву можно назвать художником международного масштаба – велик вклад Б.И. Урманче в развитие искусства и художественного образования Казахстана и Узбекистана, где он жил в 1940-1950-е годы, работая над живописными, графическими, скульптурными, монументально-декоративными произведениями.

Создавая в 1920-е годы новое для татарского народа искусство, базируясь на достижениях европейской художественной культуры, Урманче всегда оставался глубоко национальным художником, для которого понятие национального не ограничивалось выбором сюжета и темы, но обогащалось поисками общих для разных видов татарского искусства – декоративно-прикладного, каллиграфии – методов и приемов, возможностей их использования в живописи, графике, скульптуре, привнесения в структуру произведения традиционных принципов формообразования, колорита, ритма, мелодики, воплощения того, что называют национальным духом.

Творчество народного художника РСФСР, лауреата Государственной премии ТАССР им. Г. Тукая Баки Идрисовича Урманче было исключительно многогранно.

Признанный скульптор, живописец, он занимался и графикой, в том числе книжной. Кроме того, театральные декорации, эскизы сценических костюмов по мотивам татарского народного искусства, архитектуре проекты – в каждой области проявлялась широкая и яркая, богато одаренная натура этого феноменального художника, как в юности, так и в преклонном возрасте работающего одинаково продуктивно и одухотворенно.

Он кропотливо изучал и любовно изображал жизнь многонациональной нашей страны. Его творчество подлинно интернационально, но и нерасторжимо связано с культурой татарского народа, глубокие корни которой ведут к сокровищнице искусства древних булгар. Художник любит историю, прекрасно знает быт, традиции своего народа. Вышивка и ткачество, рисование узоров, народные промыслы были неотъемлемыми занятиями и в семье Урманче, в деревне Куль-Черкене Буинского района, где он родился 23 февраля 1897 г. Домашнее производство тканей, пряжи –

обычное занятие татарских крестьян. Дед его Хасан Урманче жил трудом красителя. Правда, ни чанов его с красками, ни тканей, вывешенных для сушки, будущий художник не застал, знает лишь по рассказам односельчан.

Счастливо сочетая свой редкий природный талант с упорным трудолюбием и высоким образованием, Б.И. Урманче создал более 3000 графических работ, около 300 живописных полотен и более 100 скульптур.

Творчество Г.Тукая было для Урманче неиссякаемым источником вдохновения всю жизнь. Художник долгие годы работал над графическими сериями «Шурале», «Кисекбаш» и другими. Они включают десятки и сотни листов. Это не простые иллюстрации, а подлинное сотворчество. При раскрытии этих тем художник находит все новые и новые приемы. Любая его работа выполняется с пониманием стиля народного искусства, в то же время в духе культурных традиций Востока и высоких достижений мирового искусства. Эти произведения далеки от простой стилизации, проникнуты поэзией и музыкой. Художник продолжает свой творческий труд и в живописи. В цикле «Воспоминания» интересна оригинальная творческая концепция. «В предгорьях Урала», «Сенокос в Салтыке», «Сабантуй» и другие полотна из этого цикла художник создал, используя традиции древних миниатюр, книжной и рукописной графики Востока, традиции татарского народного творчества и высокие культурные достижения современности. Находя изящное, композиционное и цветовое решение, Урманче стремится в этих картинах к декоративности и монументальности. Продолжая работать в области синтеза скульптуры и архитектуры, Урманче завершил в 1976 году мемориальный комплекс Дома-музея Тукая в Кырлае.

Работа над образом Г. Тукая открыла серию скульптурных портретов выдающихся деятелей татарской культуры: Ф. Амирхана, Г. Камала, Г. Ибрагимова, Н. Жиганова, М. Джалиля, Дэрдменда, К. Гали и других, за которую в 1967 г. Б. И. Урманче была присуждена Республиканская премия им. Г. Тукая.

В этот период им были созданы философски обобщенные аллегорические скульптуры «Сагыш», «Весенние мелодии», «Сююмбике»; живописные композиции «Приезд Ибн Фадлана в Булгары», «Сабантуй», триптих «Татарстан»; серия графических портретов лучших представителей интеллигенции и многое другое.

Одной из главных черт произведений Урманче исследователи считают их ярко выраженную национальную принадлежность. О своем труде художник говорил: «Мне не нравится выражение «служить народу», оно звучит несколько тривиально и не может выразить содержание и смысл моего труда. Ведь я живу одной жизнью с моим народом, с его страданиями и его счастьем. Его страдания и радости – это мои страдания и радости. Я хочу их выразить, я хочу рассказать о них в своих работах. О его героях и художниках, о борцах и поэтах, о молодости, любви и труде».

Глубоко проникая в думы татарского народа, в его психологию, умело используя элементы народного искусства и осваивая культурное наследие, Урманче создает подлинно национальное искусство.

Из 93 лет жизни 70 он посвятил искусству, продолжая упорно трудиться до последних дней жизни. Б. Урманче умер 6 августа 1990 году. В 1999 г. в Казани был открыт музей Б. Урманче. В городах Татарстана – Буинске, Зеленодольске, Нижнекамске, Набережных Челнах – названы улицы в честь художника. Дом музей Б.Урманче (Филиал МБУ «Буинского краеведческого музея) открылся в феврале 2012 года.

## ТАТАРСКИЙ ЯЗЫК В ОБЛАСТИ КОМПЬЮТЕРНЫХ ТЕХНОЛОГИЙ: ОСОБЕННОСТИ МАШИННОГО ПЕРЕВОДА

*Шарапов К., КФУ, магистрант I курса*

*Науч. рук. – канд. филол. наук, доц. М.Р. Саттарова*

Татарско-русский и русско-татарский переводчик – это первая попытка создания машинного переводчика на материалах агглютинативного и флективного языков.

В данной статье произведена попытка понять логику построения татарско-русского и русско-татарского электронного переводчика, а также будут рассмотрены проблемы, которые появляются при составлении подобных переводчиков.

Для примеров были использованы алгоритмы и данные татарско-русского переводчика, т.к. именно здесь лингвистические проблемы проявляются наиболее заметно, и именно татарско-русский переводчик более востребован как в нашей республике, так и за ее пределами. Электронный переводчик – незаменимый помощник, который помогает переводить тексты как с русского на татарский язык, так и наоборот, с татарского на русский. Это могут

быть переводы статей, произведений, или создание чего-то. По этой причине данную проблему мы считаем актуальной.

Во-первых, все электронные переводчики делятся на два типа: онлайн переводчики и локальные переводчики. Они отличаются друг от друга, в первую очередь, методикой обработки базы данных.

Онлайн переводчики, имеющие неограниченный запас ресурсов, берут простым количеством материала. Если говорить другими словами, они вводят в свои базы данных большое количество правильно переведенных параллельных текстов. На основе обработки большого объема информации программа сама моделирует предложение. Логично, что сначала в словари вводятся, самые простые парадигмы, в том случае, если они возможны, все зависит от структуры языка.И еще самые простые морфологические схемы. А синтаксические схемы машина вырабатывает уже на базе правильных параллельных предложений.

Локальные же переводчики не могут справиться с обработкой огромного количества информации, и они идут по пути внедрения различных парадигм, синтаксических правил, правил синтаксической сочетаемости слов, порядка предложения, и, наконец, правил семантической сочетаемости слов. Иными словами, локальные переводчики призваны распознать слова, словосочетания, отнести их в нужные разряды, и на основе этого сделать перевод. После этого необходимо правильно расположить эти слова в самом переводе, для того, чтобы в результате получился осмысленный текст, а не набор слов. Таким образом, локальные переводчики призваны сделать осмысленный перевод, насколько это возможно машине. Локальные переводчики связаны с проблемой формализации значения. Конечно, электронные переводчики не могут перевести весь текст, чтобы потом после нее не проводить поправки ошибок синтаксического характера. Но, несмотря на это, это очень облегчает задачу переводчика.

Если же говорить именно о татарско-русском электронном переводчике, то тут необходимо затронуть уже особенности правил татарского языка. Морфологический анализ слов не дает полной определенности в соотнесении того или иного слова к определенной части речи. К примеру, если в русском языке имена прилагательные, наречия имеют формальные признаки, то подобных у татарских «свойств» нет. Чаще всего они определяются

только семантически. Но так как «железо» и семантика – вещи несовместимые, то многие лексемы определяются лишь по их функционированию (местоположению) в предложении. Не случайно Г. Алпаров, Дж. Валиди и многие другие лингвисты в своей грамматической среде не выделяли их как самостоятельные части речи, а рассматривал функциональными формами имени существительного. Вольное содержание высказывание приведем из «Татарской грамматики»: «Дж. Валиди говорит о том, что русские выделяют прилагательные в отдельную часть речи не столько по значению, сколько по окончаниям, а в татарском языке прилагательные таких особых показателей не имеют, они различаются лишь по значению».

Смысловой и функциональный характер татарской морфологии придает дополнительную сложность при определении части речи татарского языка. Данное явление придает татарскому языку своеобразный аналитический характер. Русский язык, являясь синтетическим языком, опирается на формальные, в то время, как татарский язык опирается на функциональные характеристики. Таким образом, «синтаксический характер» татарского языка порождает огромное количество омоформ.

Например, практически каждый односложный глагол в повелительном наклонении имеет одну или две омоформы: яз (пиши, пахтай) и яз (весна), кара (смотри) и кара (черный, чернила).

Большое количество татарских омоформ можно разграничить между собой только путем синтаксического или семантического анализа.

Появлению такого количества омонимичных форм способствует и то, что татарский язык придерживается фонетического принципа орфографии. К примеру, при разработке французского-русского и английско-русского переводчиков эта проблема разрешается само собой, так как в этих языках преобладает традиционный принцип написания.

Вообще, недостатки татарской орфографической системы придают работе электронного переводчика дополнительные трудности. Различные написания слов в различных изданиях, сознательное пренебрежение некоторыми авторами уже принятых норм – все это лишь препятствует вхождению татарского языка в общемировую информационную сеть.

Составление электронных переводчиков – необходимый элемент развития тех языковых культур, которые при условиях глобализации, испытывают серьезное давление со стороны «мировых» языков: английского, испанского, русского и т.п.

На современном этапе локальные переводчики имеют очень малое количество языков. «Малые» языки предпочитают онлайн переводчики, в которых не разрабатывается система формально-грамматических правил, правил семантической сочетаемости и проблем контекстуальности (последнее особенно важно для татарского языка). Именно наличие локального переводчика в системе мировых языков позволит внести татарский язык и в мобильные переводчики, и в сотовые телефоны, и в другие технологии.

**ЛИТЕРАТУРА**

1. Татарская грамматика: Т.2. Морфология. Казань: Татар. кн. изд-во, 1993. 397 с.

## ХӘЗЕРГЕ ТАТАР ТЕЛЕНДӘ ГАРӘП ТАМЫРЛАРЫНЫҢ ЛЕКСИК-СЕМАНТИК ҮЗЛӘШТЕРЕЛЕШЕ

*Шафикова Р., КФУ, II курс магистранты*

*Фән. җит. – филол. фән. канд., доц. Э.Н. Денмөхәммәтова*

Татар тел гыйлемендә сүз ясалышы мөстәкыйль бүлек буларак аерылып чыгарыла, бу өлкәдә шактый фәнни эзләнүләр алып барыла. Гарәп тел белемендә сүзләрнең ясалышы, ясалу ысуллары гыйльмүл-иштикак (الا شـ تـ قاق ع لم) һәм аларның үзгәрүе шулай ук гыйльмүс-сарф (الـ صرف ع لم) яки әт-тәсриф (التَّصْرِيفُ) фәннәрендә өйрәнелә. Безнең тикшеренүебез гарәп тамырларының хәзерге татар әдәби теленең сүз ясалышында үзләштерелүен күзәтүне, татар һәм гарәп телләрендә тамырдаш сүзләрне анализлауны максат итеп куя. Татар теленең актив лексикасына кергән күпсанлы гарәп алынмалары лексик-семантик яктан төрле дәрәҗәдә үзләштерелгән. Гарәп теленең лексик-семантик яктан дөньядагы иң бай телләрнең берсе булып торуы билгеле. Телдә бүгенге көнгә кадәр борынгы гарәп теленең асыл тамырлары сакланып калган. Гасырлар дәвамында бу асыл фигыльләргә яңа мәгънә төсмерләре өстәлүе, телнең бай сүзьясалыш ысуллары да аның лексик-семантик үсешендә зур урын алып тора. Әлбәттә, һәр телдә дә алынма лексика семантик яктан үзгәреш кичерә, еш кына татар телендә гарәп алынмаларының мәгънәләренең тараюы күренә. Мондый нәтиҗә ясарга аңлатмалы, ике телле сүзлекләрне күзәтү, ике телдә сүзләрнең семантикасын чагыштыру мөмкинлек бирә.

Берничә мисал карап китик. Гарәп телендә خزن (“хазәнә”) тамыры нәрсәнедер җыю, саклау мәгънәсен белдерә. Гарәп телендә беренче һәм сигезенче бабларда кулланыла. Татар телендә хәзинә сүзе 1) милек, мал-мөлкәт, кыйммәтле әйберләр; 2) яшерелгән акча; 3) табигый байлык; 4) рухи һәм мәдәният байлыклары мәгънәләренә ия [2: 638]. Гарәп телендә бу исемнең мәгънәләре киңрәк, ул шулай ук казна, казначейлык, кассаны да белдерә. Аңлашыла ки, казна (гарәп “хәзинә”) сүзе рус теленә татар теле аша кергән. Гарәп алынмалары сүзлегеннән күренгәнчә, элек телебездә бу мәгънәдә хәзинә сүзе кулланылган [3: 673]. Бу очракта гарәп алынмасының мәгънәсенең тараюы һәм рус теле йогынтысы нәтиҗәсендә фонетик үзгәрешләр кичерүе күзәтелә. Шушы тамырдан ясалган مخزن “махзан” сүзенең татар һәм рус телләрендә кулланылышы кызыклы. Татар теленең аңлатмалы сүзлегендә магазин сүзе сөйләү теленә хас сүз буларак теркәлгән һәм 1) нәрсә белән булса да сәүдә итү өчен төзелгән бина, кибет; 2) апаратта, әсбапта нәрсә булса да салу өчен хезмәт итә торган җайланма дип аңлатылган [2: 351]. Бу сүзнең рус теленә кайчандыр төрки телләр аша кергәне аңлашыла. Чыганак телдә исә бу урын исеменең мәгънәләре киңрәк, һәр очракта да ул нәрсәнеңдер саклану урынын билгели: 1) гомумән саклау урыны, амбар; 2) парк (трамвай, троллейбус һ.б. парклы); 3) кибет; 4) патрон кысасы; 5) Мароккода хакимиятне белдерә.

Татар теленең дини лексикасына караган гарәп алынмаларының мәгънә ягыннан шактый тараюы күзәтелә. Моны әлеге лексик катламга караган сүзләрнең телгә асылда Ислам кануннары һәм мәдәнияте белән бәйле рәвештә үтеп керүе белән аңлатырга мөмкин, шул ук вакытта әлеге лексемалар татар теленең актив лексикасына карамаса да, кулланылыштан гомумән төшеп калмый, ә дингә нисбәтле сакланып кала. Мисал өчен, хәзерге татар телендә хәдис сүзе дини лексикада гына сакланып калган һәм Мөхәммәд пәйгамбәр сөйләгән сүзләр мәгънәсендә кулланыла [2: 637]. Гарәп телендә хәдис сүзе мондый мәгънәләрне белдерә: 1) әңгәмә; 2) интервью; 3) хикәя, риваять; 4) хәдис.

Асылда гарәп алынмалары мәгънә ягыннан татар телендә тарайса да, телебездә аларның яңа семантик төсмер алуы да шактый еш күзәтелә. Моны түбәндәге лексемалар мисалында расларга була. Гарәп телендә عَمِلَ (“гамилә”) фигыле беренче бабта тугыз мәгънәне белдерә: 1) (эш) эшләргә, хезмәт итәргә; 2) эшләргә; 3) эш итәргә;

4) идарә итәргә, җитәкче булырга; 5) эшләнергә, (кемдер) булып китәргә; 6) түләргә, акча түләргә; 7) (нәрсәдер өстендә) эшләргә; 8) грам. башкару; 9) интрига, хәйлә корырга. Бу фигыль 1-8 һәм 10 бапта кулланыла, аннан ясалган масдарлар да шактый. Тамырның татар телендә куллануын күзәтик. Гамәл – 1) эш, хәрәкәт; хәл. 2) мат. Математик хисаплауның төп ысулы, төре. 3) дини Намаз, шәригать буенча мәҗбүри үтәлергә тиеш булган эш; 4) Чара, мөмкинлек, ысул, әмәл [2: 122]. Татар телендә бу тамырдан фонетик ысул белән әмәл сүзе ясалган. Сүзлектә аның мондый мәгънәләре теркәлгән: әмәл – 1) нинди дә булса берәр эшне, бурычны үтәү, башкару өчен кирәкле эшчәнлек, хәрәкәт, чара. 2) Үзлегеңнән генә күрелгән дәвалау чарасы [2: 748]. Шул рәвешле, "гамәлә" тамырыннан тулаем яңа мәгънә төсмерләренә ия булган тамыр һәм аңа тамырдаш сүзләр барлыкка килгәнлеген күрәбез: әмәлле – елгыр, чос, һәрчак җаен-юлын таба торган. Әмәллек – (диал) дәвалау чарасы. Әмәлче – 1) хәйләкәр, төрле кыек эшләргә оста кеше; 2) бик гади имче, им-том итүче [2: 748]. Мәгънә киңәюе телебездә алынмадан фонетик ысул белән яңа сүз ясалган очракларда еш күзәтелә. Моңа хикәя(т) – әкият, хәзер – әзер, хаҗәт – әҗәт кебек мисалларда да ачык күрәбез.

Алынма сүзләрнең чыганак һәм алынмалар кергән телдә мәгънәләре тулаем үзгәрү очраклары еш күзәтелми. Татар телендә дә гарәп алынмаларының мәгънәсе нигездә саклана, әмма үзгәрү, тәңгәл килмәүгә мисаллар китерергә мөмкин. Гарәп телендә عار ("гарь") исеме, татар телендәге кебек үк, оят, хурлыкны белдерә [2: 123]. Татар телендә бу сүздән ясалган әр сүзенең мәгънә үзгәреше кызык. Әр сүзе тиргәү, тиргәш, орышу мәгънәләрен белдерә башлаган [2: 748]. Әлеге исемнән шушы ук мәгънә төсмерләрен белдергән *әрләү, әрләш, әрләшү* сүзләре ясалган.

Күп кенә гарәп тамырлары татар телендә бер яки чыганак тел белән чагыштырганда таррак мәгънәдә кулланыла. Гарәп алынмаларының телебездә яңа семантик төсмер алуы шулай ук шактый еш күзәтелә.

**ӘДӘБИЯТ**

1. Баранов Х. К. Арабско-русский словарь. М.: Издатель Валерий Костин, 2007 г. 944 с.

2. Татар теленең аңлатмалы сүзлеге. Казан: Матбугат йорты, 2005. 848 б.

3. Хәмзин К.З. Гарәпчә-татарча-русча алынмалар сүзлеге (Татар әдәбиятында кулланылган гарәп һәм фарсы сүзләре) / К.З. Хәмзин, М.И. Мәхмүтов, Г.Ш. Сәйфуллин. Казан: Иман, 1993. 856 б.

# ТАТАР ТЕЛЕНДӘ АЛМАШЛЫК СҮЗ ТӨРКЕМЕН УЕН ТЕХНОЛОГИЯСЕНӘ НИГЕЗЛӘП ӨЙРӘТҮ

*Шәехова А., КФУ, II курс магистранты*
*Фән. җит. – филол. фән. канд, доц. М.М. Шәкүрова*

Татар телен чит тел буларак өйрәтү процессында уеннардан файдалану укучыны белем алырга, укуга дәртләндерә, анда фән белән кызыксыну уята. Бала уйнамый тора алмый. Уен – белем алу да, тормышка өйрәнү чарасы да. Гомумән, уен барышында балаларда ирекле ярыш рухы, иҗади тапкырлык, үткенлек, өлгерлек, җитезлек кебек бик кирәкле сыйфатлар тәрбияләнә.

Әдәп-тәртип кагыйдәләрен үтәү гадәте дә уенда камилләшә. Оста итеп оештырылган уен балаларда телгә карата зур кызыксыну уята. Уеннар баланы уйларга, эзләнергә этәрә, телне белүнең тормышта кирәклегенә төшендерә. Уен барышында балалар бердәмлеккә омтыла, үзара ярдәмләшеп, биремнәр үтәгәндә, аларда үз көчләренә ышаныч тәрбияләнә.

Бүгенге көндә без “традицион белем бирү”, “педагогик технология”, “белем бирү технологиясе”, “инновация” төшенчәләре белән еш очрашабыз. Татар теле дәресләрендә кулланган төрле уеннар да бүгенге көндә бик отышлы файдаланылган педагогик технология буларак карала. Педагогик технологияләрнең төрле классификацияләре бар. Ләкин безне нәкъ уен технологиясе кызыксындыра. Мәкаләдә татар теле дәресләрендә алмашлык сүз төркемен өйрәткәндә, уен технологиясен куллану ысулларына игътибар иттек.

Татар теле дәресләрендә уеннар алмашлык сүз төркеменә бәйле төшенчәләрне үзләштергәндә, теманы өйрәнгәндә, яңа материалны аңлатканда һәм ныгытканда, сөйләм эшчәнлегенең телдән төрләренә өйрәткәндә кулланыла ала. Татар теле грамматикасына бәйле рәвештә, уеннарны без түбәндәге төркемнәргә бүлдек: фонетик уеннар; лексик уеннар; сүз ясалышы һәм морфемикага бәйле уеннар; морфологик уеннар; синтаксик уеннар һ.б.

Башлангыч сыйныфларда укучылар күбрәк зат алмашлыклары (мин, син, ул, без, сез, алар) белән эшлиләр. Ә урта сыйныфларда без инде алмашлыкның төркемчәләре белән якыннанрак таныша башлыйбыз. Татар теле дәресләрендә алмашлык сүз төркемен өйрәтүгә бәйле кайбер кызыклы һәм мавыктыргыч уеннарны карап үтик.

Дәресләрдә иң яратып кулланган һәм шулай ук укучыларның күңеленә яткан уеннарның берсе – татарча мультфильмнан ишеткән алмашлыкларны язып алу. Бу уен укучыларның игътибар булуын таләп итә. Мәсәлән, “Алтын бөртекләр” исемле мультфильмнан 6 нчы сыйныф укучылары түбәндәге алмашлыкларны ишетеп язып алдылар: аларның, үзе, үз, мин, сезне, үзегез, без, үзебез, син, безгә, ул, аны, әнә, алар, менә, шул, болай, миңа, шулар, аларны, үзләрен һ.б. Аннан соң без һәр алмашлыкның төркемчәсен әйтеп, аның җөмләдә кайсы кисәк булып килүен билгелибез.

Татар теленә өйрәткәндә, бигрәк тә рус телендә сөйләшүче балаларны, рольле уеннар аеруча актив кулланыла. Бу уеннарның өйрәтү мөмкинлекләре зур, һәм тәкъдим ителгән ситуацияләрдә укучылар алар белән иркен эш итәләр. Шуның белән беррәттән, укучыларның дәрес белән кызыксынулары арта, тел һәм сөйләм материалын өйрәнү дә нәтиҗәлерәк була. Рольле уенны парлап һәм төркемнәрдә дә оештырырга мөмкин. Дәрестә укытучы һәм укучы булып уйнарга мөмкин. Ләкин укытучы ролендә гади укучы була. Мәсәлән, алмашлык темасын кабатлаганда, укытучы сораулар бирә, ә укучы мисаллар белән җавап бирергә тиеш була. Шулай ук диалогларны сәхнәләштергәндә, исем урынына алмашлыкларны кулланырга мөмкин.

Дәрес-шоу уенын алмашлык сүз төркемен тулысынча үткәч, кабатлау рәвешендә үткәрергә мөмкин. Дәресне уздыру өчен, сыйныф берничә төркемгә бүленә, һәм һәр төркем үзенең җитәкчесен сайлый. Төркемнең җитәкчесе укытучы биргән тема буенча әңгәмә оештырырга һәм аны сыйныфка тәкъдим итәргә тиеш. Алмашлыкка бәйле түбәндәге темаларны аерып чыгарырга мөмкин: зат алмашлыклары, күрсәтү алмашлыклары, сорау алмашлыклары, билгеләү алмашлыклары, билгесезлек алмашлыклары һ.б. яки исем алмашлыклары, сыйфат алмашлыклары, рәвеш алмашлыклары, сан алмашлыклары һ.б. Әңгәмәгә башка төркем укучылары да кушыла. Шул тәртиптә барлык төркемнәр дә үзләренең темалары буенча чыгышлар ясый.

“Нәрсә? Кайда? Кайчан?” дәрес-уены телетапшыру үрнәгендә алып барыла. Аны алмашлык темасы буенча алган белем һәм күнекмәләрне тикшерү максатыннан оештырырга була. Мәсәлән, теманы өйрәнеп бетергәч, чирек, уку елы ахырында һ.б.

Нәтиҗә ясап әйткәндә, уен – сөйләм телен, туган телне өйрәтү, камилләштерүнең иң үтемле һәм нәтиҗәле чарасы. Бигрәк тә сүзле уеннар туган телендә иркен сөйләшә алмаган татар балаларын ана теленә өйрәтүдә яхшы нәтиҗә бирә.

**ЛИТЕРАТУРА**


1. Закирова К.В. Уйный-уйный үсәбез. Казан : Мәгариф, 2005. 68 б.
2. Низамов Р.А. Педагогик уйланулар. Казан : Мәгариф, 1994. 324 б.
3. Харисов Ф.Ф. Татар телен чит тел буларак өйрәтүнең фәнни-методик нигезләре. Казан: Татар. кит. нәшр., 2015. 302 б.
4. https://infourok.ru/obobschenie-pedagogicheskogo-opita-igrovie-tehnologii-na-urokah-tatarskogo-yazika-kak-odno-iz-sredstv-realizacii-sistemnodeyatel-714536.html


## ТАТАР ТЕЛЕНДӘ ФРАЗЕОЛОГИЗМНАР ҺӘМ АЛАРНЫҢ РУС ТЕЛЕНӘ ТӘРҖЕМӘСЕ


*Шакирҗанова А., Кукмара, 3 нче мәктәп, XI сыйныф*

*Җит. – Н.Н. Шакирҗанова*


Рус теленнән татар теленә тәрҗемә итү безнең ерак бабаларыбыз тарихына ук барып тоташа. Кайбер галимнәр фразеологик берәмлекләрне тәрҗемә итеп булмый дигән фикерләр җиткергәннәр. Ләкин тәрҗемә әсәрләрен уку барышында фразеологизмнар белән еш очрашабыз һәм аларның тәрҗемәләре белән танышабыз. Татар әдәбияты әсәрләренең рус теленә тәрҗемә ителүе нәтиҗәсендә күп кенә берәмлекләр рус теленә дә калькалаштырылды. Татар теленә өйрәтү рус теле белән чагыштырып алып барыла. Дәресләрдә без шулай ук “Фразеологизмнар” темасы белән танышабыз.

Дәресләрдә без татар теленең фразеологик байлыгы белән танышабыз, сөйләм телендә, гамәлдә кулланырга, башка тел күренешләреннән аера белергә өйрәнәбез.

Рус теле белән чагыштырып өйрәнгәндә безгә фразеологизмнарның мәгънәсен аңларга күпкә җиңелрәк. Әдәби әсәрләр укыганда да, фразеологизмнарның мәгънәсен аңлау, безгә авторның телен аңларга, әсәрне анализлауга җиңеллек тудыра.

Телдәге сүзтезмәләр бер сүз белән генә түгел, ә үзгәртелми, таркалмый торган тотрыклы сүзтезмәләр белән дә белдереләр: авыз еру – көлү, авызына су кабу – дәшмәү. Телдәге мондый сүзтезмәләрне фразеологизмнар (грек.phrasis — тәгъбир, сөйләм әйләнмәсе, logos-өйрәнү) дип атыйлар.

Фразеологизмнарны ирекле сүзтезмәләр бедән бутарга ярамый. Фразеологик сүзтезмәләр кимендә ике сүздән торалар,

телдә үзгәрешсез яшиләр, сөйләмгә әзер килеш керәләр; алар составындагы сүзләр арасына башка сүзләрне өстәп куярга мөмкин түгел. Фразеологизмнар бер сүз белән алыштырып була: куян йөрәк – куркак, кот очу – курку.

Фразеологик ныгымаларда компонентларының аеруча нык бердәмлеге күзәтелә. Сүзләрнең мөстәкыйль мәгънәләре тулысынча югалган булса, бөтеннең мәгънәсе аерым кисәкләрнең мәгънәсеннән килеп чыкмый: чәчләр үрә тору – жгучий страх; ут белән су арасында – между двух огней.

Фразеологик бердәмлекләрдә компонентлар арасындагы бәйләнешләр йомшара төшә. Монда да сүзләрнең мәгънәләре мөстәкыйль түгел, бөтеннең мәгънәсен алар бергә бирәләр: ике куян койрыгын бергә тоту – гнаться за двумя зайцами; телеңне тыю – держать язык за зубами.

Фразеологик тезмәләрдә компонентлар арасында бәйләнеш тагын да йомшаграк, алар ирекле сүзтезмәләргә якын торалар. Бер сүз – туры, икенчесе күчерелмә мәгънәдә килә. Шуңа күрә бөтеннеә мәгънәсе өлешләрнең мәгънәләренә шактый бәйләнгән була. Мәсәлән: борын күтәрү – задирать нос, күз ташлау-бросить взгляд.

Фразеологизм составында икедән алып җиде сүзгә хәтле компонент булырга мөмкин. Мәсәлән: зыян салу – наносить вред; арадан кара мәче үтү – пробежала черная кошка; телең булмаса карга күтәреп китәр иде – что бы ты делал без своего языка һ.б.

Фазеологизмның бер телдән икенче телгә үтеп керүе берьяклы гына процесс түгел: ул рус теленнән татар теленә кергән кебек, татар теленнән рус теленә дә күчә, калькалаша. В. Виноградов тәрҗемә итүнең өч юлын күрсәтә.

1. Фразеологик эквивалент – икенче телдә шундый ук фразеологик әйтелмәне табу. Смотреть через пальцы- бармак аша карау, ставить вопрос ребром – сорауны кабыргасы белән кую, ставить точку – нокта кую.

2. Тулы булмаган фразеологик эквивалент – һәрбер мәгънәдә дә тулы булмаган фразеологизм белән тәрҗемә итү. Ягъни телдә икенче мәгънәсе булу шарт булып тора, ләкин бу телдә сирәк күренеш. Не входить в рамку – тәртәгә сыймау, как без рук- ике кулсыз калу.

3. Бер сүздән торган өлешчә эквивалент. (однословные частичные эквиваленты)

Тәрҗемә әсәрләрдә фразеологик эквивалентлар түбәндәгечә чагылыш таба: набрать в рот воды – авызга су кабу. Чего ж воды в рот набрали, досадуя спросил Иван Алексеевич. (М. Шолохов. “Тихий Дон”). – Ник авызыгызга су каптыгыз? – дип, ачуы килебрәк сорады Иван Алексеевич (М.Шолохов “Тын Дон”).

Бу күренеш, гадәттә, әсәрләрне бер телдән икенче телгә тәрҗемә иткәндә күзәтелә.

Фразеологик берәмлекләр язучыга геройның портретын тасвирлауда, эчке дөньясын ачуда, вакыйга – күренешләрне чагылдыруда ярдәм итә, әсәр теленең халыкчанлыгын, гадилеген, аһәңле яңгырашын тәэмин итә.

Мин Г.Бәшировның “Туган ягым – яшел бишек” әсәреннән өзекләргә тукталып үтәргә телим.

“Озак та үтми, мин башым-аягым белән татлы йокыга чумам.” Баш-аяк белән йокыга чуму фразеологизмы аша автор нык һәм тиз йоклап китү турында әйтә. Г. Бәширов шулай ук түбәндәге фразеологизмнарны куллана: күңелгә хуш килү, башын ташка орырдай, очын-очка ялгап, каш сикертү,китап җене кагылу.

Шулай ук, без укыган Ш. Рәкыйповның “Чәчәкләр сөйли белә” әсәреннән өзекләрдә фразеологизмнарны очратырга мөмкин: “Үземнең дә *колакка чалынганы* бар” һ.б.

Чыгышымны йомгаклап шуны әйтәсем килә: сөйләмебездәге һәр сүз, телнең һәр берәмлеге, шул исәптән фразеологизмнар да, энҗе бөртегенә бәрабәр. Туган телен кадерләп саклау һәр кешенең изге бурычы.

**ӘДӘБИЯТ**

1. Әхәтов Г.Х. Татар теленең фразеологик әйтелмәләр сүзлеге. Казан: Таткитнәшр.,1982. 174 б.

2. Байрамова Л.К. Учебный тематический русско-татарский фразеологический словарь. Казань. Тат. книж. изд-во, 1991. 158 с.

3. Бәширов Г. Сайланма әсәрләр. Казан: Хәтер, 2006. 511 б.

4. Хәбибуллина З.Н., Фәрдиева Х.Г., Хуҗиәхмәтов Ә.Н. Татар әдәбияты 8. Казан: Татар. кит. нәшр., 2011. 208 б.

## СӨЙЛӘМЕБЕЗ ТӨЗЕКМЕ?

*Шакирова А., Казан, 180 нче гимназия, X сыйныф*

*Җит. – филол. фән. канд. Х.Х. Сөләйманова*

Дөрес сөйләм күнекмәләренә ия булу, ягъни татар әдәби теленең нормаларын кулланып эш итә белү культуралылыкның аерылгысыз бер өлеше булып тора. Әйтергә теләгән фикерне

тыңлаучыга тулы, төгәл һәм ачык итеп җиткерү өчен тел чараларын дөрес һәм матур итеп куллана белү бик әһәмиятле.

Бүгенге көн таләпләре белән мөнәсәбәтле рәвештә без бу эшебездә әдәби сөйләмгә куела торган таләпләрне билгеләргә, һәм аларны бүгенге көн таләпләре белән чагыштырырга, тиешле нәтиҗәләрне чыгарырга тырыштык. Куелган максаттан чыгып, түбәндәге бурычларны билгеләдек: татар әдәби теле турында кыскача мәгълүмат бирү; әдәби тел практикасында бүгенге көндәге әһәмиятле мәсьәләләрен тикшерү; татар теленең бүгенге яшәешендәге әдәби тел нормаларының торышын күзәтү.

Тел культурасы дигән төшенчә әдәби тел нормаларын яхшырту, камилләштерү чараларын һәм шул юлдагы эшләрне үз эченә ала. Тел культурасына ия булу исә әдәби телнең нормаларын тулысынча өйрәнеп үзләштерүдән гыйбарәт.

Татар теле культурасының нигезләре уку-укыту эшләре ана телендә куелган мәктәпләрдә һәм балалар бакчаларында салына. Сүз осталары тарафыннан татар әдәби телендә иҗат ителгән матур әдәбият әсәрләрен, публицистик һәм фәнни әдәбиятны игътибар белән аңлап уку мөһим. Татар әдәби теле осталарының телдән чыгышларын, шулай ук, игътибар белән тыңлау зарур. Тел культурасы турында язылып, басылып чыккан матбугат әсәрләреннән, махсус кулланма һәм белешмәләрдән файдалану да бик отышлы. Тел культурасын күтәрү, үстерү буенча һәрбер кешенең үз иҗади активлыгы була. Кешенең тел культурасы өлкәсендәге үз иҗади активлыгы төрле юллар белән гамәлгә ашырылырга мөмкин. Әйтергә кирәк, һәрбер татар милләтеннән булган кешегә үзенең тел культурасын камилләштерү өстендә эшләргә чиксез мөмкинлекләр бар. Бары үз теленә җитди карарга, телеңне яратырга, үз сөйләмеңә игътибарлы булырга гына кирәк.

Әдәби тел нормаларының тел кулланылышында саклануы мәҗбүри. Аларның саклануы өчен әдәби телебезнең язма һәм сөйләү төрләрендә, шул ике төрнең барлык стильләрендә түбәндәге таләпләр үтәлергә тиеш: төгәллек, ачыклык, сафлык, җыйнаклык һәм аһәңлелек.

1. Төгәллек. Бу таләп татар әдәби телендәге сөйләмнең билгеле тарихи чорда урнашкан әдәби нормаларга туры килүен, сөйләмдә ялгышлык булмавын күздә тота. Билгеле төшенчәне, эчтәлекне тәгъбир иткәндә анда лексик, фонетик-орфоэпик, грамматик, стилистик һәм орфографик яклардан хата булмаска

тиеш. Беренче чиратта ияручe сүз белән ияртүче сүзнең бер-берсенә бәйләнешен һәрвакыт истә тоту таләп ителә. Әлеге кагыйдә бүгенге көн татар әдәби теле сөйләмендә ничек чагылыш таба икән, мисалларга игътибар итик: 1) Мәгариф үзәгендә 2013 елдан бирле эшләп килгән Ч.Айтматов тормышы һәм иҗатына багышланган “И дольше века длится день...” (“Гасырдан да озын көн...”) дип исемләнгән музейда язучының костюмнары, көндәлек кирәк-ярак әйберләре, китаплары саклана. Мәгариф үзәгендә 2013 елдан бирле эшләп килгән дигән сүзләрдән соң ук Ч.Айтматов сүзләре тора һәм ул *Мәгариф үзәгендә 2013 елдан бирле Ч.Айтматов эшләп килгән* дип аңлашыла. Ә чынлыкта Мәгариф үзәгендә 2013 елдан бирле эшләп килгән музей турында сүз бара. Шуңа күрә җөмләне, төгәл итеп, башкача төзергә кирәк. 2) Әйе, укытучы үз фәне өлкәсендәге барлык яңалыклардан хәбәрдар булганда һәм шул яңалыкларны дәресендә урынлы файдаланганда гына уңышка ирешеп була. Бу җөмләдәге *шул яңалыкларны* сүзләре урынына *аларны* алмашлыгын кулланырга кирәк. Мисаллардан күренгәнчә, бүгенге көндә дә әдәби сөйләмдә төгәллек таләбе тулысынча үтәлми.

2. Ачыклык яки җиңел аңлаешлылык. Үзе төбәлгән кешеләргә карата сөйләмнең җиңел, анык аңлаешлы булуы “ачыклык” дип атала. Сөйләмдә ачыклыкның булмавы яки җитешмәве, күбесенчә, анда аңлаешсыз яки авыр аңлаешлы сүзләр, чит сүзләр, ят формалар, тәгъбир һәм синтаксик төзелмәләр катнашудан килә. Мәсәлән, түбәндәге җөмләләрдә ачыклык җитешмәү күренеп тора: Укучылар гаилә кыйммәтләре турында өлгергән фикерләр (үз фикерләрен дөресрәк булыр иде) әйтәләр. ТР мәдәнияте көннәре кысаларында (барышында булырга тиеш югыйсә!) халык кәсепчелеге күргәзмәсе, “Бүгенге Татарстан” дигән фотокүргәзмә ачылды. Шунысы кызык: бүгенге көн әдәбиятыбызда, радио һәм телевидениедә кыса сүзе бик популярлашты. Кыса билгеле бер чик дигән төшенчәне күзаллый. Безнеңчә кыса сүзен синонимик рәт белән алмаштырсак, сөйләмебездә җиңел аңлаешлылык тулысынча хөкем сөрер иде.

3. Сафлык. Бу таләп әдәби сөйләмдә лексик, фонетик, грамматик, стилистик яктан кытыршылыклар, чуарлыклар урын алмаска тиешлекне, сөйләмнең андый күренешләрдән чиста, саф булуын күздә тота. Чөнки алар сөйләмнең тыңлаучыга һәм укучыга җиңел аңлаешлылыгын киметә. Кирәксезгә бүтән тел сүзләрен, борынгы диалекталь яки гади сөйләм сүзләрен, фонетик

күренешләрне һәм синтаксик әйләнмәләрне куллану әдәби сөйләмнең сафлыгын боза, шуның белән бергә аның әйтелү, укылу җиңеллеге дә кимергә мөмкин. Моңа мисаллар: Шәхси фикере, идеяләре булган, фантазияле, иҗади сәләтле, эшлекле укучылар әзерләү өчен укытучы үзе дә һәр өлкәдә компетентлы, интеллектуаль үсешкә, педагогик этикага, культурага ия булырга, корпоратив фикер йөртә белергә тиеш. Ә яңа ФГОС (ФДББС кирәк) ул – яңача фикерләү. Вузның (дөресе: югары уку йортларының) уку-укыту эшчәнлегендә нәрсә үзгәрде соң?

Күренә ки, кагыйдә белән исәпләшмәү таләптән читкә тайпылуга китерә. Әлеге хаталар кат-кат җентекләп укыганда күзгә ташланалар бит. Газета-журналларыбыз теле укучылар теленә дә "йогачак", хаталар әдәби телдән җирле сөйләм теленә күчерелә дигән сүз бит инде бу.

4. Җыйнаклык. Бу таләп әдәби сөйләмдә билгеле төшенчәне, уйны аңлату өчен кирәк булмаган, артык тел чаралары (сүз, термин, сүз формасы, синтаксик чаралар, урынсыз кабатлаулар һ.б.) булмаска тиешлекне күздә тота.

Түбәндәге җөмләләрдә җыйнаклыкка каршы килә торган күренешләр бар: *Гаиләдә өч буын яшәгәндә генә тулы бәхетле гаилә булырга мөмкин!* Дөресе: *Өч буын вәкиле яшәгәндә генә гаиләдә тулы бәхет булырга мөмкин!* Кабатлау җөмләне ямьсезләтә. Мөмкин кадәр әлеге кабатлаулардан чыгу юлын эзләргә кирәк. Белмим, әллә игътибар җитенкерәми, әллә безгә билгесез башка сәбәпләр бар, әмма матур әдәбият һәм публицистика стиле һич кенә бу хаталардан "котыла" алмый. Кабатлау җирле сөйләштә бик күп, моны без курыкмыйча әйтәбез, барны юк дип булмый. Шулай да хаталардан котылырга бик кирәк һәм тиешбез.

5. Аһәңлелек. Сөйләмнең һәм аның кисәкләренең әйтелеш, укылыш, ишетелү һәм аңлау ягыннан уңайлылыгы аһәңлелек дип атала. Бу таләп җиңел һәм аңлаешлы укуны тәэмин итәргә, шуның белән ул укылганны тыңлаучыга җиңел аңлау мөмкинлеген тудырырга тиеш. Телдән сөйләгәндә бу таләпнең әһәмияте тагы да зуррак. Чөнки аһәңсез сөйләм тыңлаучыны тиешенчә кызыксындырмый; сөйләмнең эчтәлеге әһәмиятле булса да, тыңлаучыны үзенә тиешенчә тарта алмый. Хаталы мисалны күздән кичерик: *Укытучылар җәмгыятьтә барган үзгәрешләрне авырыксынуларсыз кабул итеп, заман белән бергә атлыйлар*. Җөмлә структур яктан төзек. Әмма аһәңлелек җитенкерәми. Безнең

таләпнең төп шарты: җөмлә тыңлаучы тарафыннан тулы һәм аңлаешлы кабул ителсен өчен, ул аһәңле һәм төзек булырга тиеш. Әлеге җөмләдә күп иҗекле сүз урынсыз кулланылган. Шулай булгач, җөмләне түбәндәгечә үзгәртсәк, ул укучылар тарафыннан тулы һәм дөрес мәгънәдә кабул ителер иде. Ягъни: *Укытучылар җәмгыятьтә барган үзгәрешләрне кабул итеп, заман белән бергә атлыйлар.* Гади һәм аңлаешлы яңгырый.

Югарыда, тикшерелеп үтелгән мисаллардан күренгәнчә, телнең әдәби нормага карата таләпләре гаять катлаулы һәм җаваплы. Әдәби телне үстерү, камилләштерү эше, беренче чиратта, һәрбер телнең үзендә булган, шунда яшәп килә торган чараларны шул телнең эчке закончалыклары нигезендә иҗади файдалану юлы белән барырга тиеш. Һәрбер әдәби тел үзенең яшәештәге халәтенә туры килә торган үзгәрешләр, яңалыклар кертү һәм чит тел элементлары алу юлы белән дә үзен тулыландыра, үстерә.

**ӘДӘБИЯТ**

1. Абдуллина Р.С. Риторика һәм интонация. Яр Чаллы, 1999. 396 б.

2. Абдуллина Р.С. Стилистика һәм сөйләм культурасы мәсьәләләре. Яр Чаллы, 1997. 128 б.

3. Хаков В.Х. Татар әдәби теле (Стилистика). Казан: Татар. кит. нәшр., 1999. 304 б.

4. Хаков В.Х. В. Хангилдин турында хатирәләр // Фән һәм тел. № 1. 2006.

5. Хангилдин В.Н. Татар теле культурасының кайбер мәсьәләләре. Казан: Татар. кит. нәшр., 1976. 96 б.

6. Җамалетдинова Ф. “Мин әйттем”нән узасы иде // Ватаным Татарстан. 2006. 6 ноябрь. № 230. Б. 3.

## “ЛӘҺҖӘИ ТАТАРИ” ҺӘМ “ЛӘҺҖӘИ ОСМАНИ” ХЕЗМӘТЛӘРЕ

*Шенер С., КФУ, магистрант I курс*

*Фән. җит. – филол. фән. докт, проф. Ә.Ш. Юсупова*

К. Насыйри Һәм Әхмет Вәфик Паша – татар һәм төрек теле фәнне өчен мөһим кешеләр. Аларның икесе дә аңлатмалы сүзлек язганнар. Бу фәнни эшебез “Ләһҗәи татари” һәм “Ләһҗәи османи” турында кыскача мәгълүмат туплауга багышланган.

“Ләһҗәи татари”нең авторы мәгърифәтче, тарихчы, этнограф, тел белгече һәм әдип Каюм (Габделкаюм) Габденнасыйр улы Насыйри 1825 елның 14 февралендә туган. «Касыймия» мәдрәсәсендә белем алган. К. Насыйри татар халкы өчен күп әсәрләр язып калдырган. Шуларның берсе – “Ләһҗәи татари”. К. Насыйри “Ләһҗәи татари” исемендәге сүзлекне 1895 елда язган. Бу сүзлек татар теленең беренче аңлатмалы сүзлеге булып тора. Бу

сүзлеккә кадәр бер төрки телдә дә аңлатмалы сүзлек басылганы булмаган. Бу сүзлек ун меңгә якын сүзне, сүз тезмәләрен һәм тотрыклы гыйбарәләрне үз эченә ала. Каюм Насыйри тел турында фикерләрен дә сүзлектә аңлаткан. Сүзлектә һәр сүз өчен мисаллар бирелгән. Кайберләре өчен табышмаклар, мәкальләр дә тәкъдим ителгән. Кайбер сүзләрнең фарсы һәм гарәп телендәге тәрҗемәсе дә бирелгән. Моннан тыш, сүзләрнең диалектлар арасындагы бәйләнеше ачыкланган. Моннан аңлашыла: К. Насыйри төрек диалектларының тел системасы турында фикер йөртә алган.

“Ләһҗәи османи”нең авторы Әхмет Вәфик Паша Госманлы империясендә беренче тюрколог булган. Ул дәүләт эшлеклесе, дипломат, тәрҗемәче һәм драматург хезмәтләрен дә башкарган. Әхмет Вәфик Паша да Каюм Насыйри кебек үк күп әсәрләр язып калдырган. Төрек теленең беренче аңлатмалы сүзлеге (Lehçe-i Osmani) булган “Ләһҗәи османи”не язган. Сүзлекнең беренче басмасы – 1876 елда, икенче басмасы 1890 елда дөнья күргән. Беренче басмада төрекчә, гарәпчә, фарсыча сүзләр тупланган. Икенче басмада төрекчә сүзләр һәм гарәп, фарсы алынмалары да бар. Бу яңалыклар Осман төрекчәсе сүзләрен көнчыгышта кулланылышта булган һәм иске формасында күрсәткән. Автор төрекчә сүзләрнең тамырлары һәм алардан ясалган сүзләрне күрсәтеп, халык әйтемнәрен дә алар белән бергә биргән. Бу әсәр төрек тарихи, диалектлары, географиясе турында мәгълүмат алуда мөһим урын алып тора.

Нәтиҗә ясап әйткәндә, Каюм Насыйри Һәм Әхмет Вәфик Паша үз теллерендә беренче аңлатмалы сүзлекләре язганнар. Ягъни, “Ләһҗәи татари” Һәм “Ләһҗәи османи” тюркологиядә мөһим әсәрләрдер.

Ике галим дә сүзлекләрендә мисаллар, табышмаклар, мәкальләр биреп барган. Кайбер сүзләр өчен әлеге сүзләрнең фарсы һәм гарәп теллерендәге тәрҗемәсе бирелгән. Сүзләр һәм диалектлар арасындагы бәйләнеше дә ачыкланган. Ике хезмәт тә Каюм Насыйри Һәм Әхмет Вәфик Пашаның төрки телләр системасын яхшы белүләрен күрсәтә.

**ӘДӘБИЯТ**

1. Çağatay S. Abd-ül-Kayyum Nasırî. Ankara: A.Ü. Dil ve Tarih Coğrafya Fakültesi Dergisi, 1952. 147 c.

2. Abdü’n-nasır oğlu, Abdü’l Kayyum.Lehçe-i Tatarî, cild-i evvel. Kazan, 1895, 226 c.; cild-isâni. Kazan, 1896, 106 c.

3. Әхмет Вәфик Паша http://www.islamansiklopedisi.info/dia/pdf/c02/c020138.pdf

ОСОБЕННОСТИ КРЕОЛИЗОВАННЫХ РЕКЛАМНЫХ ТЕКСТОВ
(на примере татарских интернет СМИ)

*Шигапова Г., КФУ, студент II курса*
*Науч. рук. – канд. филол. наук, доц. Г.Р. Мугтасимова*

Креолизованный текст – это текст, который содержит в себе вербальные знаки и невербальные (чаще всего изображения). Креолизованные тексты могут быть текстами с частичной креолизацией и текстами с полной креолизацией.

Интернет-реклама обладает рядом преимуществ: более низкая стоимость, широчайший охват целевой аудитории. Важным свойством интернет-рекламы является связь с аудиторией, более выраженная, чем у традиционных средств коммуникации. Традиционно потребитель о товаре, фирме, услуге или идее оповещается осуществляется через такие средства информации, как телевидение, радио, печатные издания, телефон. Ее отличительной чертой является интерактивность, то есть возможность немедленной реакции на обращение.

В данный работе мы обратили внимание татарские рекламные материалы в Интернете. В таких СМИ заголовки рекламы чаще всего даны на английском языке, например, «Yummy music», «JADIDfest» проекты, «Vegan Day» студиясе, «Divan» кофе-коворкингы, «Good goods» – агачтан, полимер кызылбалчыктан, зәркан сумаладан дизайн аксессуарлар булдыручы казан маркасы, “ABAU» бренды и др. Как видно из примеров, они переведены методом транслитерации. Кроме того есть и такие примеры: «Казань глазами инженера» проекты, «Солнце внутри» – мөмкинлекләре чикләнгән кешеләрне берләштерүче мәйдан, такси «Татары рулят» – беренче татарча такси, «Саида» балачактан килми китәсе. Из этих примеров видно, что и на татарских рекламных текстах используются оригинальные названия татарских брендов. А вот еще один пример, где название конкурса приводится на двух языках: «Созвездие-Йолдызлык». Это можно обьяснить тем, что конкурс проводится на двух государственных языках.

Мы выявили, что большинство татарских реклам имеют только частичную креолизацию. В них изображения играют только роль фона. Например, в рекламе клуба «Тарихи бранч» фоном дается старая фотография, изображающая революционные действия. Это, в какой-то степени, привлекает внимание и создает особенную атмосферу. Такие же примеры можно привести из рекламы «Акыл

фабрикасы», «Татарча диктант», «ABAU» и медиа-лаборатории «ТАВЫШ». Интересным примером данного типа рекламных тектов является реклама-приглашение на кастинг клуба «Сәләт». Но в рекламных текстах именно изображение играет важную роль. И в этих примерах изображение должно присутствовать для большей красочности.

В последнее время в интернет пространстве все чаще встречаются объявления с использованием хештегов других графических средств прямо в названии. Например, реклама радиопрограммы "#казанкайный", "@MinemYaratkanTatarTelem".

Есть интересные примеры частичных креолизованных текстов, где один предмет выступает вместо буквы в слове. Например, в названии татарской сети быстрого питания «Түбәтәй», вместо *й* стоит буква *и* с татарским орнаментом вместо черточки. В «Күңел радиосы» вместо буквы *ү* – растение с бабочкой. А слова «Болгар радиосы музыкаль премиясе» окрашены в золотистый оттенок как сам приз – золотая звезда. В рекламе детского садика «Ябалак» буква *б* изображается как ветка для совы. Такие же примеры можно привести и в рекламных текстах компании «Байлар», «Хәлбуки», интеллектуальная игра «Ябалак», детский сад «Ябалак», центр «Әкият» и др. Нужно подчеркнуть, что в этих названиях изображения используется и как обьяснение названия.

Интересны примеры с текстами с полной креолизацией. В рекламе хореографического спектакля «Әлиф» первая буква арабского алфавита әлиф «I» представлена фигурой исполнителя. Надпись «Татарча casual» заманча милли кием» изображена прямо на платье. Реклама творческой студии Алии Фаздаловой «Ostabikә» выполнена тоже оригинально. Вместо буквы *i* использовано изображение ниток, а вместо *O* изображена пуговица. Также в надписи ярко выделяется графический знак *ә*. Логотип группы «Зәринә һәм Cheek La Week» вбирает в себя несколько особенностей. Это креолизованный шрифт, транслитерация и использование фоном рисунка грецких орехов.

К таким примерам относится и реклама разных групп в социальной сети Вконтакте: «Татарчәйт», «Печән базары» на фоне новостной передачи на Первом канале.

Интертекстуальность в креолизованных татарских рекламных текстах тоже имеет место быть. Интернет-реклама «Татарча мафия» изображена на фоне главного мафиози Святой

отец. Реклама интернет группы «Җиһан» выполнен в стиле супергероев. Только вместо супермена представлен поэт Г. Тукай.

Таким образом, креолизаванные рекламные тексты на татарском языке в Интернете представлены, прежде всего, с помощью транслитерации. Мы выявили, что в таких текстах, в основном, используется частичная креолизация. Особый интерес вызывают тексты с полной креолизацией. Как мы выявили, татарские интернет тексты не сторонятся интертекстуальности и использования разнообразных графических средств.

**ЛИТЕРАТУРА**

1. Анисимова Е.Е. Лингвистика текста и межкультурная коммуникация (на материале креолизованных текстов): М.: Академия, 2003. 128 с.

2. Ворошилова М.В. Креолизованный текст: аспекты изучения. Вып. 20. Екатеринбург: Урал. гос. пед. ун-т, 2006. С. 180-189.

3. Гарифуллин В.З. Развитие Интернета на татарском языке // СМИ в публичной сфере. М.: Изд-во Моск. ун-та, 2011. С. 251-252.

4. Низамов И. Татар рекламы: кичә һәм бүген // Казан утлары. 1995. № 6. Б. 170-175.

## COMPARATIVE ANALYSIS OF PHRASEOLOGICAL UNITS EXPRESSING FEELINGS AND EMOTIONS

*Sabirova R., Yarullina A., KFU, 4th year student*

*Supervisor – an assistant prof. Yashina M.E.*

At all times the language is the most distinctive feature of the ethnos. It is interesting to see whether there is a national expression, unlike the mentality and what it is expressed with the language designation of feelings and emotions that are a real part of our lives and has a significant impact on human behavior. This research focuses on the comparative study of phraseological units expressing feelings and emotions on a material of English, Russian and Tatar languages. The present work is an analysis of semantic features, internal form and meaning of phraseological units. A comparison of the different languages of phraseology helps to clarify the emotional evaluation of events, taking into account the specifics of mentality of native speakers. Without knowledge of the idiom is impossible to understand the true meaning of any idiomatic expression.

In our research we adhere to a broad understanding of phraseology, the object of which are all stable combinations of words with a complicated value with the signs of stability and reproducibility.

There are groups of the phraseological units denoting human condition:

1) indicating the physical condition of the person: illness, fatigue, hunger, cold, and other.

For example, there is an idiom that expresses extreme irritation: *Russian «get out of themselves», English «to fly off the handle» (сорваться с ручки), Tatar «чыгырдан чыгу» (выйти из кожи).*

2) denoting psycho and physical condition of human: joy, sadness, love etc. For example, there is an idiom denoting extreme joy and happiness: *Russian phrase «быть на седьмом небе от счастья»,it is translated into English like «to tread on air» (ходить по воздуху), and Tatar «күңел мәтәлчек атты» (душа кувыркнулась).*

**Analysis of phraseological units from semantic and structural points.**

Six idioms were taken for the analysis from semantic and structural points. Their idiomatic equivalents were found in each of the three languages.

It should be noted that semantics of the phraseological units in all of the given languages is similar.

The first unit of idioms includes partial phraseologisms. They all have figures of «heart» and «weight», but they are different in structure.

| | | |
|---|---|---|
| ***Камень на сердце.***<br>*Noun + prep. + noun* | ***A heavy heart.***<br>*Adj. + noun* | ***Йөрәкне таш басып тора.***<br>*Noun + noun + adverb + verb* |

As we see, the Tatar equivalent has the most compound structure among others. The second unit shows idioms with similar images, that are conveyed through different lexical units (to be between flames/ the devil and the deep blue sea/ vise). The phraseologisms are very close in structure.

| | | |
|---|---|---|
| ***Быть меж двух огней.***<br>*Linking verb + prep. + numeral + noun* | ***To be between the devil and the deep blue sea.***<br>*Linking verb + prep + noun with article + conj. + adj.+ adj. noun* | ***Ике ут арасында булу.***<br>*Numeral + noun + adverb + linking verb* |

The idioms of the third unit have almost the same structure, but include different vocabulary. They are partial equivalents.

| | | |
|---|---|---|
| ***Как гвоздь проглотил.***<br>*Noun + verb* | ***As stiff as poker.***<br>*Noun+ noun* | ***Кымыч йоткан кебек.***<br>*Auxiliary verb + pronoun + verb + post-position* |

The phraseological units of the forth unit of the table are absolute equivalents. Needles are included in all of them. As for the structural point, the idioms do not differ much ( there are verbs added to English and Tatar variants).

| | | |
|---|---|---|
| ***Как на иголках.***<br>*Prep.+ noun* | ***To be on pins and needles.***<br>*Verb + prep. + conj. + noun* | ***Энәгә баскан кебек.***<br>*Noun + verb* |

According to the structure, phraseological units of the fifth unit are slightly different. It is interesting to compare them from the lexical point, as they convey the same meaning through different images: ( a mountain/ a load / a stone) , (shoulders/ mind/ heart).It can be explained by the fact that Russian, English and Tatar people have different association with a feeling of relief.

| | | |
|---|---|---|
| ***Как гора с плеч свалилась.***<br>*Noun+ prep. + verb* | ***A load off one's mind.***<br>*Noun+ prep.+ noun* | ***Иңсәдән тау төште.***<br>*Noun + noun+ verb* |

Idioms of the sixth unit are complete equivalents. It is traced near. Translation of idiom word to word will lead to its real equivalent. They are similar not only lexically but also structurally.

| | | |
|---|---|---|
| ***Витать в облаках.***<br>*Verb + prep. + noun* | ***To be up in the clouds.***<br>*Verb + prep. + noun* | ***Хыял диңгезендә йөзү.***<br>*Noun + noun + verb* |

Thus, the comparative analysis reveals the specifics of reflection in phraseological part of the English, Russian and Tatar languages. As it was said above, there are only few of absolute phraseological units. It happens because languages have different roots, moreover, nations have diverse understanding of some emotions and feelings. That is why syntactic and lexic contrasts occur, though common lexic meaning is remained.

## ЭЧТӘЛЕК

**Аргунова К.** Фоносемантика глаголов образа движения в якутском языке в сравнении с киргизским языком.......................... 3
**Аманатова А.** Тюркские мотивы в современной поэзии: якутская и тувинская литературы (сравнительно-сопоставительный анализ)................................................................................... 5
**Андылырова В.** Образные глаголы в описании якутской женщины.............................................................................................. 10
**Айзатуллова Г.** Шәхес тәрбияләүдә Р. Фәхреддин мирасын файдалану................................................................................. 13
**Әхмәдиева З., Гыйниятуллина А.** М. Җәлил шигырьләрендә «кызыл» сүзенең кулланылышы.............................................................. 15
**Әхмәтҗанов Р.** Н. Гыйматдинова иҗатында хатын-кыз образы 18
**Бабюк В.** Теоретические аспекты интерактивного isiZulu Oxford Living Dictionary.................................................................................. 20
**Байжарық Р.** Телебағдарлама атаулары – ұлт дүниетанымының көрсеткіші................................................................................... 23
**Башарова И.** Укучыларның сөйләм эшчәнлеген активлаштыру чарасы буларак фразеологизмнар..................................................... 27
**Божедонова А.** «Рыжая» масть лошади в якутском языке в сопоставительном аспекте с тюркскими языками.......................... 29
**Бурцева А.** Способы перевода описаний персонажей героического эпоса-олонхо «Ньургун боотур стремительный» с якутского на русский язык ......................................................................................... 31
**Валиева Ч.** Первый опыт Н.И. Ильминского в использовании кириллической графики для системы татарского языка................... 32
**Вилданова И.** Урта мәктәптә татар халык авыз иҗатын өйрәнү үзенчәлекләре: әкиятләр................................................................. 33
**Владимирова Л.** Опыт ассоциативных экспериментов в чувашском языкознании................................................................... 38
**Габизов И.** Татар телендә кош атамалары кергән фразеологизмнар......................................................................................... 40
**Гайнутдинова А.** Литературная гостиная как одно из средств патриотического воспитания студентов........................................... 43
**Галиева Г.** Этнические автостереотипы в татарских паремиях......................................................................................................... 46
**Гаптелбаров И., Саляхова С.** Табу слов, или «словом можно убить, словом можно спасти»........................................................... 48
**Гәрәева Ә.** Татар фольклорында музыкаль жанр (бишек җырлары)........................................................................................... 50
**Гомәрова Д.** Төс компонентлы чагыштыруларның татар әдәбиятында чагылышы................................................................... 53
**Гурьев А.** Концепт слова «таҥара» (бог)........................................... 56
**Гүләр О.** Караманлы төрекләр турында кыскача мәгълүмат........... 57

**Гыйззәтуллина А.** Мәгърифәтче, галим, дин әһеле Ш. Мәрҗани ... 58
**Гыйльмиева Д.** Татар халык авыз иҗатында шүрәле образы......... 63
**Гыймадиева Г.** Татар һәм төрек телләрендә килеш категориясе..... 65
**Давтян К.** Основные сходства и различия местоимений в русском, татарском и английском языках........................................................ 68
**Дагарова А.** Қазақ тіліндегі окказионализмдердің лингвомәдени сипаты.................................................................................................... 71
**Данилова С.** Способы перевода тропов поэтических произведений (на примере переводов А. Лаврика в литературно-художественном журнале «Полярная звезда»)................................ 74
**Даулаити Д.** Күңел концептының лексик-семантик кыры............. 76
**Дәүләтшина Э.** М. Әгъләмов иҗаты: үсеш-үзгәреш тенденцияләре һәм үзенчәлекләре............................................................................... 78
**Дәүликамова И.** Хатлар – телнең тере шаһите............................... 79
**Диас Е.** Фразеологические единицы, обозначающие юношеский возраст, молодость в английском и русском языках.......................... 81
**Долгова Л.** Халык һәм автор җырларында гөл образы.................... 85
**Егорова Я.** Семантизованные модификации гласных в якутском языке........................................................................................................ 88
**Ербулатова И.** К вопросу о содержании понятия «реалия» как переводческого термина............................................................. 90
**Ермағамбетова А.** М. Қашғаридің «Диуани лұғат ат-түрік» еңбегіндегі мақал-мәтелдер................................................................. 93
**Жұмабекова Ж.** «Айман-шолпан» жырындағы этнографиялық деректердің ұлттық тәрбиедегі маңызы............................................... 96
**Заһидуллин Р.** Милли асылыбыз – туган телдә ............................... 99
**Закирова Г.** В. Нуриев хикәяләренең тәрбияви әһәмияте............. 101
**Закирова М.** Робагыйлар – күңел ташкыны.................................. 103
**Закирова Т.** Ш. Мәрҗани эшчәнлегенә үткән заманнарда һәм бүгенге көндә караш.................................................................... 106
**Захарова А.** Образные прилагательные в якутском героическом эпосе П.А. Ойунского «Дьулуруйар ньургун боотур»..................... 108
**Ибатуллина Р.** Татар сөйләшләрен өйрәнә башлау тарихы........... 111
**Исмәгыйлева Л.** Г. Тукай иҗаты үрнәгендә укучыларда милли мәдәни-тарихи күзаллау формалаштыру.......................................... 113
**Камалетдинова А.** Татар матбугатында «маңкорт» сүзе................ 116
**Карипжан Самал.** М. Әуезов еңбектеріндегі фольклор мәселелері.......... 119
**Кольчанова Ю.** Тема родного языка в творчестве Р. Хариса......... 121
**Куличкина П.** Приемы перевода синонимов на русский язык (по произведению Г. Тукая «Шурале»)............................................. 124
**Куравина М.** Тема родного края в творчестве А. Рашита.............. 126
**Кэюму К.** Лингвокультурологическая специфика фразеологических единиц татарского языка........................................................................ 129
**Латыйпова Ч.** Ф. Әмирхан иҗаты үрнәгендә укучыларда мәдәни-тарихи күзаллау тәрбияләү............................................................... 132

**Лукина Ю.** Лексические параллели названий украшений татарского и якутского народов........................................................ 134
**Маннанова А.** Мишәр диалектында гарәп алынмаларының мәгънә тараю очрагы.......................................................................... 136
**Мирҗанов Р.** Татар телендә «вакыт» концепты.............................. 138
**Мөхәммәтҗанова А.** Татар теле дәресләрендә сүзлекләр белән эшләүнең мөһимлеге...................................................................... 141
**Муллахмәтова Л.** Г. Исхакый мәкаләләрендә милләт язмышы проблемасы................................................................................ 143
**Мырзағалиева А.** «Кедейлік» концептісіне жататын ақпараттық лексемалардың концептілік қызметі................................................ 145
**Намакаева З.** Особенности индивидуально-авторского стиля Джером К. Джерома в повести «Трое в лодке, не считая собаки»... 148
**Нәбиева Р.** Рус теленнән кергән алынма сүзләргә кушымчалар ялгау мәсьәләсе.......................................................................... 150
**Нигъмәтҗанова А.** М. Мәһдиевнең «Без – кырык беренче ел балалары»н урта мәктәптә өйрәнү үзенчәлекләре.......................... 155
**Нуретдинова И.** «Күз» сүзенең лексик-семантик мәгънәләре........ 158
**Нуруллаев А.** Концепт цвета в священном Коране: лингвокультурологический аспект................................................. 160
**Олесова М.** С. Данилов саха сиригэр тылбаас сайдыытыгар кылаата («Чолбон» сурунаал матырыйаалынан).............................. 162
**Портнягина Л.** Словесное ударение в якутском и хакасском языках... 164
**Птимбаева А.** Қазақ ертегілерінің тәрбиелік мәні мен тағылымдық маңызы.......................................................................... 166
**Рақымғалиева А.** Лексикалық синтагматика мен норма мәселесі.. 169
**Ризванова Э.** Сөйләм эшчәнлеген белдергән фигыльләрнең татар халык авыз иҗатында кулланылыш үзенчәлекләре......................... 171
**Сабирова Э.** Татар телендәге прагматонимнарның этномәдәни потенциалы.................................................................................... 173
**Сабирҗанова Д.** Балаларда тәнкыйди фикерләүне үстерүче технология буларак әдәби тәнкыйть................................................ 176
**Сагирова А.** Г. Тукай әсәрләренең тәрбияви әһәмияте................... 179
**Садриева Р.** Х. Туфан иҗатында мотивлар.................................... 181
**Сәйфетдинова Д.**Г. Бәшировның «Туган ягым – яшел бишек» әсәрендә туй йоласы чагылышы...................................................... 184
**Санатуллина Х.** Ә. Рәшит иҗатында тарихи тема.......................... 186
**Сатанар М.** Конвергентный подход в изучении архаической эпики олонхо: перспективы развития............................................... 189
**Сафина А.** Г. Афзал иҗатында юмор һәм сатира............................. 191
**Сафиуллина Г.** Макроструктура и микроструктура англо-татарского словаря для учащихся.......................................... 194
**Софронеев П.** Культ медведя у сибирских тюрков (алтайцы, тувинцы, якуты)................................................................................ 197
**Стручкова Я.** Особенности восприятия красного цвета в якутских и татарских пословицах................................................................. 200

**Тимерханова И.** Татар халык иҗатының кыска җырларында «Хәсрәт» концептының кулланылыш үзенчәлекләре....................... 202
**Тянь Фань.** Особенности отражения безэквивалентной лексики в лингвострановедческом словаре «Россия»...................................... 205
**Фарсыева Г.** Семиотика красного цвета в переводах сказок братьев Гримм на татарский язык...................................................... 207
**Фәсхиева З.** XX-XXI гасыр сүзлекләрендә ризык атамалары ........ 209
**Фахразиева А.** Татарская община Санкт-Петербурга: вопросы сохранения языка и культуры............................................................ 211
**Хайбуллина А.** Особенности перевода терминов на башкирский язык на сайте «Башинформ»................................................................ 214
**Хайруллина А.** Лексико-семантические средства выражения психологизма в английском, татарском и русском языках............. 216
**Хәйретдинова А.** Татар һәм рус фразеологизмнарындагы «кеше» сүзенең синонимнары ...................................................................... 218
**Нуэрсяти Х.** Уйгур телендә баш киеме атамалары........................... 221
**Хасанов А.** Сравнение формул приветствия в татарском, турецком и языке урду......................................................................................... 223
**Хисамова А.** М. Мәһдиевнең «Торналар төшкән җирдә» әсәрендә саннар символикасы.......................................................................... 226
**Хисияма Ю.** Татар теленең кушма җөмләләрендәге -лык кушымчасы........................................................................................... 228
**Хөснуллина Г.** XX гасыр ахырында басылган татарча-русча сүзлекләр................................................................................................ 231
**Хөснетдинова Ә.** Чувашия җирләрендә яшәгән татарларың актуаль проблемалары.......................................................................... 234
**Шадрина С.** Национальные обряды в творчестве Б. Урманче........ 236
**Шарапов К.** Татарский язык в области компьютерных технологий: особенности машинного перевода................................ 239
**Шафикова Р.** Хәзерге татар телендә гарәп тамырларының лексик-семантик үзләштерелеше..................................................................... 242
**Шәехова А.** Татар телендә алмашлык сүз төркемен уен технологиясенә нигезләп өйрәтү......................................................... 245
**Шакирҗанова А.** Татар телендә фразеологизмнар һәм аларның рус теленә тәрҗемәсе......................................................................... 247
**Шакирова А.** Сөйләмебез төзекме?................................................. 249
**Шенер С.** «Ләһҗәи татари» һәм «Ләһҗәи османи» хезмәтләре..... 253
**Шигапова Г.** Особенности креолизованных рекламных текстов... 255
**Sabirova R., Yarullina A.** Comparative analysis of phraseological units expressing feelings and emotions.................................................. 257

*Научное издание*

# ТЮРКСКАЯ ЛИНГВОКУЛЬТУРОЛОГИЯ

## ПРОБЛЕМЫ И ПЕРСПЕКТИВЫ

**материалы IX Международной научно-практической конференции учащихся, студентов и аспирантов**

**Казань, 20–21 февраля 2018 г.**

Подписано в печать 15.02.2018.
Бумага офсетная. Печать цифровая.
Формат 60x84 1/16. Гарнитура «Times New Roman». Усл. печ. л. 15,35.
Уч.-изд. л. 13,97. Тираж 100 экз. Заказ 132/2.

Отпечатано с готового оригинал-макета
в типографии Издательства Казанского университета

420008, г. Казань, ул. Профессора Нужина, 1/37.
Тел.: (843)233-73-59, 233-73-28